# Казан утлары



8

АВГУСТ

1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

**8**

АВГУСТ
1968

## Бу санда:

РОМАН, ПОЭМА, ХИКӘЯ ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР

**Г. АХУНОВ.** **Хуҗалар.** Роман . . . . . . . 3
**Р. ХАРИСОВ.** **Мулланур.** Шигырь . . . . . 51
**НГУЕН ЧУНГ ТХАНЬ.** **Са-ну урманы.** Хикәя. Ә. Синегулов тәрҗемәсе . . . . . . . 55
**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** **Балачактан туры...; Ишетәсеңме...; Күпсенмә, күк!..; Сөерсең, дисең, яши...; Мәңгегә яратам диммм...; Яктыга төшә күз...; Күпмегә тулды...; Ул көннәрне инде...; Шәфәкъләр алсу-алсу...; Хакыйкать ул...; Сөю көчле иманнан...; Теләге бәхеттә иде...; Хәерлегә булсын.** Шигырьләр . . . . . . . 69
**М. СӨНДЕКЛЕ.** **Икмәк валчыгы; Бер генә; Назим Хикмәттән.** Шигырьләр . . . 72

ОЧЕРКЛАР

**М. ГЛУХОВ.** **Тибрәндереп күңел кылларын** . 73

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Э. МОСТАФИН.** **Көймә көтеп утырабыз; Юллар чатында; Ак каеннар...; Чәйгә салган...; Авылда бер көн; Бер җыр килә; Яңгыр тамды; Аккошлармы...; Һавада кошлар гына.** Шигырьләр . . . . 80
**Ә. РӘШИТОВ.** **Мунчадан репортаж; Семей; Мәдхия.** Шигырьләр . . . . . . . . . 83
**П. АПУШЕВ.** **Күңелдәге һәйкәл; Владимир Комаровка; Аның кыры...; Гашыйклар.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . 86

МЕНДЕЛЕЕВСК ХИМИЯ ЗАВОДЫНА 100 ЕЛ

**Т. СӘГЫЙТОВ.** **Буыннар язмышы** . . . . . 88

ЯЗУЧЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ДӘФТӘРЕННӘН

**Г. БАКИРОВ.** **Каләм һәм сугыш** . . . . . 95

ЮРИСТ ЯЗМАЛАРЫ

**Н. ЯМАЛИЕВ.** **Тәрәзәгә кем аткан!** . . . . 104

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ХИКӘЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**Ф. ХӨСНИ.** Хикәя укыйсым килә! . . . . 118
**М. ӘМИР.** Игътибар җитми . . . . . . 122

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**И. САЛАХОВ.** Фәхретдин бине Мифтахетдин . . . . . . . . . . . . . . 124

ИРКЕН МИНЕМ ТУГАН ИЛЕМ

**Н. ХӘКИМУЛЛИН.** Җир сулышы. Фоторепортаж . . . . . . . . . . . . 133

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**Ш. ГАЛИЕВ.** Балалар дөньясы . . . . . . 144
**З. ГОМӘРОВА.** Тәрәзә төбендә; Кучердем дә кучердем; Йокы чүлмәге. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 146

КИТАП КҮЗӘТҮ

**А. ХАЛИКОВ, Р. ФӘХРЕТДИНОВ.** Татар халкы турында зур фәнни хезмәт . . . . . 147

УКУЧЫЛАР ФИКЕРЕ

**Р. ЯКУПОВ.** Рәхмәтләр юллыйм . . . . . 155

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Г. ВОЛКОВ.** Педагогның якты язмышы . . 156
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . 158

**Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Редактор өчен: Ләбибә Ихсанова
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 14/VI-1968 ел. Басарга кул куелды 26/VII-1968 ел. ПФ 09039. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 64546 экз. Заказ Д-1038. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1968 ел.



# ХУҖАЛАР

## Гариф Ахунов

С. КУЛЬБАКА рәсемнәре

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

РОМАН

1

Башкала ерак калды.

Карга күмелеп утырган авыллар, тимер юл буена сыенган бәләкәй станцалар утлы күзләре белән җемелдәп төн эченнән чапкан поездны зарыгып көтеп алалар да, аның сәлам дә бирми китүенә үпкәләгәндәй, тавышсыз-тынсыз артка йөгерәләр.

Вагон чайкала. Тәгәрмәчләр тукылдый. Каяндыр югарыдан әкрен генә радио сөйли. Ул, гүя, төнге авазларның барысын бергә җыеп, бала бишеге янына баскан анадай, пассажирларны йокыга әзерли.

Арслан йоклый алмый. Куллары белән иягенә таянып, тәрәзә буенда, бәләкәй өстәл янында утыра. Күптән утыра инде: чемоданыннан юл киемнәрен дә алып кими, вагон чайкалудан түгелеп, суынып беткән чәенә дә кагылмый.

Мәскәүдән аның белән бергә утырып чыккан Камил Мөстәкыймов — партиянең шәһәр комитеты секретаре — иптәшләрен эзләп күрше вагонга киткән иде, әле һаман кайтканы юк. Арслан белә — алар анда күңел ачалар. Кайтмач — эш муеннан, буш вакыттан файдаланып калырга кирәк.

Арслан бүген үзе дә, начальник икәнен онытып, «тузан коеп» алырга каршы килмәс иде. Ләкин анардан читләшәләр, аның шешә белән дус булмавын белгән көннән бирле, аны компанияләренә алмыйлар.

Чөйдә портфель эленеп кайта. Вагон чайкалган саен шап-шоп стенага бәрелгән энә шул калын сары портфельдә Арсланның челпәрәмә килгән өметләре кайта...

Моннан ике ел элек Арслан Кыңгыраулы Чишмә мәйданын кабул итеп алган иде. Күз күреме житмәс киң ялан. Үзәннәрдә авыллар яшь, чишмәләр ага, елга тугайларында көтүләр йөри... Нефть эзләүче разведчиклар килде, унбиш километр саен бер скважина куеп, кул-аяк тимәгән Яңа мәйданның запасын барлап чыктылар. Нефть белгечләре әйтте: Кыңгыраулы Чишмә ел саен дүрт миллион тонна нефть биреп барачак.

Гыйльми институт Яңа мәйданны эшкәртүнең проектын төзеп бирде. Проектта бер нәрсә — эрәмгә яна торган газ искә алынмаган. Йөзләгән скважинаның газы корым булып күккә оча, күгелҗем томан булып үзәннәргә җыела. Нишләтәбез аны?

Дөнья галимнәре исәпләп чыгарган — егерменче гасыр уртасына җир шарының нефть запасы житмеш миллиард тонна калган. Күрер күзгә бик зур сан бу, ләкин ул запас планетага утыз биш елга гына житәчәк. Арслан — ун ел нефть эшендә, ун ел бүе промыселларда газ яна. Гади бер бораулаучы яки бурмастер булып эшләгән чакта аның эрәм янган газга каршы көрәшердәй көче юк иде. Хәзер ул — производство командиры, яшәп килгән хуҗасызлык белән килешсә, аның тигез урында түмгәк булып утыруыннан кемгә файда?

Кыңгыраулы Чишмә яклары урманга ярлы, утынга ярлы; борынборыннан монда агач кытлыгы, йортларны сөяннән, усактан салганнар, өйне салам ягып, кизәк ягып җылытканнар.

Яңа промыселларның ике меңнән артык операторы авылларда яши. Кышкы салкын иртәләрдә, Кыңгыраулы Чишмәнең төрле якларыннан — житмеш ике авылдан — операторлар җир маен суыртырга дип скважиналар янына җыела. Аларның тормышын ямьлерәк итәсе иде бит. Авыллар бөтәйде хәзер — гаражлар, клублар, таш мәктәпләр салына. Аларны җылытасы, аларга җан өрәсе бар.

Промыселларда газ яна.

Нефть калаларында кышын яшел кәбестә юк, помидор, кыяр юк. Саласы иде гигант теплица, рәхәтләндерәсе иде калаларны яшелчәгә. Авылларда яшәүче нефтьчеләр ягулыкка тилмерә. Зәңгәр баллоннарга тутырып, өләшәсе иде өйләргә Яңа промыселларның бәрәкәтле газын.

Кыңгыраулы Чишмә мәйданына завод саласы иде. Европа масштабындагы завод түгел. Союз күләмендәге заводка да исәп тотарга кирәкми. Газ-компрессор заводы. Яңа промыселларның үз газын эшкәртердәй генә...

Арслан Кәлимәтнең Техник китапханәсеннән материаллар сайлап алды, илнең төрле өлкәләрендә эшләүче зур белгечләр, инженер-төзүчеләр белән хат языштып озаклап киңәште һәм, тәвәккәлләп, Идарә проектчыларына моңарчы күрелмәгән яңа эш тапшырды. Башта бик дулкынланып тотынганнар иде, тора-бара куңелләре сүрелде. Чөнки бу эшнең барып чыгачагына бернинди өмет тә юк, завод бюджетка кертелмәгән иде.

Арслан бер елдан Яңа промыселлар идарәсенең техсоветын җыйды. Идарәнең баш инженеры, файдалы эш дигәндә җанын ярып бирергә әзер торучы Вадим Сергеевич Золотухин, беренче булып каршы чыкты. Чамасыз кайнар табигатьле бу кеше сикереп урыныннан торды да юка кылыч борынына элеп куйган тар кысалы күзлеген йолкып алды:

— Арслан Шәвәлиевич! Акылыгызга килегез. Кем безгә завод чаклы завод салырга рөхсәт бирсен?! Бу бит көлке! Кешеләрне юкка өметләндермик, буш хыяллар белән башларын әйләндермик, — диде.

— Башкалар ни уйлый? — диде Арслан, сабыр гына.

Өч кеше дәшмәде. Баш технолог Шәйхеразимов, җилкәсен җыерып, уңайсызланып елмайды.

— Белмим... бу хәл минем башыма сыймый. Моны, минемчә, без түгел, совнархоз, һич югы, «Татнефть» берләшмәсе күтәрергә тиеш иде.

Арсланны берләшмәдә дә якламадылар.

— Сабыр итик, иптәш Гобәйдуллин. Партия бездән әлегә завод сорамый, нефть сорый, — диделәр.

Берьюлы ике оешмада кире кагылу Арсланны уңайсыз хәлгә китереп куйды. Ул үзен ялгыз итеп, ярдәмчесез итеп тойды. Кычытмаган җирне кашып йөри, диделәр аның турында. Золотухин эшне куертып җибәрде: төп вазифабызны онытабыз, эшчеләр кайгысын кайгыртырга вакыт!

Арслан башта түзде. Әмма үң кулы булырга тиешле баш инженерның нефтьчеләрдә кирәкмәгән ярсыну уятуы аны партком секретаре Тажи Вилданов белән киңәшеп карарга мәҗбүр итте. Тажи — аз сүзле кеше. Артыгын сөйләмәс, акыл сатмас. Урта мәктәпне бетергән көннән промыселларда ул: беренче торбаларын салышкан, беренче факелларын кабызган, фонтан асларында калып, нефтькә коенган. Заманында ул экономист булырга җыенып йөрде. Институтка китәсе елны кулбашын имгәтеп, озак кына авырып ятты, аннан терелүгә сукыр эчәгесен кисеп алдылар. Ул арада яше чыкты. Институтны да, практиканы да — барысын бергә промыселларда узарга туры килде аңа. Арсланны якласа әнә шул Тажи яклый, әгәр инде ул да кирәксез дип таба икән — күңелдә йөрткән хыяллар белән саубуллашырга туры килә.

Сөйләшү партком бүлмәсендә булды. Очлы терсәкләре белән өстәлгә таянып, ләм-мим бер сүз дәшмичә, Вилданов аны ярты сәгать буе тынлап утырды. Парторгның какча йөзенә, теләктәшлек-мазар белдермәгән ярым йомык күзләренә карап, Арслан үкенә башлады. Нигә сөйли соң әле ул? Тажи йоклап утыра түгелме соң?

Юк, Тажи йокламаган иде. Беравык дәшми торгач, гади генә итеп әйтте:

— Золотухинга тимәгез. Намуслы инженер ул. Кеше просто арыган: үн ел сугыша инде, ирешкәне — вак-төяк. Борчылмаска, канатсыз яшәргә өйрәттеләр безне. Еллар буе. Бик озак...

Тагын сүзсез калды, Арсланның күзләренә карады.

— Проект тирәсендә кешеләрне бик озак азапладың шул. Гайрәтләрен чигердең. Проектны хәзер директив органнарга тапшырырга вакыт. Шуңарчы безгә бер нәрсәне ачыкларга кирәк: нинди акчага салабыз заводны? Җидееллыкның бюджеты инде расланган. Дәүләт безгә акча бирмәячәк бит.

— Узган елны экономияләгән бер миллион акчабыз бар.

— Менә монысы — чын сөйләшү. Димәк, без дәүләт кесәсенә кермибез. Завод күпмегә төшәчәк — чама белән исәпләдеңме?

— Документларны күп актардым, белгечләр белән сөйләштем, ике миллионнан да артмас, диделәр.

— Ә калган бер миллионны каян алабыз?

— Әгәр партоешма булышып, яшьләрне, комсомолны күтәрсәк, хәрәкәтсез фондларны худка җибәрергә була.

— Бик хуп. Ә эшне кемнән башлыйбыз?

— Госкомитеттан.

— Юк, иң элек, минемчә, проектны Институтка биреп тикшертеп алырга һәм тиешле оешмалардан раслатырга кирәк. Шуннан соң гына без югарыдан рөхсәт ала алабыз. Үз көчебез белән башкарып чыгуга бик нык басым ясарга кирәк.

Институт төзәтмәләр кертеп проектны башта нефть берләшмәсе карады, аннан ул совнархозга күчте. Совнархоз күршедә генә булса

бер хәл иде, ул бит әнә кайда — Куйбышевта ук. Теләгән чагында ялт кына барып керә дә, тиз генә сөйләшә дә алмыйсың.

Документлар Куйбышевта өч ай ятты.

Баш инженер Золотухинга да мәшәкатьләнергә туры килде. Ул, ике мәртәбә махсус командировка алып, Куйбышевка барып кайтырга мәҗбүр булды. Икенче баруында ризасызлык аның йөзенә үк чыккан, ул тагын завод салудан баш тартыр дәрәҗәгә житкән иде инде.

Ничек булса булды, тырыша торгач, документлар Главкага барып керде. Керде дә тоткарланып калды.

Шалтыратып та карадылар, хат язып та сорадылар, җавап килми дә килми.

Ул арада Кыңгыраулы Чишмә мәйданын бораулый да башладылар. Тәҗрибәле карт мастер Лотфулла Дияров үз җаена, ашыкмый гына эшләсә дә, яңадан-яңа скважиналар өлгертеп кенә тора. Арслан сизеп йөри: озакламый «хәрәкәтсез фонд» исемлегендә йөри торган, ягъни бораулап бетерүгә авызын томалап куйган скважиналар саны күзгә күренеп артачак. Ә алар Яңа промыселлар идарәсенең нефть чыгару планына керәләр, бер сүз белән әйткәндә, промыселны артка сөйри башлаячаклар. Лотфулла агай янына аның улы Булат Дияров та кушылып, рәттән ике скважинаны рекорд белән тәмамлагач, Арсланның күңеленә шом төште.

Яңа скважинаны товар паркларына тоташтырырга, җир астыннан торбалар сузарга, нефть кудыру станцалары салырга кирәк. Завод кайгысы артык планга күчте.

Арслан аңлый: ил зур, нефть берләшмәләре күп, Госкомитетта алар кайгысы гынамыни!? Ләкин эш кетә, кешеләр тынгысызлана.

Бигрәк тә Золотухин борчыла. Бер уйласаң — баш инженер хаклы. Завод проектына кул куеп биргәннән соң, Яңа промыселлар идарәсенә газ житештерү планы да өстәделәр. Бер ел узды, — завод юк, газ планы каргыш булып өстә асылынып тора. Премияне кистеләр. Кешеләрнең кесә ягына сукты бу, ризасызлыкны көчәйтте.

Бәйрәм демонстрацияләрендә аларны хәзер иң артка куялар. Эшчеләр гарьләнә, Арслан ягына ымлап, тонык кына гүлиләр иде.

Арслан үз карамагындагы барлык телефоннарны худка җибәреп, нефть берләшмәсеннән дә гозерләнеп әйттерә торгач, ниһаять, аны Госкомитетка чакырып алдылар.

Каушап һәм дулкынланып юлга чыкты Арслан. Кайчандыр, сугыш вакытында, Белоруссия урманнарында партизан булып йөргән чакта, разведкага барыр алдыннан шундыйрак хис кичерә торган иде ул. Төн эченә чумып, үзенә йөкләнгән сугышчан задание белән күзгә-күз калгач кына каушау ничектер үзеннән-үзе бетә, тез буыннары ныгый, аның бөтен барлыгын тәвәккәллек һәм ышаныч биләп ала торган иде. Ләкин алар ул чакта өчме-дүртме егет бергә йөриләр, янәшә баруларын, бер-берсенә кирәк булуларын сизеп торалар, ә бүген ул ялгызы, аның алдында, тынлыгы белән куркытып, Госкомитетның соры таш бинасы калкып тора.

Биек түшәмле ят бер кабинетта аны илле яшьләр тирәсендәге калку буйлы, пөхтә киемле кеше каршы алды. Арслан күрешергә дип кулын сузганда, бер генә мизгелгә туктап, гаҗәпләнеп калды. Аның каршысында кайчандыр Кәлиматтә шау-шу куптарып, Кәрим Тимбиков үлеменнән соң эшеннән алынган Николай Николаевич Кожанов басып тора иде. Никадәр үзгәргән ул: яңак сеңгерләре бүртеп чыга торган усал, кырыс йөзе түгәрәкләнә төшкән; кайчан карама тырпаеп, тузгып торган тыңлаусыз чәчләре шома итеп, майлап тараган; өстенә кигән киеме дә кайчандыр партработниклар Сталиннан күчереп алган ярым хәрби китель түгел, күзләрне иркәли торган нәфис йон костюм иде.

Кабинетның хуҗасы, Арсланның йөзенә бәреп чыккан гаҗәпләнүне күреп, дустанә елмаеп күреште:

— Саумы, коллега? Күрәм: сез гаҗәпләнеп калдыгыз.

— Николай Николаевич... Мин сезнең Мәскәүдә икәнегезне ишеткән идем, ләкин, беләсезме... монда очрашырбыз дип...

— Уйламаган идегезме?

— Чын әгәр.

Кожанов дала җилләре кискән кара тут йөзле Арсланның бетон багана кебек нык, таза гәүдәсен үлчәп-сынап күздән кичерде дә өстәл яныннан урын тәкъдим итте. Буровой гөрелтеләре эчендә калган әллә кайчангы гаугалы тормышын күңел төбеннән актарып, Кәлимәт турында сораша башлады. Сорашыр нәрсәсе күп иде аның. Ни дисәң дә, гомеренең алтын чагын ул анда, Татарстанның беренче нефть мәйданнарында, үткәрде, көчен һәм белемен кызганмыйча, нефть чирәмен күтәрешә — илдәге иң зур бораулау трестының управляющие булды. Аны куып җибәрделәр. Госкомитеттагы шушы урынын ул гаять зур тырышлык белән яулап алды. Менә инде аның кул астында эшләгән яшь-яшь егетләр олы кыяфәткә кергәннәр, чәчләренә чал куна башлаган. Әле күптәнмени ул аны эшкә кабул иткән иде, аның белән бергә кар көртләре эченнән чыга алмый яткан вахта автобусларын этешкән иде. Бүген аның каршысында — зур бер производствоның командиры. Әллә ниләр куптарып, завод даулап йөри. Дәвере шулай — кешеләрне чәчләреннән тартып үстерә. Тик әле аңа сабыр итәргә туры килер. Завод — кечкенә нәрсә түгел. Ордым-бәрдем генә салып булмый аны...

— Күңелсез хәбәр әйтергә туры килә бит, иптәш Гобәйдуллин, — диде Кожанов, уңайсызланып.

— Ничек?! — Арслан бөтен гәүдәсе белән алга сөрлекте. — Яраксызмыни безнең проект?

— Проект әйбәт. Материаль база юк, туганкай.

— Без бит дәүләттән акча сорамыйбыз.

— Беләм. Завод салу белән генә эш бетми. Заводтан торбалар сузарга, әзер газны каядыр кудырырга кирәк. Торбаны Трансевропа таләп итә — «Дуслык» магистрале. Кстати, ул сездән башлана — Кәлимәттән. Менә шулай, коллега, сабыр итеп торырга туры килер.

— Кайчанга чаклы?

Анысын инде Кожанов әйтә алмый. Бәлки бер ел, бәлки биш ел узып китәр. Һәрхәлдә, өметне өзмәскә кирәк. Җитәр вакыт — хәбәр итәрбез.

Арслан, мөмкин хәтле сабыр булырга тырышып, заводның бик тә, бик тә кирәклеген, нефть чыгаручыларның тормышы яхшырачагын дәлилләп аңлата башлады. Кожановның чырае кырысланды, сөйләшү беткәнне аңлатып, ул урыныннан торды.

Арслан шаккатып, гаҗиз булып, аптырап калды. Сүгенә белә торган булса, ул бәлки Кожановка берәр усал сүз әйтүдән дә тартынмас иде, ләкин сүгенә белми иде шул. Үпкәсен, рәнҗешен эченә йотып, Госкомитетның соры ташлы салкын бинасыннан чыгып китте.

...Һәм менә аның челпәрәмә килгән өметләре чөйдә эленеп кайта. Юк, ул Кожановка үпкәләми. Кем ул Кожанов? Заман үзгәргән саен төсен үзгәртеп торучы. Кичә ул гадәттән тыш комиссар киемендә иде, нефтьче егетләр белән яңак сеңгерләрен биетеп, өстәл сугып сөйләшә иде, бүген итагатьле интеллигент костюмы киеп алган, сүзен үлчәп кенә, елмаеп кына сөйли. Аңар нәрсә — инструкция ни кушса, шуны үти, никадәр төгәлрәк үтәсә, шулкадәр тынычрак яши.

Промыселларда газ яна. Еллар буена. Моңа кем җавап бирә? Гомумән, кайчан да булса җавап бирүче булырмы?

Арслан, башын куллары белән кысып, озак кына тын утырды. Нефтьче операторларның тормышын күңеллерәк, мәгънәлерәк итү

хыялларының юкка чыгуын, эрәмгә янган газ кебек, төпсез бушлыкка, күккә очуын уйлап, көрсенеп куйды. Сугыш вакыты, Белоруссия урманнарында партизан булып йөргән чаклары тагын исенә төште. Үзенең һәм иптәшләренең гомерен кыл өстенә куеп, хәтәр операцияләргә баруы, дошман эшелоннарын тау астына тәгәрәтеп, илне һәлакәттән коткарышуы турында уйлады. Ул чакта аңар ышаналар, аны яклыйлар иде. Нәрсә хакына эшләде соң ул аларны? Әнә шул Кыңгыраулы Чишмә мәйданнары, яңа заводлар салу хакына түгелмени? Бүген алар рөхсәт итмиләр. Бу хәл аның башына сыймый, аның намусын рәнҗетә, күңелен газаплый иде.

Авыз эченнән күңелле бер көй көйләп, Камил Мөстәкыймов кайтты. Өстәл буенда бөкрәеп утырган юлдашына:

— Моңаябызмы, Арслан Шәвәлиевич?.. — диде.

Арслан дәшмәгәч, тавышсыз гына чишенеп, салкын одеял эченә кереп ятты.

Поезд ниндидер бәләкәй станцадан узды, ахрысы, күз иярмәс тизлек белән сары утлар йөгерешә башлады, тәгәрмәчләр тукылдады. Арслан ритмлы тукылдаган тәгәрмәчләр тавышын тыңлап утырды. Алар, гүя, аны үртиләр, башкалага бардыңмы, эш кырмакчы булдыңмы? — диләр.

«Кыр-дың-мы? Кыр-дың-мы? Кыр-дың-мы?» — дип тукылдыйлар тәгәрмәчләр.

## 2

Арсланны өендә дә күңелсезлек көтә иде. Ләкин ул күңелсезлек башта караңгы чырайлы булып түгел, ташып торган шатлык булып килде.

— Арсланым минем, юлбарысым! Рәхмәтләр яусын сиңа! Күктән көткәнне җирдән бирде! Рәхмәтләр яусын! — дип, Сәгыйдә аны, ишектән кайтып керүгә, ашкынып муеныннан кочаклады.

Арсланның бер кулында чемодан, икенче кулында портфеле белән төргәкләре иде. Ул аларны идәнгә куярга да, кулында тотып торырга да белми, Сәгыйдә, аңар сүз әйтергә дә ирек бирмичә, шатлык-сөенечен өермәдәй өереп, берьюлы бушата иде.

— Гомер буе хыялланып йөрдем. Балалар рәхәтләнер инде. Ул матурлыгы! Ул йомшаклыгы! Түшәк тә түшәк, ул да түшәк! Рәхәтләнер балаларым. Ышанасым килми. Билләһи менә, чын әгәр! Ничек башыңа килде ул синең, ничек әйтеп калдыра белдең?! Кил әле, үбим әле бер үзеңне! Сагыныплар беттем бит инде! Арсланым минем, юлбарысым!

Арслан берни аңламый иде әле. Өстенә бизәкле чуар халат киеп алган, күе кара чәчләрен маңгай өстеннән ак тасма белән җыеп бәйләгән Сәгыйдә аны кулыннан җитәкләп алды да йөгертеп диярлек залга алып керде. Арслан тик хәзер генә аңлап алды: зал идәнен тутырып, зур бер келәм җәелеп ята. Келәм залга байларча төс кертеп җибәргән, аңа карап торулары ук күңелле. Арслан аптырап калды — аның беркемгә дә заказ биргәне юк бит. Хатынының шатлыгын берьюлы бозмас өчен, ул иплән кенә келәмне кем китергәнен сораша башлады.

— Гозәеров абый алып килде. Арслан Шәвәлиевичнең туган көненә, ди... Кырык яшь — зур бәйрәм, түгәрәк дата, ди...

— Кайчан китерде?

— Кичә. Балаларны бакчадан алып кайтып кына тора идем. Ике кеше келәм күтәреп керделәр.

«Туган көн икәнне кем әйткән, кырык яшь тулганны каян белә? — дип күңелсез генә уйлап алды Арслан. — Менә син тамаша. Бу бәладән ничек котылырга инде?»

Сәгыйдә иренең кәефе киткәнен шундук аңлап алды.

— Нигә, Арслан, әллә китерергә кушмаган идеңме? — диде.

— Тукта... Мин аның белән сөйләшим әле, — дип, Арслан телефон трубкасына үрелде.

Сәгыйдәнең йөзе очлаебрак китте. Ул, муенын сузып, ире сөйләшкәнне тыңлап тора башлады.

— Гозәеров кирәк иде. Әһә! Ислам агай, үзегезме? Гобәйдуллин борчый әле сезне. Рәхмәт. Гөрли дим, гөрли башкала. Йомыш бар иде сездә. Юк, болай гына әйтә торган түгел. Безгә килеп чыгыгыз әле. Әйе. Мәскәүдән алып кайткан күчтәнәчем дә бар...

Телефоннан килергә ризалык бирделәр. Арслан трубканы элде дә, гаепле кеше сыман, уңайсыз гына елмаеп:

— Сәгыйдә, табын әзерләргә туры килә инде, кунак чакырдым, — диде.

Сүз тыңлаучан, ирен хөрмәтләп яшәргә күнеккән Сәгыйдәнең Арслан Мәскәүдән кайтышка дип пешергән ризыгы күп иде. Табын әзерли-әзерли, Мәскәү хәлләрен сораштырды.

— Юллар уңмады... — диде Арслан, аңлатып тормас өчен чемоданнан бүләкләрен чыгара башлады.

Ак җирлеккә яшел бизәк төшерелгән, өф итеп өрсәң очып китәрдәй җинел җәйге күлмәкне хатынына тоттырды. Сәгыйдә, көзге каршына килеп, күлмәкне иңенә салып карады, кулы белән сыпырды; Арсланны әллә ни арада үбеп алды һәм тагын кухня ягына йөгерде. Улы Рафикъка Арслан бөке белән ата торган пистолет, кызы Әлфиягә күзен йома белә торган курчак, табын янына булыр дип, Сәгыйдә заказы буенча, Мәскәү конфетлары, кыйммәтле кызыл балык алып кайткан иде.

Сәгыйдә үз нәүбәтендә Арслан кайтышка дип кичә үк пешереп куйган тавыгын, вак бәлешен холодильниктан чыгарып, җылытасын җылытып, тәлинкә-тәлинкә өстәл өстенә тезеп куйды.

— У-у! Күбрәк булмыймы бу, энисе? — диде Арслан, елмаеп.

Сугыштан кайткач, биш ел буена заводта эшләү, аннары нефтьче булып, буровойда көннәр буе коры-сары ашап йөрү аны ризык-мазарга талымсыз булырга өйрәткән иде.

Идарә башлыгы булганнан соң, промыселларга чыгып, көннәр буена нефть чыгаручы операторлар арасында йөргән чакта да ул кырга ризык-мазар алып чыкмый, нефтьчеләр белән бергә «кумәк казаннан» ашарга ярата иде.

Менә хәзер әллә ни арада өстәлгә килеп утырган шул хәтле ризыкнигъмәтне күргәч, аңа хәтта уңайсыз булып китте.

Зал белән кухня арасында яшь киленнәр кебек җилкенеп, ихлас күңелдән йөгереп йөргән чуар халатлы хатыны — чак сизелердәй юаная башлаган, дөресрәге — бәхетле тигез тормыштан, сабыр холыклы, ягымлы ир белән яшәүдән тулышып кына киткән Сәгыйдә, бүген аңа аеруча якын, аеруча үз иде. Ул аны сагынган, гел күрәсе, үз янында тотасы, иркәлисе-назлыйсы килә иде. Арсланның дулкынлануы Сәгыйдәгә дә күчте, Сәгыйдәнең күңелендә дә сүз белән әйтеп булмый торган якты бер тойгы, яратасы һәм яратыласы килү тойгысы уятты.

Табын әзерләнеп бетүгә, Гозәеров та килеп җитте. Ишекне сак кына шакып, тыйнак кына килеп керде ул. Кергән мәлгә ашыгып түргә узмады, ишек төбендә туктап, өйдә кемнәр барын чамалап алды. Чакырылган кунак үзе генә икәнлегенә төшенгәч, аның кара мыеклы чибәр йөзенә елмаю чыкты. Әдәп өчен бераз кыстатып, татар гадәте буенча, чамасын белеп кенә ялындырып, заманча җыйнак, элегант пальтосын, яшь тюлень мехыннан тегелгән бүреген салып, чөйгә элде. Тик очлы башлы чит ил ботинкасын салуга эш терәлгәч, ул чак сизелерлек икеләнде. Аңа шундук Сәгыйдә ярдәмгә килде: аяктан салырга кирәк түгеллеген әйтеп, аны кыен хәлдән коткарды.

— Сәгыйдә дөрес әйтә, узыгыз, Ислам агай, — диде Арслан.

Шуннан соң Гозәеров артык кыстатып тормады. Ишек төбендәге коры чүпрәккә бик җентекләп аягын сөртте дә, Арсланга ияреп, зал ягына узды. Аның суыктан алсуланган кара-кучкыл йөзенә канәгатьлек билгесе җәелде. Ул кичә китергән зур, затлы келәм, бөтен өйне балкытып, идәндә ята! Аның тырышлыгын аңлаганнар! Болай булгач, сорыйсын аяк терәп сорарга була.

Алар тик хәзер генә кул биреп күрештеләр. Гозәеров Арсланның дәү кытыршы кулын кысты. Идарә башлыгының кулы каты иде. «Моның белән чамалап сөйләшергә кирәк», — дип уйлады Гозәеров.

Арслан кунагын табын янына чакырды.

Чуклы калын эскәтер ябылган түгәрәк өстәл өстендәге дефицит азыкларга, чит ил этикеткасы ябыштырылган җәлпәк шешәле коньякка күз сирпеп алгач, Гозәеровның ышанычы арта төште: яратканнар аның бүләген, юкса шул хәтле үз итеп каршы алырлар идемени? Гобәйдуллинны ул бернинди мактауга да, бернинди бүләккә дә исе китми торган усал начальник дип кенә ишетә белә иде. ОРСта эшләүче дуслары әйттеләр аңа, кара аны, Ислам, Гобәйдуллин сине келәмең-ниең белән милициягә илтеп бирергә мужыт, диделәр. Һи, белә инде ул, Гозәеров, сәүдә эшендә бер ел гына эшләве түгел, җүнле җимгә капмаган балыкның булганы юк әле. Тик җим салуның җаен белергә, тупас кыйланмаска гына кирәк... Ә бу юлы Гозәевровка чуртанның бик зурысы капты, шәһәрнең ярты байлыгы аның кулында. Теләсә ул сине солтан итә, теләмәсә олтан итә.

Табын янында Гозәеров үзен бик тыйнак һәм әдәпле тотты. Коньяк аның күрмәгән шәрабы түгел. Кирәк дип әйтәләр икән, бүген үк, сәгате-минуты белән таба ул аны. Сине зурлап чакырулары үзе ни тора!

Гозәеров сөйләвен дә күп сөйләмәде, матур гына елмаеп, Арслан Шәвәлиевичны тыңлап, аның сүзен генә җупләп утырды. Мәскәү хәлләрен сорашкан чагында, начальникның юлы уңмаганга чын күңелдән борчылды, хәтта Мәскәү түрәләре адресына берничә усал сүз әйтүдән дә тартынмады. Тормыштан бик аерылганнар бит алар Мәскәүләр, кабинетларының дүрт стенасыннан башканы белмиләр, янәсе...

Коньякны бәләкәй рюмка белән ашыкмый гына эчтеләр. Гозәеров Арслан Шәвәлиевичнең коньяк сайлый белүен мактады. Шушындый шәрабны югарыдагы сәүдә оешмалары нефть шәһәренә, гомумән, башкаладан ерактагы калаларга бик сызланып кына җибәрәләр, дип үкенеч белдерде. Югыйсә, азмы бездә йөзем җимеше, азмы бездә аның осталары! Өйрәтергә иде бит нефтьчеләрне рюмка тотарга. Юкса нәрсә килеп чыга? Стаканлап Бөгелмә аракысын чөмерәләр дә, айныткычка эләгеп, үзләре дә хур булып бетәләр, предприятие башлыкларына да тел-теш тия. Шуның аркасында семьяда күпме низаг, күпме күңелсезлек!

Арслан, аның сүзен хуплагандай, баш кагып куйды. Бу исә үз нәүбәтендә Гозәеровның кыюлыгын тагын да арттыра төште. Кәлимәттә әле сәүдә эшенең тиешле югарылыкка куелмавын, ашханәләрдә чисталык җитмәвен, китап киоскларының аз булуын сөйләп алды. Ул менә ничә мәртәбәләр шул хакта горисполком утырышында сүз кузгатты, тыңлаган чакта килешкән кебек тә булалар, карарын да чыгаралар, сессия узып киттеме, тагын барысы онытыла. Ә ни өчен онытыла? ОРСта күңел биреп эшләгән акыллы җитәкче юк. Әнә Краснодуров заманында Кәлимәттә барысы да бар иде, ите-мае да җитә, әлемлекнең дә дүрт-биш төрлесен алырга була иде. Краснодуровның бездән китеп, Түбән Камада эшли башлавы булды — Кәлимәттә җүнле нәрсә калмады. Кеше кайда гына эшләмәсен, үз эшенең остасы булырга тиеш. Краснодуров эш рәтен белә иде, дуслары да күп иде. Советлар Союзы

тулы иде аның дуслары. Бүген аның ике вагон кофесы сатылмый ятамы — ул аны әрәм итеп торгызмый шул инде. Ул аны шундук Мәскәүгә озата, ә Мәскәүдә, үзегез дә беләсез, кофесыз тора алмый бит халык. Товар ятмаска тиеш, товар ятса — чери, бозыла, халыкка да, дәүләт кесәсенә дә зыян булып төшә...

Арслан аның йөзенә сыный төшеп карады. Инде илле яшьләрдән узып киткән бу кешенең чырае яшь иде әле. Коньяктан һәм ышанып сөйләүдән ул тагын да алсуланыбрак киткән, юклы-барлы бер-ике җыерчыгы да язылган, төз борыны, куе кара кашлары, борын астындагы бармак бите чаклы гына килешле кара мыегы, ара-тирә уңайсызланыбрак елмаюы — барысы әйбәт тәэсир калдыралар, шуның өстәвенә Арслан аның үз эшен белеп, яратып эшләвен дә ишеткән иде. Аны менә хәзер пенсиягә чыгачак ОРС начальнигы урынына куйсаң да начар булмас иде, тик бер ягы бар: гаделме ул? Тырышып йөрүе җылы урын өчен, баер өчен, үз кесәсен калынайтыр өчен генә түгелме?

Сүз әкренләп шул якка таба борылды.

— Гафу итегез, сер булмаса, ОРСка кемне куярга уйлыйсыз, Арслан Шәвәлиевич? — диде Гозәеров, сүз җаен китереп.

«Хәйләкәр. Минем кылны тартып карамакчы», — дип уйлады Арслан, ләкин уен белдермәде.

— Горком кемне тәкъдим итәр бит, — диде.

Гозәеров кулына тоткан рюмканы чәкешергә дип китергән җиреннән кире куйды, ничектер алга иелә төшеп:

— Анысы инде, Арслан Шәвәлиевич, яшерен-батырын түгел. ОРС начальнигын горком куймый, идарә начальнигы куя. Ник дигәндә, шәһәр сәүдәсе нефтьчеләргә хезмәт итә, — диде. — Беләсезме, Арслан Шәвәлиевич, шәһәрне әйбәт тәэмин иткәнебез юк. Әгәр дә сез ризалык бирсәгез...

— Ләкин мин бик усал бит, рәхимсез, — диде Арслан, аның тел төбен аңлап.

— Усал кеше — гадел кеше була ул, Арслан Шәвәлиевич.

— Әйе, мин гаделлек ягында. Гаделлек ягында мин, — дип, Арслан кинәт кенә өстәл яныннан кузгалды. — Ислам агай, сез миңа турысын гына әйтегез әле: бу келәмнең чын бәясе күпме тора?

Гозәеров болай ук маңгайга тәрәп биргән сорауны көтмәгән иде, бер генә мәлгә ул тотлыгып калды. Нәкъ менә кирәкмәс чакта тотлыгуның, ык-мык килеп торуның шәп түгеллеген, ниндидер астыртын мәгънәсе барлыгын начальник аңлар дип уйлап, тизрәк җавап бирергә ашыкты:

— Сез сорамагыз, мин әйтмим инде аны, Арслан Шәвәлиевич.

— Ә нигә? — диде Арслан. — Аның ни гаебе бар?

— Бүләкнең бит бәясен сорамыйлар, Арслан Шәвәлиевич. Бүләккә сөенәләр генә. Бикәчеңә дә бик ошады. Ул бит болай. Сезгә кем генә килми, авторитет дигән нәрсә бит ул акыллы булудан гына килми, яшь белүдән дә килә. Мәскәүдән дә, Казаннан да түрә-кара килми тормас. Аларны бит конторда гына түгел, өеңдә дә кабул итәсе була. Келәмсез йорт бит ул, ничектер, нурсызрак...

— Анысы дөрес, — диде Арслан. — Келәм миңа кирәк иде. Юк, түрәләргә күрсәтергә түгел. Балалар идәндә уйнарга ярата лар. Ә идән суык. Күпме тора бу келәм?

— Юк ла инде, Арслан Шәвәлиевич, булмаганны... Әйтеп торам бит: бүләккә акча алмыйлар. Кырык яшеңдә шундый бер бүләк тә алмагач, кая сезнең авторитетыгыз?

— Юк, шулай да сез аның бәясен әйтегез, — диде Арслан үзсүзләнеп, — мин бит, Ислам агай, үз бәямнең күпмерәк торганын белергә тиеш...

Гозәеров баштарак, Арслан бик төпченә башлагач, шүрләбрәк калган иде. Азмыны хәзер кызыл авызланып кыланучылар. Тотар да өстенә акыра башлар.

Ләкин идарә начальнигы сүзен әйтеп бетерүгә матур гына итеп елмаеп куйгач, Гозәеровның эченә жылы йөгерде.

— Инде алай дип әйтәсез икән, Арслан Шәвәлиевич, бәясе күпме тора икәнен белергә телисез икән, списать иткән товар дип ялгыша күрмәгез, складтагы иң шәп коверны китердем мин сезгә. Бәясе моның инвентарь исемлегендә чистогоном биш йөз дә житмеш бер сум тора.

— Сезнең хезмәт хакыгыз күпме? Йөз житмеш биш сум бугай, хәтерем ялгышмаса?

— Бик дөрес әйтәсез, Арслан Шәвәлиевич, бер йөз дә житмеш биш сум.

Арслан башын чайкап куйды.

— Сезгә бит бу келәмнең бәясен өч ел буе түләп барырга туры киләчәк.

Гозәеров — Арсланнарга килгәннән бирле беренче мәртәбә — жәелеп бер елмайды: кара мыегы астыннан ак тешләре жемелдәшеп күренделәр.

— Их, Арслан Шәвәлиевич, сез мине ул хәтле үк төшеп калган кеше дип уйламагыз. Кемнең соң бүләкне хезмәт хакына алганы бар! Азмы әрәм булган товар. Табигый зыянга дип биргәне дә житә бит аның. Сезгә бер келәм харам булмас: ил байлыгы артсын дип, көне-төне чиегез чыга лабаса!

— Яхшы алайса, рәхмәт, — диде Арслан, Гозәеровның кулын кысып. Ислам ага чак кына кычкырмый түзеп калды. Арсланның кулы шундый каты иде. — Рәхмәт, агай, зурладыгыз, — диде тагын бер тапкыр. — Көтмәгән идем сездән. Моны ничек алып килдегез соң? Авырдыр бит бу? Ким дигәндә, биш пот бардыр?

— Бик дөрес әйтәсез, Арслан Шәвәлиевич, биш поттан биш кенә килога ким бу, — диде Гозәеров. — Япа-ялгызың гына күтәреп алып килерлек түгел. Кая ул! Автобуска салып алып килдем. Жиңел машинага салып караган идем, сыймый, автобус чакыртырга туры килде.

Ул рәхәтләнеп бер көлде. Ләкин аңа көлүеннән капыл гына тукталырга туры килде.

— Яхшы! — диде идарә башлыгы, бик кинәт житдиләнеп. — Сез моны, Ислам агай, төреп алыгыз да, каян алган булсагыз, шул урынына илтеп куегыз.

— Шаяртмасагыз иде...

— Шаяру бетте! — Арсланның күзләре кысыла төштеләр.

Гозәеров та елмаерга дип жәелгән авызын жыеп алды. Кинәт бөркү булып китте аңа, чигә турысында бер тамыры тартыша башлады.

— Алган жиргезгә илтеп куегыз, — диде Арслан, сабыр гына. — Алдан ук кисәтеп куям, тагын бер мәртәбә андый эш эшләгәнегезне белсәм, шундук судка бирәм.

Гозәеровның кара мыеклы алсу йөзе кәфен кебек агарды.

## 3

Сәгыйдә төне буе елап чыкты.

Гозәеровның үртәлеп һәм соң дәрәҗәдә рәнжеп, келәмне күтәреп чыгып китүе, Арсланның тәрәзә янагына сөялеп, салкын бер рәхимсезлек белән аның артыннан карап калуы — Сәгыйдәнең бар дөньясын айкап ташлады.

Башта ул түзде. Балалар бакчасына барып, Рәфигы белән Әлфиясен алып кайтты. Аларга Мәскәү күчтәначләрен бирде. Иренен тешләп, кечке ашны әзерләде, тамакларын туйдырып, балаларын йоклатты, шун-

ан соң үзләренә урын җәеп, сүзсез-нисез генә караватка менеп ятты. Арсланны чакырмады, аңа хәерле төн дә, тәмле төшләр дә теләмәде. Арслан үзе килер, дип көтте. Әй, көтеп тә карады соң аның килеп гафу үтенүен!

Кысылып кына калган ишек ярыгыннан зал якның уты төшә, Арслан әллә китап укый, әллә язулары белән утыра — селкенеп тә карамый иде.

Сәгыйдәнең күңеле тулып, ташып китте. Ә нинди начарлык эшләде әле ул аңа? Шулай күрәләтә мыскыл итәләрмени? Соң ул бит аның ничек сөенгәнен күреп торды лабаса! Ярар, Гозәеров келәмне аңа ялагайланып, аны үз ягына аудару теләге белән дә китерсен, ди. Шуның өчен ныгытып кына бер тиргәргә дә, тиешле бәясен түләп, алып калырга иде. Харап булган инде, ул гына бик гадел, ул гына тигезли дөньяны!

Ята торгач, ул үзенең ялгыш фикер йөртүен, иренең бик җаваплы урында эшләвен уйлый башлады. Әгәр ул үзе аның урынында булса һәм хәзер ире хәлендә калса, нишләр иде? Хакы бармы соң аның Арсланга үпкә белдерергә? Юк, барыбер артыгын кыланды Арслан. Ярар, Ислам агай хаклы да булмасын, аны сатып алырга да теләсен, нигә шул хәтле рәхимсез рәвештә аңардан көләргә, аның серләрен ачтырып бетергәнче коньяк эчеп, сайрап утырырга?

Ни өчендер аның гел Гозәеровны яклыйсы килә, ул аны кызгана, аның янына үзен куеп, үзен дә үләр чиккә җитеп кызгана иде... Әгәр менә хәзер Арслан аның янына килеп, аңардан гафу үтенсә, ул инде күптән тынычланган булыр иде, болай гына тынычлана алмый шул инде. Җылак капчыгы ычкындымы — хатын-кыз тиз генә җылаудан туктый беләмени ул...

Үз-үзен һәм Гозәеровны кызганып, тавышсыз гына күз яше коеп ята торгач, Сәгыйдә арыды, йокымсырагандай булды, күпмедер вакыт узгач, ямьсез төшләр күреп, саташып уянды.

Аннары бөтенләй күзенә йокы кермәде.

Юк, ул Арсланны барыбер хаклы түгел дип тапты. Тик бу юлы инде аның күңеле бераз йомшый төшкән, ул аның белән бергә үткәргән кыз чакларын, Арсланның больницага эләккән вакытларын исенә төшергән иде.

Туктале, ул чакта да соң аны, фельдшер кызны, Арсланның һәрнәрсәгә аек һәм гадел карый белүе, гадилеге тарткан иде түгелме соң? Ул бит аның күңел киңлеген, ихлас һәм туры булуын җизнәләре Кәримнәрдә рекорд бәйрәме үткәргән чакта ук сизеп алган иде. Мине таныштыр әле дип апасы Мөнәвәрәгә ялынган иде. Апасы моңаеп кына авыр сулап куйгач, алайса мин үзем танышам, берегез дә кирәк түгел, дигән иде. Больницада ул аның аягы төзәлүен эчке бер зарыгу, хәвеф һәм борчу белән көтте. Ялгыш ялганмагае, аксак булып калмагае дип борчылды. Беренче мәртәбә бинтны кисәргә килгәч, яңгырга эләккән иде. Әй рәхәт, җылы яңгыр булган иде ул, Сәгыйдә җеп бөртекләренә чаклы чыланган, суга төшкән чебеш хәлендә калган иде. Ыңгырашып җибәрер дәрәҗәдә чын итеп күз алдына китерде ул бәхетле көннәрен. Капка төбенә чыгып утырган Арсланны, аның таза, яшь йөзен, кара чәчләрен, тыныч-сабыр йөзен күз алдына китерде. Аның беләгенә хәтта җылымса яңгыр тамчысы тамгандай булды, күңелен айкап, Арсланның өздереп карый торган кара күзләре чагылып китте. Ләкин шундук күңелен икенче бер тойгы, алдану һәм рәнҗү тойгысы биләп алды. Беләгенә тамган җылы яңгыр аның күз яше иде. Арслан хәзер аның хәлен дә белергә теләми, гафу да үтенми, зал ягында китапларына багынып утыра.



Өйләнешеп тора башлагач та шактый ук авыр бер тойгы кичереп алган иде Сәгыйдә. Бер ел уздымы икән, артыкмы, ул кинәт Арсланның аны үзе кебек үк өзелеп яратмавын, жаны-тәне белән сөймәвен, итагатьле һәм ихтирамлы гына булып йөрүен сизеп алды. Һай, авыр да булган иде дә соң ул чакта! Әгәр шул хис гомер буена китсә, Арслан аңа карата ихтирамлы-битараф булып кына калса, ул түзмәс, аның тынгы белмәс кайнар жаны жавап хисе эзләп талпыныр, алар гомерлеккә бергә була алмаслар иде.

Ул чакта инде Сәгыйдә беренче баласына авырлы иде. Әле һаман больницада эшли, эштән соң һавада күбрәк булырга тырыша, әллә больницада кайбер гарип туган балалар белән очрашкангамы, котлары алынып, баласының исән-сау тууын көтә иде.

Таза булып, нык булып туды аларның уллары. Больницадан алып кайтырга Арслан такси яллап килгән иде. Үзе белән бергә эшләүче врач кызлар аны шау-гөр килеп озатып калдылар.

Арслан Сәгыйдә кайтышка балалар караваты алып куйган иде. Рәфикъны шунда юрганы белән салдылар, бәби каршы алырга килүчеләр төрле-төрле шалтыравыклар китергәннәр иде, караватка аркылы каеш тактылар да каешка шалтыравык попугайны элеп куйдылар.

— Әнекәем лә! Шалтыравыкны күрә! — дип сокланып әйтеп куйды Фәйрүзә апалары. — Билләһидер менә, карап ята бит ул, шайтан баласы!

— Ничево! Шалтыравыкны күрмәсә, каешны күрер, — диде Арслан, елмаеп.

Ата белән ананы бала бәйли диләр, дөрес икән. Арслан гажәеп дәрәжәдә бала жанлы ата булып чыкты. Ул эштән кайтуга Рәфикъны күтәреп ала да үчтекләп сикертә, сакауланып әллә ниләр сөйләнә, тәмам хикмәтләнеп бетә иде. Рәфикъ мүкәләп йөри башлагач, Арсланның да тормышы идәнгә күчте: ул да мүкәләп йөри, ат булып кешни, ә Рәфикъ аның муенына атланып, әтисен өзлексез куалап тора иде. Аннары Әлфия туды.

Күңелләрне нечкәртердәй ул көн менә хәзер Сәгыйдәнең күз алдыннан барлык матурлыгы, барлык рәхәтлекләре белән үтеп китте.

...Сәгыйдә инде соңгы көннәрен йөри, аның битенә мул булып сары тут төшкән, иреннәре күпереп, калынаеп киткән, кыяфәте моңсу, сабыртыенкы булып калган иде. Вахтадан кайткан Арсланга ашарга әзерләп бетергәч, Сәгыйдә Рәфикъны йоклатырга дип йокы бүлмәсенә чыкты. Дүрт яшь тулып узган иде инде ул чакта Рәфикъка. Башка малайлар кебек, Рәфикъ та песи ярата иде. Бу юлы да ул Мияубикәсен юрган астына алып яткан. Сәгыйдә, песи баласын алмакчы булып, караватка үрелде.

— Йокласын инде, әнием, — диде Рәфикъ.

— Юк, улым, йокламасын, йоны коела аның, авызыңа керер.

— Йокласын, әнием, аяк очына гына куям, авызыма китермим.

Сәгыйдә песидән Рәфикъның күңелен биздермәкче булып:

— Менә песи белән күп уйнасаң, больницага салырмын әле үзеңне, — диде. — Йоклаган чакта юкка гына тешеңне шыкырдатмый тор-

гансындыр әле син, эчендә корт бардыр әле. Песи корты утыра торгандыр.

— Ә анда соң бүтән малайлар бармы, больницада? — диде Рәфикъ, шүрләп.

— Синең кебек песи белән уйный торган малайлар бар.

— Нишлиләр алар анда?

— Ашыйлар, йоклыйлар. Врач аларга дару эчертә.

— Ник?

— Кортлары коелсын дип.

— Ә анда рәсем ясыйлармы?

— Рәсем дә ясыйлар.

— Ә син минем янга килерсеңме?

— Килми булмас.

— Кайчан?

— Төш вакытында. Аннары — кичен, эштән соң.

— Нәрсә алып килерсең?

— Мәмиләр.

— Ә мин сине кочаклап үбәрмен, яме.

— Барасыңмыни больницага?

— Син бар дисәң, барам... — диде Рәфикъ һәм кинәт башка сүзгә күчте: — Әни, әни, ә нигә мин бер үзем?

Улының соңгы сүзләрен ишетеп, бала караваты янына Арслан да килеп җитте.

— Ничек бер үзең? — диде ул, улына төбәлеп.

— Равилнең Фәрите, Фәридәсе бар. Рөстәмнең — Мансуры. Ә мин бер үзем...

— Ә сиңа кирәкме соң алар? — диде Арслан, Сәгыйдәгә күз кысып.

— Кирәк. Бер малай. Я Фәрит, я Мансур шикелле.

— Ә сеңел булса?

— Әйем, кызлар кирәкми.

— Ник?

— Кызлар җылак була. Фәридә гел җылый әнә.

— Улым, аны сайлап алып булмый бит. Больницада кемне бирәләр, шуны аласың. Әнисең әнә кыз алам дип барган иде, сине биреп җибәрделәр.

— Юк, малай бирсеннәр...

Сәгыйдәгә больницада малай бирмәделәр, кыз бирделәр. Кыз балага тыны-көне бетеп сөенде Арслан. Сөенче алырга чыккан нянкене кочаклап үбеп, аңа берьюлы егерме биш сум акча тоттырган, дип кереп әйттеләр Сәгыйдәгә.



Энисе белән сеңелесен алмага больницага Рәфикъ та килде. Сеңелесенә ул шалтыравык попугай белән койрыгын күтәреп, авызын ачып торган маэмай алып килгән иде. Тәтиләрне Рәфикъ үзе күтәреп килде һәм, бирәүгә дә бирмичә, үзе күтәреп кайтты.

Рәфикъ сеңелесен бик яратты. Аңардан да битәр эти кеше яратты кызын. Арсланның шатлыгы эченә сыймый, эштән кайткан чакларда да елмаеп кайтып керә, Сәгыйдәнең хатын-кызга хас вак-төяк капризларын олы җанлылык белән, карышмый-нитми үти иде. Сәгыйдә кинәт сизеп алды, Арсланның балаларга булган мәхәббәте, коры саламга дөрләгән ут шикелле, аның үзенә, Сәгыйдәгә күчте. И бәхетле дә сизгән иде соң ул чакта Сәгыйдә үзен!

Әйе, бүгенгә тикле шулай иде. Иркәләүгә, әйткән бер сүзнең үтәлүенә күнегеп беткән Сәгыйдәгә бик кыен булды бу келәм вакыйгасы. Арсланның ул гадел кеше, исәп-хисап мәсьәләсендә четерек кеше, әйткән җиреннән өзеп чыгара торган нык кеше икәнен онытып җибәргән иде шул. Аның иң зур теләгән кисәк өзеп төшерү, сөенечен рәхимсез рәвештә, бер селтәнүдә алып ташлау бик авыр булды аңа.

«Әллә яратмый башладымы икән? — дип шомланды Сәгыйдә, — әллә арага берәрсе килеп кердеме?» Кинәт, күңеленә ут салып, апасы Мөнәвәрә күз алдына килде. Әллә арага ул килеп кердеме? Ничек инде ул керсен, аның бит безгә җиде ел килгәне юк. Менә шул шул: килгәне юк. Ә нигә килми ул? Берни дә булмаса, килер иде. Туйга да килмәде, балалар тугач та күренмәде, котлау хатлары язып, бәбәй ашларын юлаучы кешеләр аркылы гына җибәреп ята. Юк, монда нидер бар, шик бар монда. Ул бит Кәлимәттән нибарысы утыз-кырык чакрым ары бер авылда яши, зур юл өстендәге мәктәптә укытып ята, бер килмәсә, бер килер иде, килми калмас иде, нидер бар монда, нидер бар, бар...

...Арслан бу вакытта сагынып кайткан хатыны белән очрашуның ямен бетерүенә үкенеп утыра иде. Ул үзен, хатынының кадерле муенсасын йолкып алып, аның күз алдында аяк астына салып таптагандай, уңайсыз хис итте. Аның Сәгыйдәне юатасы, «Кайгырма, әнисе, келәмне мин сиңа иртәгә үзем алып кайтып бирермен», — дип әйтәсе килде. Ләкин әйтә алмады, ул арыган, аның үзенең дә зур сөенечен, Сәгыйдә келәме кебек, кулыннан тартып алдылар бит. Арслан шушы сәгатьтә үк хатынын юата алмаячагын аңлап, Сәгыйдәнең йоклап киткәнен көтеп утырды.

Ләкин Сәгыйдәнең йокысы качкан иде. Ул бик озак ирен көтеп ятты, көтеп-көтеп тә, ире килмәгәч, урыныннан торып, зал якка чыкты. Эче җу итеп китте. Арслан анда юк иде. Тиз генә кухняга керде, карады, анда да юк: бөтенләй куркуга төшеп, балалар бүлмәсенә керде, исе китте: Арслан, бала кебек бөгәрләнеп, улы Рәфикъ янында йоклап ята иде...

## 4

Иртәнге чәйне сүзсез генә эчтеләр. Сәгыйдә берничә мәртәбә иренә үпкә сүзләрен, кимсенүле авыр тойгыларын белдерергә җыенган иде, ләкин үзен тыеп кала алды. «Юк, барыбер әйтергә, аның да җанын әрнетерлек итеп гауга чыгарырга кирәк әле», — дигән үчлекле уй аның күңелендә сакланып калды.

Беләсе иде, хәзер менә шушы минутта, аның тастымаллар бөркәп, барлык хәсиятен китереп пешергән хуш исле куе чәен эчкән чакта, кашларын җыерып, нәрсә уйлый ул? Нәрсә уйласын, аны тиргидер. Гомер-гомергә мал-мөлкәткә ябыштың, ди торгандыр. Нигә, әллә мин келәм өстенә келәм сорыйммы? Берәүнең дә артыгын чыгарып ташлаганы юк. Матур киемне кем яратмый? Затлы келәмнәр җәелгән өйгә кайтып керү кемгә рәхәт түгел? Барысы да мал җыя, начальник хатын-

нарының олысы да, кечесе дә. Нигә Сәгыйдәгә генә күктән иңгән фәрештә булып кыланырга?

Ләкин Арслан бу минутта киләм хакында да, киләмгә бәйләнешле кичәге вакыйга хакында да уйламый, ул аны инде оныткан иде. Болар инде арттә, еракта калды. Әллә кайчан булган бер вакыйга кебек, күңелнең төпкелендә томан пәрдәсе белән капланып бара иде. Хәзер идарә башлыгын ярты сәгатьтән шәһәр комитетының беренче секретаре Корбанов белән булачак очрашу борчый иде. Ни дип әйтер ул аңа? Тажи Вилданов та түземсезләнеп көтәдер. Алар ни дип әйтер? Золотухин да көтәдер. Ул инде бу күңелсез хәбәрне артык исе дә китеп кабул итмәс. Ә идарәнең гади операторлары, инженерлары ни диярләр? Алар да бит шул ук Корбанов, шул ук Вилданов кебек, яхшы хәбәр ишетергә телиләр. Бүгенме, иртәгәме, һич югы, ярты елдан, бер елданмы, өйләребезгә газ керер, поселокларыбызга җан өретер дип өметләнеп торалар. Аларга нәрсә диярга? Юкка өметләнгәнсез, мин булдыксыз житәкче булып чыктым, югарыда сүземне үткәрә алмадым, үзем башлаган эшне үзем җимереп кайттым дияргәме?

Шул хакта уйлары куера барган саен, аңа өй эче тарая, чәйнең дә тәме юк, хатыны Сәгыйдәнең дә артык тырышып пудраланган йөзе сөйкемсез булып тоела башлады. Арслан, эчә башлаган чәен эчеп бетермичә, урыныннан торды.

— Нишләвең бу, этисе, эчеп бетер инде чәеңне! — диде аңар Сәгыйдә.

Арслан дәшмәде. Сүзсез генә тәрәзә буена килеп басты. Тәрәзәдән каршыдагы ике катлы таш йортның кыегы күренә, аның теге ягында корымдай куе кара төтен ургылып-ургылып күккә күтәрелә иде.

«Яз житә, эшләгән гөнаһларыбыз берәм-берәм җир өстенә чыга, — дип уйлады Гобәйдуллин, борчылып. — Ничек туктатырга шул нефть түгүне?»

Арслан тиз генә өстенә киенде, бәхетсез проект салынган калын сары портфелен кулына алды. Ишек төбенә житкәч, дәшми-нитми чыгып китүне уңайсыз санап, хатыныннан:

— Бүген кич дежурствога барасың бармы? — дип сорады.

— Барасым юк. Нигә? — диде йокысыз үткәргән төннән соң күз төпләре җилсенгән Сәгыйдә.

— Киноа билет алып кайтыйммы?

Сәгыйдәнең күңеле тулды. Баш кагып кына билет алырга мөмкин икәнне аңлатты. Арслан аны үзенә тартып китерде дә, яшьле күзләреннән үбеп, ашыгып чыгып китте.

Урамга чыккач, күкрәк тутырып, иркенләп бер сулыш алды. Зәгъфран тавы өстендәге күгелҗем урманга, еракагы вышка силуэтларына карап торды. Болытлы соры күк фонында алар тоныкланып күренәләр иде. Кары эри башлаган Зәй тугайларыннан дымлы җил исә, төтен исләрен алып килә. Нефтьчеләр шәһәре көндәлек мәшәкате белән яши: йөк машиналары доңгырдап чаба, автобуслар гөжләп уза, тротуарның ике ягыннан, соры бетон коймалар буеннан, брезент киемле кешеләр эшкә ашыгалар иде.

Арслан бер генә мәлгә кай якка юл тотарга белми икеләнебрәк калды. Хәзер үк эшенә китәргәме, әллә шәһәр комитетына кереп чыгаргамы? Әгәр идарәгә китсә, шофер Бәхетгәрәевне чакырырга кирәк — Яңа промыселлар идарәсе Кәлимәттән кырык чакрымнар ары урнашкан. Тик аның әле бүген, менә шушы сәгатьтә үк, анда барасы килми. Бару белән Золотухин кереп житәчәк. Ике арада нинди сөйләшү буласы билгеле инде. Арслан кискен бер карарга килде: Золотухин белән очрашканчы Нәҗип Корбановны күрергә, шәһәр комитетының беренче секретарена күңелне бушатырга да, нишлим дип, киңәш сорарга. Аннары инде Золотухин белән сөйләшү җиңелрәк булыр.

Ашыкмый гына шәһәр комитетына таба китте. Юлда баргында идарә эше белән бәйле уйларын уйлады. Аны тау чаклы эш көтә. Юллар өзелгәнче иң зур фонтанлы җиде скважинаны капиталь ремонттан чыгарасы бар. Кар астына су төштеме — ремонт вышкалары, авыр агрегатлар ачык кыр өстендә батып калачаклар. Нефть бирми торган кысыр скважиналарың белән тутырып кара аннары планны! Өстәвенә Кыңгыраулы Чишмә мәйданында бораулаган яңа скважиналар авызларын томалаган килеш торалар. Аларны әле кайчан товар паркларына тоташтырасың... Эш муеннан! Мәшәкать мәңге дә бетәчәк түгел.

Арслан уйлый торгач, үзе өчен бер хакыйкатьне ачыклады: фонтан атмый торган скважиналар да, капиталь ремонт та, язгы кыр өстендә тракторларның йөри алмавы да — болар бер быел гына килеп туган мәшәкатьләр түгел. Ел саен, ай саен кабатланып, өстәлеп торалар алар. Арсланның иң зур хыялы тормышка ашмады — алар шуңа аеруча зур булып күренәләр бугай...

Шәһәр комитетының кабул итү бүлмәсендә секретарь кыз Әнисә, баш өстенә кибән чаклы итеп өйгән җирән буяулы чәчләрен рәтлирәтли, балаларча беркатлы, якты күзләрен балкытып, аны олылап каршы алды, ләкин шундук йөзе үзгәреп:

— Их, Арслан Шәвәлиевич, вакытсызрак килдегез, Нәҗип Идрисович пленумга әзерләнә, берәүне дә кертмәскә кушты, — диде.

Арсланның киңчә кара тут йөзеннән соры күләгә узып китте. Менә син бәхетсезгә вакытсыз. Ул, бер кулына сары портфелен, икенче кулына йөнтәс зур бүреген тотып, кием элгеченә карап, уңайсызланып басып тора иде әле. Кабинетыннан Корбанов үзе килеп чыкты. Аның җыерчыклар белән буразналанган йөзе тонык иде. Арслан бер күз сирпүдә Корбановның үз уйлары белән яшәвен сизеп алды. Аңа күренергә, исәнләшергә ашыкмады. Корбанов Әнисәгә тиз генә нидер әйтте дә, үзенә кереп китим дигәндә, Гобәйдуллинны күреп алды.

— Арслан! Саумы, туганкай! Минем янгамы?

— Менә ни... Сезгә дип килү иде дә, — диде Арслан, аңа кул биреп күрешкәндә. — Менә бит әле Әнисә туташ әйтә...

Корбанов, Әнисәгә карап, рөхсәт сораган сыман елмайды. Гобәйдуллинны үзе белән кабинетына алып кереп китте.

— Чишен, әнә элгечкә эл пальтоңны, — диде ул, стена буйлап бик күп урындыклар тезгән кабинетына килеп кергәч. — Я, кил, сөйлә, ниләр җимереп кайттың?

Арслан, аның каршысына килеп утыргач, үзен әле генә тәртип бозып тотылган малай кебек хис итеп:

— Җимердем шул... — дип әйтеп куйды.

Корбанов чуалып төшкән чал чәчләрен кулы белән баскалап һәм идарә начальнигына бөтен барлыгы белән төбәлеп:

— Я, сөйлә, сөйлә. Баштан ук сөйлә, — диде.

Гобәйдуллин аңа Мәскәүдә Кожанов белән булган очрашуны баштанаяк сөйләп бирде. Корбанов сагая төшеп, тамырлары бүрткән зур кулларын өстәл өстенә куеп, тынкы гына тыңлап утырды.

Беренче секретарь теге елларны да Кожановның тормыш принциплары белән бигүк килешеп бармый иде. Николай Николаевич Кәлимәткә корыч дисциплина алып килде. Масштаблылыкка, ил күләмендәге данга дәгъва кылды. Тик аның колач киңлеге үз мәнфәгатенә, карьерачылыкка нигезләнгән булып чыкты. Девон скважиналарын бораулауда баш әйләнгеч рекордлар куйган Кәрим Тимбиковның фаҗигале үлеменнән соң Кожановка яшь нефтьчеләр каласын ташлап китәргә туры килде. Кәлимәт шәһәр комитеты аңа Союздагы иң зур бораулау тресты белән җитәкчелек итүне алга таба да ышанып тапшыра алмады. Кожановның трест җитәкчелегеннән алынуын ул чакта Корбанов үзе таләп итте. Менә хәзер кая барып урнашкан икән. Бу аның, постыннан

файдаланып, инициативаны буарга теләвеме? Әллә Кәлимәт башлыкларыннан үч алуымы?

Шушы урында Корбановның күз алдында кара урман һәм шул урман аланында кара-каршы очрашкан ике арслан килеп басты. Аларның берсе — кайчандыр сугышып хәлсезләнгән, ләкин хәйләкәр булып калган карт арслан, ул көч җыйнарга, хәл алырга өлгергән; тагы да бер мәртәбә сугышып, тәүге атаманлык хокукын алырга тели; икенчесе — яшь, көчле, ләкин әле хәйлә-мазарны белми, сугышса да булган көче һәм үз-үзенә нык ышануы белән гадел сугыша торган арслан. Карап карарбыз, кайсы җиңеп чыгар?

Корбанов өстәл өстендә яткан трубкасын алып, озаклап аңа тәмәке тутырды, ут кабызды һәм тирән итеп эчкә бер төтен алгач, Арслан Гобәйдуллинга сәленке чал кашлары астыннан сөзеп карап, әти кеше кебек салмак, ягымлы тавыш белән сүз башлады:

— Синең бик әйбәт бер ялгышың бар, Арслан туган. Син моңа кадәр бөтен нәрсәне үзем генә башкарып чыгам, дип уйлап йөрдең. Горкомны борчырга теләмәдең. Яшьлегеңә, энергияңә таяндың, ахыр килеп, югарыда утыручыларның гаделлегенә исәп тоттың. Ләкин алай гына булмый. Без барыбыз да заман продукциясе. Үзебездә заманның плюсларын һәм минусларын йөртәбез. Иң кирәк урында ялгышабыз. Хикмәт Кожановта гына түгел. Аның урынында бүтән кеше утырса да, сине борып кайтарган булыр иде. Хикмәт безнең үзебездә, мәсьәләне зур итеп, дәлилләп куя белмәвебездә. Хәзер инде завод салып кына котылып булмый. Яңа промыселлар өчен өр-яңа шәһәр салырга кирәк. Көн саен Кәлимәттән илле чакрым читкә китеп эшләү, эш вакытыннан тыш ике сәгатьне юлда әрәмгә үткәрү — бу бит хуҗаларча түгел. Ярый, нефтьчеләр моңарчы түзделәр, ди, моннан соң да түзмәсләр бит. Менә, мисал өчен, сине генә алыйк. Идарәдән кайтып киткәннән соң, хуҗалыгыңда ниләр булганны белеп торасыңмы син? Оператор халкының нинди уйлар белән яшәгәнен беләсеңме?

— Белмим шул, — диде Арслан, аның белән килешеп.

— Монысы — мәсьәләнең бер ягы. Икенче кыенлык — операторларның бер тирәдә оешып эшләмәве. Ничек уйлыйсың, алар тамакларын туйганга гына риза булып яшәрләрме? Балаларын музыка мәктәпләрендә, рәсем мәктәпләрендә, ниһаять, спорт мәктәпләрендә укытасылары килмәсмени аларның? Бүген дәшмәгәч тә, иртәгә дә дәшми торырлар дигән сүз түгел әле бу. Текучка күпме синдә? — диде Корбанов кинәт кенә.

— Эшчеләрнең өчтән бер өлеше ел саен алышынып тора.

— Менә шул шул. Эшне яратмаганга гына китми бит алар. Уңайлырак шартлар эзләп китә. Балаларының язмышын уйлап. Үзәк Комитет ни өчен яңа калаларда сәнгать мәктәпләре ачуны көн тәртибенә куйды? Тормыш моны үзе таләп итә. Гади генә бер мисал алыйк. Сиңа проектчы белгеч кирәк. Талантлы зур белгеч. Син аны, алтын таулары вәгъдә итеп, Мәскәүдән чакырып китердең, ди. Хезмәт хакын да артык түләргә вәгъдә бирәсең, квартирның да иң шәбенә урнаштырам, дисең. Ул инде синең белән килешеп тә бетте кебек. Тик азактан, сүз уңаенда гына сорап куя: музыка мәктәбе бармы? Юк! Ә рәсем мәктәбе? Юк! Белгечең синең борыла да китә: ярый, бигайбә, сау булып торыгыз! — ди.

Корбанов трубкасын озак итеп суырды, башын кырын салып уйланып торгач, әйтте:

— Менә шулай, Арслан туган. Производствода син эшеңне комплекслап алып барасың. Завод салу мәсьәләсендә дә комплекслап уйларга кирәк. Шәһәр салсак — заводның кирәклеген тормыш үзе көн тәртибенә китереп куячак.

— Шәһәр салырга рөхсәт итәләрме соң?

— Мин иртәгә обком пленумына китәм. Беренче секретарьга хәлләрне җиткерермен. Алар синең инициативаңны беләләр, эшеңне күзәтеп баралар.

— Чынмы? Кем әйтте икән аларга?

— Сүз иясе белән йөрми. Кем әйтсә дә барыбер түгелмени?

— Гафу итегез. Завод салуга ничек карыйлар?

— Ул хакта сүз бер ел бүе бара инде. Шәһәрнең дә проектын әзерлиләр.

Арсланга кинәт күңелсез булып китте.

— Димәк, минем нервы туздырып йөрүем бушка булып чыкты...

— Нишләп. Проектыңны бракка чыгармаганнардыр бит?

— Юк. Проектны әйбәт диделәр.

— Шулай булгач, тагын ни кирәк? Завод салырга рөхсәт алу белән проектны худка җибәрергә була. Әгәр бик беләсең килсә, серне ачыйм инде, әнә шул синең завод салу идеяң шәһәр салу идеясен дә китереп тудырды. Ләкин син бик тиз сөенергә ашыкма әле, үзең пешергән ботканы үзеңә ашарга туры килмәгәе. Завод салырга килсә бер-ике белгеч килер, төп кадрларны үзеңдә әзерләрсең. Ташчылар, бетончылар, сварщиклар турында бүгеннән үк уйлый башла. Бәлки, кыска сроклы курслар ачарсыз. Партоешма секретаре Вилданов белән киңәш. Кыскасы — белгечләрең әзер булып торсын. Аңладыңмы?

— Аңладым, Нәҗип агай, — диде Арслан һәм, дулкынланудан рәхмәт әйтергә дә онытып, ашыгып урыныннан кузгалды. Ишек янына җиткәч, Корбанов аны кире чакырып алды.

— Бер генә минут. Парткомның отчет-сайлау җыелышын кайчанга билгеләдегез?

— Апрель урталарына дип торабыз.

— Сузасыз, егеткәем.

— Сузылды шул, Нәҗип агай. Мәскәүдән күңелле хәбәр алып кайтып булмасмы дип көткән идек.

— Ярый, хәерле булсын. Сездә җыелыш үткәрүне без Мөстәкыймовка тапшырдык. Аның сиңа әйтәсе сүзе бар бугай, кереп чык әле.

Мөстәкыймов белән сөйләшү Арсланның сөенеченә күләгә төшерде. Камилнең өстендә инәдән-җептән генә чыккан өр-яңа кара костюм, энҗе сипкәндәй елтырап торган синтетик галстук, ак синтетик күлмәк иде. Киенеп йөрүгә бигүк вакыты калмаган Арслан, секретарь белән күрешкән чакта: «Кешеләр кием кайгыртырга да вакыт таба...», — дип уйлап өлгерде.

Мөстәкыймов аңар йомышын әйтергә ашыкмады. Башта бик иркенләп йорт хәлләрен сорашты. Бала-чагалар исән-саумы, Сәгыйдә килен бик сагынмаганмы, янәсе.

«Нигә бик җәелә әле бу, йомшак җәеп катыга салырга җыенамы әллә?» — дип уйлады Арслан, аның бик тырышып кырылган зәңгәрсу йомры иякләренә күз төшереп.

Мөстәкыймов, маңгай турысыннан уймакланып коела башлаган йомшак коңгырт чәчләрен көмеш кысалы тарак белән тарый-тарый:

— Яңалык булырга тора бит әле сезнең идарәдә, Арслан Шәвәлиевич, — диде һәм Арсланның пинжәк якасына кунган бер чүпне алып ташлады.

Алар кара-каршы басып сөйләшәләр иде.

— Нинди яңалык ул?

— Сездә отчет-сайлау җыелышы үткәрәбез.

— Бу бит яңалык түгел, Камил Сәләхович. Җыелышка без күптән әзерләнәбез. Аннары... Минемчә, ул хакта партком секретаре белән сөйләшергә кирәктер.

— Әлбәттә, әлбәттә! Тик, беләсезме, сезнең үзегез белән генә, ип-

тәшләрчә киңәшеп аласы бар иде. Секретаребызны алыштырырга ниятләп торабыз бит.

— Кем белән? Нигә? — диде Арслан, сәерсенеп.

Мөстәкыймов, йөзендәге елмаюны сүндермичә, гап-гади бер хәбәр әйткәндәй:

— Казаннан килгән секретарь белән, — диде.

— Ну-уу? — диде Арслан, баягыдан да битәр гаҗәпләнеп. — Ә нигә партком секретарьларын Казанда әзерлиләрмени?

Мөстәкыймов, ашыгуы сәбәпле саксыз сүз ычкындырганын аңлап, иренен тешләде. Кемгә-кемгә, Арслан Гобәйдуллинга ул әйтер сүзен алдан бик нык уйлап, анда да җаен китереп, иплән кенә әйтергә тиеш иде. Гобәйдуллин — төпле акыллы, үзсүзле кеше. Мөстәкыймовтан яше белән дә өлкәнрәк, дөньяны да күп күргән. Ярты сүздән Мөстәкыймовның тәкъдимен юкка чыгарып, кибәк урынына очырып җибәрүе мөмкин. Җитмәсә, Мәскәүдә килеп чыккан уңышсызлыгы... Аның хәзер күңеле төшкән чагы. Ләкин инде бер әйтеп ычкындыргач, чигенү юлы юк. Мөстәкыймов аңар партия ихтыярын тага да белергә тиеш.

— Шаяртуыгызны аңлыйм, Арслан Шәвәлиевич. Секретарьларны Казанда әзерләмиләр, билгеле. Алар халык арасыннан үсеп чыгалар, — дип, ул баштагы саксызлыгын йомшартырга уйлады.

— Соң шулай булгач? — диде Арслан.

— Безгә аны обком җибәрә.

— Партком секретаре итеп куегыз, дип әйтәмени обком?

— Куегыз дими, эшкә урнаштырыгыз, ди.

— Минә шул шул. Бу — бөтенләй башка мәсьәлә. Сез бит, Камил Сәләхович, бик яхшы беләсез, бездә халык ярата торган секретарь бар.

Мөстәкыймов сүзсез калды. Гобәйдуллинны күндереп булмаячагын ул әнә шул ике авыз сүз алышудан ук аңлап, аны өстәл янына чакырды, утырыйк әле, диде. Моның белән күз бәйләш сукыр тәкә уйнарга ярамый, дип фикер йөртте Мөстәкыймов, — ачыктан-ачык сөйләшсәң генә теләгеңә ирешеп була.

— Сез инде, Арслан Шәвәлиевич, каршы килмәгез. Урнаштыргач, әйбәт урынга урнаштырыйк. Әлеге иптәш — фамилиясе Гәрәйшин аның, Хәким Солтанович — өлкә комитетында инструктор булып эшләгән, кстати, промышленность буенча. Характеристикасы әйбәт. Заманында югары партия мәктәбен бетергән.

— Нигә килә соң ул безгә?

— Тормышка якынрак буласы килә. Казаннан шалтыратып әйттеләр, Кәлимәттә урнаштыра күрегез, сезгә ышанабыз, диделәр. Минем урында, мәсәлән, сез үзегез нишли алган булыр идегез?

— Минме? Мин әйткән булыр идем: килсен, яңа шәһәр белән танышсын, берәр ел рядовой эштә эшләп күрсәтсен, кая куярга икәнен күз күрер, дияр идем.

— Сез һаман шаяртасыз, Арслан Шәвәлиевич.

— Юк, шаяртмыйм. Минем эштә шаярту мөмкин түгел. Горком бездән нефть сорый, обком бездән нефть сорый. Цека шулай ук... Ә ул нефтьне чыгарачак кешеләрне кем тәрбияләргә тиеш? Партоешма түгелмени? Шулай булгач, партком секретаре итеп кемне сайлау мәсьәләсен безнең үзебезгә, нефтьчеләргә калдырыгыз инде.

— Бу сезнең соңгы сүзме?

— Хикмәт минем сүздә түгел. Идарә коммунистлары аны сайламаслар бит. Хәзер инде «остазыбыз», «даһи юлбашчыбыз» дип торган дәвер узды. Һәркем үз башы, үз акылы белән уйлап карый ала. Аңа кем файдалы, кем аның мәнфәгатен күзәтә — шуны сайлый. Гәрәйшин бәлки бик тә әйбәт кешедер, ләкин бит без аны белмибез. Вилданов — безнең үз кешебез, нефтьче-оператордан күтәрелгән партработник.

Кстати, ул да партия мәктәбе бетергән. Эшчеләр телен белә, хуҗалыкны белә, экономия буенча теләсә нинди белгечнең авызын каплый ала. Вилданов — талантлы егет!

— Ә андый талантлы егетләр бер сезгә генә кирәк дип уйлыйсызмыни? Әгәр без аны иң авыр участокка, Зур промыселлар идарәсенә күчерсәк.

— Сез аны теләсә кая күчереп йөртә аласыз. Ләкин үз ихтыярыгызны тагар өчен генә аны бездән тартып алу гаделлек булырмы соң? Минемчә, монда коммунист намусы да исәпкә алынырга тиеш.

Мөстәкыймов тагын сүзсез калды, Гобәйдуллинның тагын бик акыллы итеп мәсьәләне үз файдасына борып куюына кәефе китте. Җиңелүен сиздермәс өчен, папирос алып кабызды, тирән итеп эчкә төтен суырuga, коточкыч арыганлыгын тойды.

Заманында, партиянең шәһәр комитеты секретаре булганга кадәр, Мөстәкыймов лектор булып эшләгән иде. Була иде шундый аудиторияләр, уртак сүз таба алмый аптырыйсың, сәгать ярым лекция сөйләп төшкәнче, көннәр буе таш ваткандай арыйсың. Хәзер дә ул үзен шулайрак хис итте.

— Ярый, иптәш Гобәйдуллин, сүз көрәштермик. Уйлагыз. Иптәшләр белән киңәшегез. Мин иртәгә кадәр көтә алам.

— Юк, Камил Сәләхович, иртәгә калдыруның мәгънәсе юк. Таҗи Вилданов өчен мин теш-тырнагым белән сугышачакмын.

— Туктагыз әле, нигә сез Вилдановка ябышып ятасыз?

— Таҗи минем күзләрем. Кем инде үз ирке белән күзләрен чукып чыгарырга риза булсын?!

— Көч сынашырга телисезме? — Мөстәкыймов сабыр булырга тырышып елмайды. — Ярый алайса, Арслан Шәвәлиевич, әйдәгез, сынашып карыйк. Сайлау үткәрергә мин үзем киләм.

## 5

Золотухин белән очрашу көтелмәгәнчә килеп чыкты.

Арслан үзенең кабинетына килеп, урынбасарларыннан идарә хәлләрен, үзе Мәскәүдә йөргәндә ниләр булганны сораштырырга җыенып кына тора иде, кабинет ишеге бик хәтәр җилләнеп ачылды да атылыпбәрелеп баш инженер килеп керде. Аның түсе качкан, галстугы кыйшайган, пиджак чабулары җилферди һәм ул пиджак эченнән чыгып китәрдәй булып ярсына иде.

— Нәрсә бу?! Бу ниткән безобразие? Без кая барабыз? Нигә безне борыныбыздан тартып йөртәләр? Адым саен этлек! Дәшми дигәч тә, нигә безне аңгырага саныйлар?

— Ни булган, Вадим Сергеевич? Тынычланыгыз әле, утырыгыз, исәнмесез?

— Утырмагыз инде, Арслан Шәвәлиевич. Мине күп утырттылар инде, җитәр! Моның бер чиге булырга тиештер бит? Этлек өстенә этлек! Я миңа бүген үк расчет бирегез, я минем кушканнарым үтәлсен...

— Утырыгыз, — диде Арслан, нык итеп.

Золотухин урындыкны дөбердәтеп аның каршысына килеп утырды. Ул авыр мышный, иреннәре дерелди, күзлек пыялалары елтыр-елтыр килә иде. Кесәсеннән кулъяулыгын тартып алып калку зур маңгаен сөртергә тотынды.

— Я, сөйләгез, ни булган?

— Әдәм әйтеп әдәм ышанмас! Мин йөз егерме станокка заказ бирәм — берләшмәдән яртысын сызып кайтаралар. Алты йөз парафин кыргычына заказ бирәм — яртысын сызып ташлыйлар. Бу ни дигән сүз? Мин юри сорыйммыни аларны? Олы башым белән алдашып язаммыни?

Йөз егерме станок сораганмын икән, димәк, киләсе елга йөз егерме станок кирәк дигән сүз. Кыңгыраулы мәйданы сафка керә, элекке мәйданнарның күпме скважинасына капремонт үткәрәсе бар. Ә алар мәсиңа — заказның яртысын сызып ташлыйлар. Безобразие! Көпә-көндез алдашырга чакыралар. Мин, идарәнең баш инженеры, йөз егерме станок алырга теләсәм, ике мәртәбә артык заказ бирергә тиешмени? Ил буйлап шулай алдаша башласак, кая китә ул аннары...

— Аңладым, Вадим Сергеевич. Борчылмагыз, берләшмә начальнигы Асылгәрәев белән үзем сөйләшермен, сез биргән заказны алырга тырышырбыз. Я, нинди яңалыклар белән сөендерәсез?

— Нинди яңалык белән сөендерик? Авария юк. Капремонттан ике скважина чыкты — фонтан аталар. Тагын икесенә тотындык. Кыңгыраулы Чишмәнең кайбер корылмаларын сала башларга вакыт. Татнефтестрой белән сөйләштем — риза булдылар.

— Менә монысы өчен рәхмәт. Дөрес иткәнсез.

— Рәхмәте торып торсын — завод нишләде? Сез миңа шуны әйтегез.

— Госкомитет үткәрмәде заводны.

Тынычланып җитә язган Золотухин тагын ут кебек кабынып китте:

— Их, Арслан Шәвәлиевич, әйттем мин сезгә, юк белән булашмыйк, эшчеләр кайгысын кайгыртып кына яшик, дидем. Була торган эшмени ул завод!

— Паникага бирелергә иртә, Вадим Сергеевич. Тамчы тама-тама таш яра. Кулыбызда зур власть булмаса да, зур һөнәр бар безнең: нервы боза беләбез. Теңкәләренә тими торып, туктау юк әле. Алар бездән я завод салдырып, я урыныбыздан алып кына котыла алалар.

— Ну, үзегезгә карагыз инде...— Золотухин, кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь алып, каефсез генә өстәлгә салды.

— Нәрсә бу? — диде Арслан.

— Штат кыскарту турында күрсәтмә. Безнең бер инженерны күпсенәләр. Сез, әлбәттә, мине кыскартырсыз дип ышанам.

Золотухин күзлеген салды, уңып беткән аксыл кашларын күтәрде: балаларча беркатлы, чиста зәңгәр күзләр өметсезлек белән идарә башлыгына төбәлделәр. Гобәйдуллин шундук партком секретаренең сүзләрен искә төшерде: «Золотухин — намуслы инженер. Ул арыган, сугышыр көче калмаган. Үн ел буе ирешкәне — вак-төяк». Димәк, аның кычкырынуы энергиясе ташып торганнан түгел, арыганнан, нервысы туздганнан.

Начальникның күңеленнән хәвефле уй узды: «Я хода, ул үзе дә, Золотухин кебек, арып, ярты юлда туктап калыр микәнни?»

— Ни өчен сезне кыскартырга? — диде Арслан, төшенке уйларын куып.

— Каныгызга тоз күп салдым. Җае чыкканда файдаланып калыгыз. Мин дә котылырмын, сезгә дә тынычрак булыр.

Гобәйдуллин аңа төбәп карады. Сүзен өзеп, нык итеп әйтте:

— Минем артык инженерым юк. Йокыгыз туймаган булса, барыгыз, Вадим Сергеевич, салкын су белән башыгызны чылатыгыз да кирәкле эш белән шөгыльләнегез.

Золотухинның тамагына төер утырды. Дулкынлануын идарә начальнигына күрсәтмәс өчен, ул тәрәзәгә таба борылып урамга карап тора башлады. Артык гасабилы булуына ул үзе дә үкенә иде. Күпме күңелсезлеккә очрады ул шуның аркасында, ничәмә-ничә кат тәүбә итте! Юк, ташлый алмый шул гадәтен. Кайнарлык аңар көньяктан йогып кайтты. Мәскәү институтын тәмамлагач, аны Төркмәнстанга, нефть эшенә җибәргәннәр иде. Көньяк кояшыннан каралып, какланып, үз кеше булып китте ул. Бу якларның ихлас күңелле, аз гына гаделсезлеккә дә түзеп тора алмаучан, ярсу табигатьле кешеләрен аңа байтак вакыт хуҗалык исәпләренә өйрәтергә туры килде. Шулардан үзенә дә тынгы-

сызлык, кайнарлык йогып калды. Бәлки ул гомер буена шунда яшәр, зур бәхетен шунда табар иде, ләкин врачлар әйттеләр, сезгә көньякта калырга ярамый, кан басымыгыз югары, һәлак булачаксыз, диделәр. Ул Татарстанга күчте. Икенче Бакуның аяусыз темпы аны үз өермәсенә бөтереп алды — тәмәке төтененә тулган бөркү кабинетлар, өзлексез каулап торган зур эшләр аның ысланган битен агартты, маңгай чәчен койды, әмма кайнарлыгын бетерә алмады. Ул аңлый: хәзер йөрәк заманы түгел, акыл заманы, автомашиналар заманы. Ләкин юк, тыныч кала алмый, аз гына гаделсезлек тә аның җанын айкап, бавырын тамак төбенә менгереп җиткерә шул...

Арслан аягүрә басты.

— Мин хәзер промыселларга китәм. Калганын, Вадим Сергеевич, иртәгә сөйләшербез. Әгәр мәшәкать дип санамасагыз, юл уңаенда шофер Бәхетгәрәевкә генә дәшеп китегезче. Ул кызлар янында әкият сөйләп утыра булыр...

Золотухин, күзлеген кулына тотып, аркасын бөкрәйтеп чыгып китте.

Бер минуттан ишек төбенә күн тужуркалы кара егет мут елмаеп кереп басты:

— Тыңлаем сезне, иптәш начальник!

— Алмачуарың әзерме, Атнабай?

— Әзер, иптәш начальник: солысы ашатылган, суы эчертелгән, көмеш камчым кулымда. Кая тиклем илтергә боерасыз?

— Промыселларга, көне буена чыгабыз. Бензиның җитәрлек булсын, заправкага барып кил.

Арслан үзе белән Тажи Вилдановны алып чыккан арада, Атнабай бензин салып килде. Аның мутланып йомгалаган кысык күзләреннән, калын иренле дәү авызын җыя алмыйча, гел елмаеп сөйләшүеннән идарәдә эшләүче кызлар «тынгы белмәс дала баласының» юлга җыенганын белеп алдылар.

— Әй, копченый колбаса, авызыңны бик җәймә, драндулетыңның тәгәрмәчләре коелып калмасын!

— Кызлар, кызлар, Атнабайга ашъяулык бирегез, машинасының сөякләрен җыеп алып кайтыр, ха-ха-ха!

Кызларның шаяртулары юкка түгел, юл йөрүне ярата иде Атнабай. Үз гомерендә (аңа хәзер егерме җиде яшь — ул инде дөньяда бик күп яшәгән!) берничә һөнәр алмаштырырга өлгергән ул: башта шофер булды, буровойда верховой булды, менә дигән бораулаучы булып җитеште, мастер итәбез дип кенә торганда, кинәт буровой белән исәп-хисапны өзеп, Башкортстанга кайтып китте. Кемдер, үзе белән бергә эшләгән бораулаучы егетләрдән берсе күреп кайткан, «тынгы белмәс дала баласы» филармония артистлары труппасында курайчы булып йөри, кызлардан аңа чәчәк ява, имеш. Тагын бер ел үттеме икән, юкмы — Атнабай янә Кәлимәттә пәйда булды. Бу юлы ул буровойга кайтмаган, иң яраткан эшенә, машина йөртүгә алынган. «Ашыгыч ярдәм» машинасының ачкычын бармагында болгап, кызларга күз кыскалап, елмаеп йөри, чакырган бер җиргә сәгате-минуты белән барып җитә иде. Усал телләр әйттеләр, Атнабай өйләнгән, «сөекле сөяге» аны ташлап, бүтән берәүгә кияүгә чыккан, Кәлимәткә ул хәсрәтен онытырга дип кайткан, имеш. «Сөекле сөяк» турындагы имеш-мимешнең күпмесе дөрес, күпмесе ялган, берәү дә ачык кына әйтә алмады. Әмма егетнең Кәлимәткә япа-ялгыз кайтуы хак иде. Табигатькә гашыйк бу егет өйдә бикләнеп яши алмый, төннәрен больницада, «ашыгыч ярдәм» машинасында дежур торса, көндезләрен елга тугайларына чыгып югала, урманнарда йөри, әллә никткән кәкре-бөкре агач тамырлары җыеп, шуларның барысын кочагы белән өенә ташый иде.

Арслан Яңа промыселлар идарәсендә начальник булып эшли башла-

гач, аны — күптәнге дустын — үзенә шофер итеп чакырды. Бәхетгәрәев бер шарт куйды:

— Арслан Шәвәлиевич, алама бер гадәтем бар. Кызлар күрсәм, күңелем кузгала. Юл буенда тилмереп басып калган кызларны утыртмый китү үлем белән бер миңа. Әгәр буш урынга кызларны утыртып йөртүгә каршы килмәсәгез, биш куллап риза, — диде ул.

Арслан, мыек астыннан көлеп, беравык Атнабайга карап торды. Теге заманнарда, моннан ун ел элек, үзен Бөгелмәдән алып кайткан киң күңелле, шаян табигатьле Атнабай иде бу.

— Ярый, салу гадәтең өстәлмәгән булса, килешәбез, — диде.

Шул көннән Атнабай — идарә машинасында. Көн дими, төн дими, яңгыр дими, буран дими — «алмачуар» әзер, көмеш камчы кулында! Әйт кенә, боер гына!

Начальник белән партком секретаре да киенеп чыктылар. Таза гәүдәле Арслан янында Таҗи чебеш кенә. Идарә башлыгы чатырдатып бер кысып алса, партком секретареның җаны чыгарга тора, шулкадәр дә юка гәүдәле Таҗи Вилданов. Атнабай кайчагында аптырап та калгалый, шундый өтек кенә кешенең авторитеты кай төшенә әләгеп тора икән? Нефтьче-операторлар әйтә, акыл йөртә Таҗины, гәүдә йөртми, диләр.

Юлчылар газикның түренә үк кереп утырдылар.

Атнабай «алмачуарын» бик тиз кузгатып, иң якын юлдан кырга алып чыкты. Һәм, иелә төшеп, чабыш тизлегенә кинәнгән башкорт җайдагы сыман, машинаны тигез асфальт өстеннән җил уйнатып алып китте.

Күгелҗем урман өсләреннән башларын сузган ерак вышкалар, март кояшының күз камаштыргыч яктысыннан балкып утырган көмеш чаңнар, товар парклары, цемент төяп чыккан галәмәт дәү платформалар, челтәр баганалар, чарпылышып беткән электр чыбыклары аның бөтен барлыгын биләп алдылар. Бу басуларга ул моннан ун ел элек кайткан иде. Япа-ялгызы, буш урынга, буш басуга. Кызык, ул чакта да аны шушы романтик табигатьле башкорт егете Атнабай алып кайтты, хәзер дә ул йөртә. Теләге кабул булды егетнең: Арслан — хәзер зур бер предприятиенең хуҗасы — сөенергәме шуңа? Кая ул! Бораулаучы булган чагында җаны тыныч иде аның: буровоеның беләсең дә тормоз тотканны беләсең. Бурмастер чакта да ул бер бригаданың, нибары егерме бер кешесенең язмышы өчен генә кайгыра иде. Ә хәзер аның карамагында өч меңнән артык нефтьче. Заводтагы кебек бер түбә астында гына җыелып яшәми бит әле алар: яртысы — шәһәрдә, яртысы — авылларда. Кирәк чакта җыеп кара син аларны, эшкә чыкмаса — нигә чыкмаганлыгын белеп кара. Аларны укытасы, белемле итәсе, аларның ял вакытларын оештырасы бар. Җитмәсә, партком секретарен алыштырабыз дип торалар. Таҗи кешеләрне белә, эшне белә, бу басуларның һәр сукмагы аңар таныш. Алсалар, үкенечле булачак...

Арсланның кәефе кырылды. Нигә дип әле алар Мөстәкыймов кубызына биергә тиешләр? Нигә дип ул үз ихтыярын өлкә комитеты исеменнән тага? Нигә партия демократиясен боза? Юк, үлсәң үл, Арслан, бирмә Вилдановны...

Каршыда ак таштан салынган ике катлы озын ак бина һәм түбәсенә төрле яклардан бик күп чыбыклар килеп тоташкан диспетчерлык пункты күренде.

Арслан, шоферның җилкәсенә җиңелчә кагылып:

— Туктыйбыз, — диде.

Машинадан башта җиңел сөякле Вилданов сикереп төште, аның артыннан базык гәүдәле Гобәйдуллин ашыкмый гына килеп чыкты.

Промысел бинасы яшел рәшәткә белән уратып алынган. Урта бер җирдә зур парадный капка, капка буенда ук плакат: кара бомба тесле

булып бик дәү нефть тамчысы төшеп килә һәм эре хәрефле язу: «Тукта, укып кит!» дип чакыра иде.

Туктап укыдылар. Плакат хәбәр итә: әгәр минутына бер генә тамчы нефть тамып торса да, елына 230 килограмм сыек ягулык әрәм була.

— Синең эшме? — диде Арслан партком секретарена.

— Идеясе минеке. Плакат акылга гына түгел, хискә дә тәэсир итәргә тиеш. Формасын тапканнар, молодцы!

Капкадан эчкә уздылар. Промысел ихатасының яртысын диярлек яшь алма бакчасы алып тора. Аякларына озын кунычлы резин итекләр кигән, кулларына зур кайчылар тоткан ике хатын-кыз алмагачларның артык чыбыкларын кисеп йөриләр. Зур гына кара күзлек киеп, авыз-борынын марля белән урап куйган резин плащлы кеше пульверизатор белән агачларга агу сиптерә, тузан булып очкан яшел сыекча, кояш нурыннан кабынып, аллы-гөлле төсләр белән балкый, җәйге җылы яңгырдан соң күкне иңләп алган салават күперен хәтерләтә иде.

Арслан адымнарын кызулата төшкән Таҗига яннан кырын күз салып алды. Таҗи канәгать — авыз колак артында. Шулай булмыйча соң! Промыселларны бакчага күмү идеясен ул күтәреп чыкты. Операторлар белән бергә балчыкка батып, алмагач чокырларын казышты, питомниклардан яшь үрентеләрне белеште. Эшчеләр башта мыгырдандылар, дегет чокырында ничек инде алмагач үссен, ни чыкмаса бездән чыга, диделәр. Язын яшь бакча яшел яфраклары белән лепелдәп утыра башлагач, барысы да сөенде, инде менә хәзер аларны кушып торасы да юк, үзләре белеп эшлиләр. «Кешеләрдә дәрт сүнмәсен, инициативаны якларга кирәк, — дип уйлады Арслан. — Кеше табигатькә якынайган саен йомшаграк күңелле була. Юкса нефть тә план, план да нефть»...

— Хезмәтегез җиңел булсын, туганнар!

— Язны башлап җибәрдекме?

Хатын-кызлар яктырып исәнләштеләр. Аларның берсе, яулыгын өчкелләп бәйләгәне — урта яшьләрдәге татар хатыны, икенчесе, тамак астыннан китереп чуар косынка бәйләгәне — сары чәчле рус кызы иде.

— Я, быел алма алырга уйлыйсызмы инде?

— Насыйп булса, исәп юк түгел иде, Арслан Шәвәлиевич.

— Кая куеп бетерерсез икән, бакчагыз зур күренә.

Татар хатыны авызын бөреп елмайды. Рус кызы, оялып-нитеп тормастан, алар каршысына ук килеп басты:

— Алмасы гына булсын, урынын табарбыз! — диде.

Промысел мөдире Сапожниковны аппарат-передатчик янында очраттылар. Торна кебек озын буйлы, мазутка буялып беткән кыска ак тунлы, ике-өч көн инде сакал-мыегы кырылмаган, утыз яшьләр тирәсендәге кырыс чырайлы кеше, аппарат трубкасын әле авызына якын ук китереп, кемгәдер, күренмәгән бер кешегә дәшә, әле трубканы колагы яныннан кул озынлыгы арага куя да тыңлап тора, әнә шул чагында трубкадан, радио сөйләгән төсле, көчле калын тавыш кычкыра башлый:

— Басым аз. Батырма насос төшереп ятабыз. Сиртмәле дисезме? Юк, ул бармас...

Читтән килгән кеше монда сүзнең ни турында барганын да аңламас иде. Әйтерсең лә, бөтенләй башка дөньядан, нindидер күз күрмәс патшалыктан килгән кешеләр үзләре генә белгән телдә, җир астының буйсынмас көчләрен, тылсымлы сүзләр белән буйсындырып, кешегә хезмәт иттерергә телиләр.

Сапожников кунаклар белән баш кагып кына исәнләште. Буш кулы белән, утырыгыз дип, ишарә ясады — сүзеннән туктамады. Бөтен промыселның хәлләре турында төрле участоклардан хәбәр алгач кына, аппаратын калдырып, кунаклар янына килде, бөрәм-бөрәм күрешеп чыкты.

— Нинди яңалыклар белән сөендерәсез, Андрей Иванович?

Яңа начальникның кыскалык яратуына күнеккәннәр иде инде. Сапожников та кергән генә әйтеп бирде:

— Яңалык шул: квартал планын тутыра яздык. «805» белән «607» ремонттан чыктылар. Сиртмәләләр нормальный эшли. Ә менә батырма насослар...

— Нефть түгү дә булгалаган икән.

— Булды бераз...

— Яндырасызмы?

— Яндырмый, кая куясың аны, түгелгән нефтьне колхозларга сатып булмый бит, Арслан Шәвәлиевич.

Сапожников, идарә начальнигының кашлары җыерылуын, сабыр йөзеннән соры күләгә узып китүен күреп, тынып калды.

Тажи промысел парторгын эзләп, кызыл почмакка китте. Атнабай кызлар янына «теш агартырга», мутланырга китеп барды. Промысел мөдире белән идарә начальнигы, үз эшләре турында сөйләшә-сөйләшә, товар паркыннан әйләнеп кайттылар.

Сапожников Арсланны төшке ашны бергә ашыйк дип чакырган иде, тегесе әдәп белән генә баш тартты, барасы, карыйсы урыннары күп иде әле.

Икенче промысел мөдире Борис Смельчанский начальствоны капка төбенә үк чыгып каршы алды. Гобәйдуллинның промыселларны карап йөрүен ул идарәгә шалтыратып белгән иде. Кояш күрмәгән ак чырайлы, галстуклы бу кеше үз-үзен тотышы белән дә, чиста-пөхтә киенүе белән дә Сапожниковтан бик нык аерылып тора иде. Ул бер нәрсәдән дә зарланмады, идарәдән бернинди ярдәм дә сорамады, артистларныкы сыман тигез салмак тавыш белән, үзен ифрат дәрәҗәдә тыныч һәм бәйсез тотып, сораган бер сорауга төгәл җаваплар биреп торды.

Саубуллашып китеп баргач, Арслан кинәт Тажидан сорап куйды:

— Нинди рәк кеше Смельчанский? Өч ел эшлим инде, аңлый алганым юк.

— Минемчә, ул бик чак кеше. Партком белән дәгъвага керми. Җыелышларда берәүне дә тәнкыйтьләми.

— Операторлар белән мөгамәләсе ничек?

— Начар димәс идем. Һәрхәлдә, аңардан зарланмыйлар. Узган айда ин күп нефтьне ул бирде бит.

— Аңысы шулай... ләкин баш геолог аңардан бигүк канәгать түгел.

— Нигә?

— Байпас белән шаяра икән. Скважиналарның режимын боза. Ремонтка да исе китми: хәрәкәтсез фонды арта бара. Ремонт бригадаларында югары белемле бер генә инженеры да юк, тәкъдим итәм — алмый.

— Сәер кеше... — Тажи тамак астын кашып куйды. — Кичә аның өстеннән хатыны жалу белән килгән иде.

Арслан сагая калды.

— Хатын-кыз белән шаяра мәллә?

— Ул кадәресен әйтү кыен. Курортка үзе генә китәргә йөри, ди.

— Соң... китсә?

— Биш ел буена япа-ялгызы йөри.

— Кайда ял итә?

— Кырымда...

— Карале, Тажи, — диде Арслан, беркавым дәшми баргач. — Кешенең гаилә тормышына тыгылу уңайсыз, ләкин Смельчанскийның участоктагы эшен партбюрода бер тыңлап аласыз мәллә? Үзең беләсең, фонтаннар заманы узып бара, тиешенчә нефть алыйк, тиешенчә план тутырыйк дисәк, скважиналарны күзгә кебек тотарга тиешле без. Ә ул нигәдер ремонтны күп ясата. Ничек чыгара ул нефтьне? Моннан бер генә нәтиҗә ясап була: димәк, гадел юл белән чыгармый.

— Әйдә, бер участогына керәбез, — диде Тажи. — Башта үз күзебез белән күреп ышаныйк. Аннары бюрода отчетын куйсаң да булыр.

— Икенче участокка бор, — диде Арслан, Атнабайга карамый гына.

Участок өе буш булып чыкты. Почмактагы бүлмәдә, аппаратлар янында башына берет, өстенә зәңгәр халат кигән яшь бер кыз гына утыра иде. Арслан ишекне ачып карау белән аппаратчы кыз дөбердәп урыныннан торды, кычкырып сөйләп торган микрофонны басты.

— Сөйләшегез, сөйләш, — диде Арслан, кулы белән ишарә ясап.

Кыз яңадан урынына барып утырды. Яңадан микрофонның кычкырып сөйләгән тавышы ишетелде.

— Гөлниса, акыллым, ишетәсеңме? Участок начальнигына, Габдуллинга әйт әле...

— Апа, ни... Габдуллин юк бит монда. Килмәде ул бүген.

Микрофоннан ирләрчә бик хәтәр сүгенгән тавыш ишетелде. Диспетчер кыз микрофон чыбыгын тиз генә өзде дә, кып-кызыл булып кызарып, Арсланга урын тәкъдим итә башлады.

— Гафу итегез. Арслан Шәвәлиевич. Ни... утырыгыз.

— Борчылмагыз, Гөлниса. Кем белән сөйләштегез әле сез?

— Өлкән оператор... Кыз сөйләшүченең кем икәнен әйтергә бер генә мәлгә икеләнеп алды да: — Фәйрүзә апа белән,— диде.

— Диярова беләнме?

— Әйе, — диде Гөлниса, куркып.

— Нигә бик тузына Фәйрүзә апаң?

— Аптырадык инде, Арслан Шәвәлиевич... Промыселга автомат чыгырлар куймый интектерәләр. Участок начальнигы Габдуллин абый чатыр чаба, автомат чыгыр складта да юк икән. Шуны эзләп үзәк складка китте.

Диспетчыр кыз яныннан чыккач, Арслан Тажига:

— Участок начальнигы Габдуллинны беләсеңме? — диде.

— Нигә белмәскә! Узган ел гына техникум бетереп килде бит. Кайнар егет. Комсомолец.

— Нигә соң Гөлниса аны абый ди?

— Хөрмәт итеп әйтүедер. Габдуллин операторларының хәлен җиңеләйтү өчен складтан складка чаба.

— Фәйрүзә апа кайсы яктарак эшли? Барып булыр микән анда?

— Анысын инде Атнабайдан сорарга кирәк.

Атнабай йөзен чытып кына барырга риза булды. Юллар монда чоңгыл-чоңгыл булып казылып беткән иде. Бер тын баргач, трактор эзеннән урман эченә кереп киттеләр. Атнабай партком секретаре белән идарә начальнигының, ат өстендә чапкандай, утырган җирләреннән сикереп-сикереп китүләрен тоеп, үзалдына елмаеп бара башлады:

— Ни булды сиңа, Атнабай, әллә син безнең башны тишәргә уйлыйсыңмы? — диде Арслан, ачусыз гына.

— Юлмыни бу! Ресурлар сынса күрерсез әле менә.

— Сукранма, Атнабай. Мин сине аена бер генә мәртәбә мондый юллардан йөртәм. Бер айдан «Волга» кайтачак. Кызлар йөртергә була сиңа. Ни дисәң дә, «Волга» бу караңгы «Газик» түгел инде. Кругом пыяла — ялт итеп тора.

— Аның монысы да кара көнгә ярап тора. Кызлар утыртып урманга чәчәк җыярга кереп чыгасың. «Волга» нәрсә ул! Аның белән опера театрына гына чабарга ярый.

— Менә «Кәлимәт — Казан» трассасы салынып бетсә, гел шулай итәрбез. Опералarга, тантаналы җыелышларга йөрербез. Бераз гына түз инде, — диде Арслан, шаяртып.

Урман аланында, яфраксыз язгы шәрә агачлар арасында, көмеш буявы белән ялтырап ак чаң — мерник күренде. Атнабай машинасын урман читенә туктатты.

Арслан трап-мерниктан башлап сузылган кара торбага тотынып беркавым тыңлап торды. Торбадан гөжләп нефть акканы ишетелә иде. Арслан, буровойда эшләп йөргән чакларын искә төшереп: «Менә ул җирнең кан тамыры, Тажи дус!» — димәкче иде, мерник янында кулына озын саплы щетка тоткан хатын-кызны күреп, әйтми калды. Әлеге хатын башына шакмаклы шәл бөркәнгән, телогрейкасының якаларын чишеп җибәргән дә, ирләрчә нык кул белән, селтәнеп-селтәнеп, көмеш чаңны юып ята, күрәсең, күптән түгел генә мерниктан нефть ташыган булган. Урман аланына туктаган машинаны һәм торба буенда сөйләшеп торган начальствоны күреп, ул тизрәк мерник артына шылды.

— Кая качасыз, чыгыгыз монда! — диде Арслан. — Гөнаһыгызны яшермәкче буласызмы?

Оператор хатын, кулын чүпрәккә сөртә-сөртә, мерник артыннан килеп чыкты. Ул инде, щеткасын куеп калдырган, кояшта янган һәм тырышып эшләүдән алсуланып киткән түгәрәк йөзенә беркадәр каушау бәреп чыккан, кара күзләре бимазалы елтырыйлар иде.

— Нефть түктеңме? — диде Арслан, кырыс кына һәм каршысына атлаган хатынның Фәйрүзә апасы икәнен танып, тотлыгыбрак калды. Ике арада килеп туган уңайсыз тынлыкны бетерергә теләп булса кирәк, Тажи оператор хатын белән күрешергә ашыкты:

— Исәнлекме, Фәйрүзә апа?

— Ару гына әле, Таҗетдин.

Арслан да апасына кулын сузды. Кулының дегеткә буялуын, дөресрәге апасы аның кулын юри буявын аңлап, иренен кысты.

— Я, сөйлә, ни хәлләр? — диде ул, тонык кына.

— Үзеңә барырга тора идем әле, начальник энем. Юкса, бик эрәеп киттең. Мәскәү юлыннан кайтып кермисең. Промыселларны оныттың!

— Йомыш төштеме? — диде Арслан, сүзне зурга җибәрмәс өчен. Тажи алдында ул апасының ярсынып китүен теләми иде.

— Йомыш төште, — диде Фәйрүзә, күзләрен уйнатып. — Үгәнләп алып килмәкче идем сине.

— Ну, ну, чамалап! — диде Арслан һәм партком секретаре ягына күз сирпеп алды. Тажи, ике туган арасындагы сүзне тыңлап тормас өчен, чыгыр будкасына таба китеп барды. Фәйрүзә аны күзләре белән озатып калды да:

— Кайчан бирәсез сораганны? Өегезгә барып тавыш куптарганны көтәсезме? — дип кутәрелеп бәрелде. — Кайчан акылга өйрәтәсез ул Смельчанскийны?

— Ну, нәрсә бар, нәрсә?! Аңлатып сөйлә, — диде Арслан.

— Әдәм рәтле әйткәнне аңламыйсызмыни сез! Җыландай телемне чыгарып әйттем, автомат чыгыр куйсыннар дидем. Көне буена кул чыгыры әйләндереп куллар кабарып бетә. Нефть түгелсә — оператор! Скважина туктаса — оператор! Бишенче разрядлы башым белән дүрт скважина карап йөрим. Автомат куйсагыз, унны карар идем, уникене.

— Багапалар утыртылган бит инде, чыгыры да булыр.

Сүрелә башлаган Фәйрүзәне янә котыртып җибәрергә шул сүз җитә калды.

— Багана! Нәрсә ул багана — начальник кебек кукыраеп утыра бирә. Минем өчен чыгыр әйләндерми. Сезгә нәрсә — план тула, премия килә...

— Планы да бит тулмый әле аның, апа.

— Авызың белән кош тотып йөрсәң тулмас ул, энем, — диде Фәйрүзә, юашлана төшеп. — Усаллык житми синдә. Синең урыныңда мин булсаммы, мин булсам, синең ул Смельчанскийларыңа оператор халкының маңгай тире белән шаярырга ирек куймас идем мин...

Арслан, апасы белән күңеленнән килешсә дә, теләгенне үтәрбез, дип әйтергә ашыкмады. Коры вәгъдә белән генә эш барып чыкмаячак,

икенче промыселны бүгеннән үк махсус контроль астына алырга кирәк булыр.

Фәйрүзә белән уңайсызланып кына саубуллашты да машина янына китеп барды. Тажи ике туган арасында зур сүз булганны Арсланның чырае карангылануыдан үк аңлады.

Күкне болыт каплый башлады. Сизелерлек суытты. Эрегән җир дымы, машина җиле белән кушылып, ачык тәрәзә аша эчкә үтеп керә иде.

— Өченче промыселга керәбезме? — диде Атнабай, урманны чыккач.

Арслан өчен Тажи җавап бирде:

— Анда эшләр түзәрлек. Егетләр нык анда, каты куллы. Безнең күрсәтмәләрдән башка да ерып чыгарлар, — диде Вилданов, елмаеп. — Сез Мәскәүдә чакта барган идем әле мин аларга.

— Нишләдегез?

— Парторглары белән сөйләштем. Сессияләр җитә бит, кичке техникумда, урта мәктәптә укучыларны имтиханга әзерли башлыйсы бар. Сменаларны җайлап яталар. Кыенга туры киләчәк аларга. Булдыра алсак, ярдәм итәсе иде.

Арслан үзе янында бәләкәй генә булып, башын пальто якасына яшеребрәк утырган Тажига сыный төшеп карады. Машина тәрәзәсеннән бәреп кергән җил юка пальто гына кигән Тажины да туңдыра бугай, аның борыны зәңгәрләнгән, каядыр еракка төбәлгән күзләре малахай бүрек астыннан елтырап күренә. Ихлас күңелле бу кешене аңардан алырлар микәнни? Шул сорау ничә тапкыр инде аның күңеленә килде. Әллә Мөстәкыймов әйткәнне аңа сиздереп куяргамы? Отчет докладына ныграк әзерләнер. Арслан берничә мәртәбә әйтәм-әйтәм дип талпынды, ләкин ул уеннан шундук кире кайтты. Юк, алай әйбәт булмас. Коммунистлар ничек тели, шулай эшләсеннәр. Акыллары булса, Вилдановны җибәрмәс өчен сугышырга тиешләр алар...

Завод салынырга тиешле урында машинадан төштеләр. Әле кары эремәгән зур гына мәйдан дүрт ягына бетон багана утыртылып, бүлеп алынган, кар астыннан чыгып калган былтыргы әремнәр, алабута сабаклары язгы җилдән чайкалалар, кар өстен чуарлаган күн итек эзләре монда алардан башка да кемнәрнеңдер килеп йөрүен әйтеп тора иде.

Сүзсез генә бетон баганалар яныннан урап кайттылар, сүзсез генә машинага утырдылар. Аларның кичерешләрен аңлаган Атнабай бер генә шаян сүз дә әйтмәде, руле өстенә ятып, машинаны куды.

Юл чатында бер төркем операторлар җыелып тора иде. Арслан машинаны туктатырга кушты. Төштеләр. Җыелып торучылар туңганнар, көчәя башлаган җилгә яннарын куеп, брезент бияләйләрен шапшоп бәреп, туктаусыз таптаналар, яшьрәкләре бер-берсенең аркасына шапылдатып сугып алалар иде.

Идарә башлыгы белән партком секретарен тыенкы гына каршыладылар. Теләр-теләмәс кенә исәнләштеләр. Зур күн итекле, шадра битле абзый идарә начальнигына йөнтәс кашлары астыннан усал итеп карап алды. Сезнең эш җайлы, янәсе, машина үз кулыгызда, утырдың — чыктың, ә менә без сигез сәгать буена җил оясында йөрдек, арка шыбыр су, машинаның безне алмага килергә исәбендә дә юк әле.

— Нәрсә, иптәшләр, вахта машинасы көтәбезме? — диде Арслан, сүз башлау өчен.

— Юк, вертолет көтәбез, — диде бер егет, авыз ерып.

— Начальство аэропорт салдыра икән дип ишеттек, — диде икенчесе.

Аны шундук күтәреп алдылар.

— Кеше җанын эт җанына да күрмиләр!

— Кайчан бетә инде бу тәртипсезлек?!

— Беркайчан да бетәсе юк аның! — диде аякларын киң аерып баскан шадра оператор һәм катлы-катлы итеп сүгенеп ташлады.

Арслан әшәке сүзне күтәрә алмый иде.

— Сүгенмәвегезне сорыйм, — диде Вилданов, аның ул гадәтен белгәнгә күрә.

Шадра оператор күзләрен кыса төште, элеккесеннән дә битәр күтәрелеп бәрелде:

— Каян килгән нәфис колаклы чиновниклар! Ишетәсегез килмәсә, вакытында транспорт бирегез. Чыккансыз бит әнә киерелеп утырып.

— Әйтеп бетерегез, — диде Арслан.

— Нәрсәсен әйтәсең аның! Нәрсәсен?! Эш булса — рабочий класс!! Сүзләре дә табылып тора: галиҗәнап! Материаль байлык тудыручы! Җәмгыятьнең терәге! Рәхәте — түрәләргә! Коттеҗы да машинасы, курорты да дачасы! Кайчан бетәр бу гаделсезлек?

Кинәт бик тын булып калды.

Эшчеләр ни буласын көтеп, идарә начальнигына төбәлделәр. Арслан ашыкмый гына шадра оператор янына килде.

— Мин сезне аңлыйм. Әгәр бар да житешле булса, сез дә, мин дә монда басып тормас идек. — Ул кисәк кенә Атнабайга дәште, тегесе ашыгып машинадан җиргә сикерде. — Иптәш Бәхетгәрәев, машинага ун кеше сыямы?

— Автоинспекция бәйләнмәсә, сыя, иптәш начальник.

— Анысы өчен мин җавап бирәм. Эшчеләрне хәзер үк шәһәргә илтеп куй!

Беренче рейска олырак яшьтәгеләр утырдылар. Атнабай, бәйге көтеп зарыккан чаптар кебек, машинаны бик хәтәр кузгатып алды да әллә ни арада күздән дә югалды. Зур бер җәнҗал чыгасын көтеп, шул тамашага әзерләнгән ике егет, дәгъваның шулай тиз бетүенә риза булмагандай, сүзсез калдылар. Инде ярсуы басыла башлаган шадра оператор начальство күзеннән читкәрәк китүне кулай күрде...

Бәхетгәрәевнең житез машинасы операторларны икенче рейска алып киткәннән соң да әле вахта машинасы — өстен брезент белән бөркәгән грузотакси — егерме минутлар чамасы соңлап килде.

Өстенә күн тужурка кигән, машина приборлары янына ялангач актрисалар ябыштырган, «сулагай» йөрергә гадәтләнгән Дугинцев үзен көтеп торучыларның бүген нигәдер икәү генә булуларына аптырап, машинасыннан төште. Көтелмәгән хәвеф барын бавыры белән сизде ул. Каршысына ашыгып килгән ике начальниктан котылу өчен, күңеленнән сылтау эзли башлады.

— Путевка! — диде Гобәйдуллин, бер генә сүз белән.

Шофер тужурка кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарып бирде. Арслан путевканы бик җентекләп карады.

— Төп-төгәл сәгать өчкә килеп җитәргә тиеш идегезме?

— Мин бит, иптәш начальник... — дип аклана башлаган иде, Арслан аны тагын ярты сүздә өзде:

— Мин сорыйм: өчтә килеп җитәргә тиеш идегезме?

— Өчтә, иптәш начальник...

— Хәзер ничә? Ике минуттан биш туламы?

— Мин бит, иптәш начальник...

— Сез ике сәгатькә кичегеп килдегез. Хәзер кайтып китә аласыз.

— Ә сез кайтмыйсызмыни? — диде Дугинцев. Ул тагын акланырга тотынмакчы иде, Арслан кырт кына кисеп:

— Сүз бетте. Юлыңда бул! — диде.

Дугинцев лап-лоп атлап, машинасы янына барды, ишекне ачкан чакта әллә ничек таеп, егыла язып калды, ашыгып кабинасына утырды, машинасын үкертеп китеп барды.

Матур башланган көннең шулай күңелсез бетүе Арсланның да, парторг Вилдановның да кәефен алган, шушы хәлендә аларның шәһәргә кайтып керәселәре килми, күңелдәгене бераз гына булса да бушатасы килә иде. Аннары әле алар бүген көне буена тамакларына да ашамаганнар иде.

— Әллә берәр урман аланына алып керәсеңме? — диде Арслан, эшчеләрне шәһәргә илтеп кайткан Атнабайга карап.

Шоферның җилләр кискән кара-кучкыл чибәр йөзенә берьюлы ике кояш чыкты. Андый сүзне Атнабайга гына әйт инде. Урман аланы дигәндә, ул җанын ярып бирергә әзер.

— Була ул, Арслан Шәвәлиевич. Аланның иң матурын, иң яктысын табам мин сезгә.

Һәм менә Атнабайның «алмачуары» язгы урман аланында. Биредә кар күп әле, тирә-як, каеннар чуарлыгы белән дә кушылып, ап-ак булып күренә, күзләрне әлҗе-мәлҗе китерә. Атнабай машинасыннан брезент алып, кар өстенә җәйде. Бер читтәрәк карны чистартып, таган асты, учак ягып, чәй кайнатырга куйды, бәрәңге күмде.

Арслан, тезләрен кочаклап, утка карап утыра, ә Тажи — аңар күпме генә урын кирәк, — брезент өстенә бөтенләй сузылып ятып, бик тәмләп тәмәке тарта иде.

— Ну, Атнабай, яшерми генә әйт әле: «скорый» да эшләү шәпме, идарә машинасындамы? — диде Тажи, бүген сикерткән казылмаларны исенә төшереп.

— О-о! Сез юкка көләсез, Тажи абый. «Ашыгыч ярдәм» хәтәр шәп ярдәм ул. Төн. Бөтен кеше йоклый, син уяу. Бер кешенең бер кайгысы юк, син бүген тагын кем авырып китәр икән дип ут йотып утырасың. Ул гынамы! Миңа өч мәртәбә кендек әбисе, ике мәртәбә врач-акушерка булырга туры килде. Башыңа төшкәч, башмакчы буласың, ди, мин дә өйрәнеп алдым ул эшкә. Үзегез беләсегез, ул якка, хатын-кыз мәсьәләсенә, батырлык бар минем, ул-бу булмагае дип куркып тормаем. Авыруны бит аны, ягъни йөкле еңгәйне шәһәрдән генә түгел, ерак авыллардан да алып кайтырга туры килә. Кайчагында янында врач та булмый. Йөкле еңгәй ул сиңа идарә конторасы түгел, — диде Атнабай, Арслан Гобәйдуллинга төрттереп. — Анда, агаем, бүген вакыт юк, иртәгә килерсез, иртәгә вакытым юк, берсекөнгә килерсез дип кире борып ебәреп булмай. Яшь гражданин дөньяга килергә тели икән, килә инде ул, синнән дә, миннән дә рөхсәт сорамай, кәгазь подписать иткәнне дә көтеп тормай, тупырдап кына килә. Бер вакытны шулай утыз чакрымдагы бер авылга ебәрделәр үземне. Төн. Дөнья үлеп йоклый. «Алмачуар» җан кисәгемне чабышка барган кебек куып, ухылдап барып кердем: кан эчендә ята йөкле еңгәй, акушерка дигәнебез, унҗиде яшьлек кыз, мәктәпне бетереп кенә кайткан, бала табып карамаган үзе, таптырып та карамаган, менә шул унҗиде яшьлек яшел кыз йөкле еңгәй бала тапкан чакта кендеген ашыгыбрак тарткан да, кан киткән. Алып чыктым боларны юлга, акушерка кызны да, еңгәйнең ирен дә машинага утыртып алып чыктым, и куам, күзгә ак-кара күренмәй, изге пигамбәр Мөхәммәт Галиәссәламнәрне исемә төшерәм, ходаем, мин әйтәм, түз, еңгәм, түз, җитәбез, җитәбез, шулай дөнья җан-фәрман чабып, Кәлимәткә җитеп киләдерпек, юл өстендә үк ап-ак бер нәрсә ята. Тормозга бастым, туктарга итенәм, күреп алдым — бер капчык он. Калада ипи бетеп торган чак, шәп булды әле бу, дим, төшеп алырга да, күтәреп машинага салырга гына бит инде, квартир хуҗасы төче коймак ашатып кына яткырасы; агаем, юк, күңел тартыша, алма, ди, шайтан котырта, ал, ди. Җиңдем шайтан иблисне, туктап җитмәдем, тагын полный ход бирдем дә чаптым Кәлимәткә. Китереп больницага

тапшырдым, карадылар, аһ иттеләр, уколлар да кададылар, үзләре белгән әллә ниткән әкәмәтләрне кыландырдылар. Аңына килде еңгәй, икенче көнне сөйләшәләр, ак халатлы докторларым, могжиза, могжиза, диләр. Тагын өч кенә минут соңга калса, үләсе икән, диләр. Ә минем чәч төпләрем чымыр-чымыр килә: я ходаем, изге пигамбәр Мөхәммәт Галиәссәлам, мин аны өч кенә минутка соңгарып китерсәм, йөкле еңгәй вәссәлам буласы икән. Онны алмаенча дөрес эшләгәнмен...

Икенче көнне тагын шул юлдан үтәргә туры килде. Бу юлы туктаттым «алмачуарны», төшеп карадым, капчык юк, онны алып киткәннәр, бәлкем, ул он да булмагандыр, бәлкем, шикәр булгандыр. Мина әлеге мәде ул, бүтән берәүгә эләкте, мин аңа үкенмәем, аның караве йөкле еңгәм исән калды...

Атнабай сүзеннән туктап, учакны рәтләде, чыбык белән кәшәләп, бер бәрәңгене тартып чыгарды, бәрәңге инде бер ягыннан күмерләнгән, икенче ягыннан пешмәгән иде әле, тагын иплэп кенә күмеп куйгач, үзеннән тагын нидер сөйләүне көтеп, аның авызына карап утырган Арслан белән Тажига елмаеп куйды да, гадәтенчә, көйлерәк тавыш белән, ашыкмый гына сөйләп алып китте:

— Йөкле еңгәйләр генә түгел, үзем дә ике мәртәбә әҗәл авызыннан калдым. Шулай бервакыт Иске Кәлимәт ягыннан авыру бер картны алып кайтам. Яман эшәке тайгак бозлавык. Карасам — каршыга әкәмәт дәү йөк машинасы килә. Күреп торам — минем өскә шуыша бу. Машинаны күпер читенә кыса барам, кыса барам, теге аның саен минем өскә, арада нибары ярты метр калып бара. Тая теге имансыз, үкереп минем өскә килә. Чытырдатып күземне йомам, беттек, мин әйтәм! Сизәм, нидер чытырдады, машина күпер өстеннән очып, лапылдап җиргә төшеп утырды. Айнып киттем. Карыйм — баш исән, гәүдә исән, муеньмда — бәләкәй бала. Машинадан чыктым, машинаның ян канаты яньчелгән, арткы ишеге ачылып киткән, урыныннан кыл да кыймылдый алмый яткан авыру карт, шуышып, носилкадан урамга чыгып бара...

— Ну-уу? — диде Тажи, муенын сузып. — Каян килә диген кешегә үлем алдыннан шундый көч?

— Мин дә аптыраем аңа, — дип, Атнабай башын чайкап куйды. — Җан иясе тереклек итәргә шул тиклем тырыша, инде күзен йома, инде соңгы сулышын ала дисең, әз генә ярдәм кулы суздынмы, тагын тернәкләнеп китә. Сез әйтәсегез, ничек син анда, «ашыгыч ярдәм» машинасында эшләдең, дисегез. Әнә шул аз гына булса да ярдәмем тимәсме дип эшләдем. Ату берәр төн йөрәге минем урында утырып торса, көн үтсенгә, яки акча килсенгә йөри башласа, нәмә була ул аннары. Кеше машина түгел бит, ватылды, иртәгә төзәтермен, дип калдырып булмый аны.

«Шулай шул, — дип күңеленнән килеште Тажи Вилданов. — Кешеләр белән эшләүнең бөтен авырлыгы да шунда шул ул...»

## 7

Вилданов Девон урамы чатында машинадан төште. Арслан саубуллашкан чакта үз итеп әйтте:

— Тажи дус, автотранспорт конторасыннан белешә алмассыңмы, Дугинцев нигә соңгарып килде икән? Әгәр инде вакытың булмаса, минем урынбасар Заһитзадәгә булса да әйтеп куйчы. Дугинцев сулагай йөргән булса, җәзасыз калдырырга ярамый аны. Күрдеңме, эшчеләр ничек ярсыналар...

Вилданов, риза икәнлеген белдереп, баш какты.

— Үзем дә тикшергән булыр идем, әни авырып тора минем, бүген

кич эниләргә барып кайтырбыз дигән идем. Сагыйдә тәгәл кайтып житәргә кушты, — диде Арслан, гафу үтенгән сыман.

— Борчылма, Арслан Шәвәлиевич, жиренә житкерермен.

Вилданов машина чаттан борылганчы баскан жиреннән кузгалмый карап торды, аннары ашыкмый гына урам буйлап китте.

Кичке шәһәр үз тормышы белән яши — тәрәзәләрдә утлар яна, каяндыр музыка ишетелә. Көннәр жылына башлаганмы — халык урамга сибелгән. Шаулап сөйләшәләр, көлешәләр, төркем-төркем булып яшьләр узып китәләр. Тажи базар капкасы төбендә бер төркем малайның күгәрченнәр турында бәхәсләшеп торганнарын ишетте. Элек Кәлимәттә күгәрчен юк иде. Димәк, Кәлимәт чын шәһәргә әйләнеп бара — күгәрчен нияләшү шуның билгесе инде ул. Әнә биш катлы яңа йорт өлгерә. Тәрәзә саен кәкре торба тыгып, урам якка чыгарып куйганнар, торбалардан төтен ургый. Бөтен өй тәрәзә-авызларына трубка кабып, тәмәке төтәтеп утыра төсле. Аның белән янәшә икенче бер йортның стеналарын өяләр. Күтәрү кранында прожектор яна, кран муенын борган чакта, прожектор уты каршы яктагы биш катлы йортның стенасына килеп төшә һәм бик дәү күләгә бөтен урамны иңләп, әкрен генә шуышып уза, икенче бер йортның күләгәсе белән барып кушыла...

Кәлимәт бик якын Тажига. Әллә яңалыгы, әллә яшьләрнең күплеге — аны гел дулкынландырып тора. Ихтимал, ул хәзер иске шәһәрдә яши дә алмас иде. Менә шушы урам тутырып барган егетләрдә, әнә шул күгәрчен туйдырган малайларда, күтәрү кранының түбәсендә янган прожектор утларында аның да яшьлеге бар. Ул яңа каланы, тынгысыз таш каланы Тажиның, Арсланның хыяллары, өметләре юктан бар иттеләр. Борынгы художниклар жиргә чүгеп беткән салам түбәле мужик йортларыннан гуманизм эзләгәннәр, бер якка янтайган сыңар тәрәзәле йорт аларның күңелләрен нечкәртеп, күзләреннән яшь китерә алган. Хәзерге яшьләрне андый эвеш-түеш каралтылар белән шаккатыра алмыйсың. Яңага, яктыга, биеккә омтылалар алар. Һәр заманның үз зәвыгы, үз омтылышлары...

Тажи уйлары белән мавыгып ишетми калды, аңар кемдер сәлам биреп китте. Бераздан гына аңына барып житте: ул бит исәнләшүчегә жавап бирмәде. Бу аның өчен бик сәер бер кыргыйлык иде. Кире борылды. Нәкъ шул мизгелдә сәлам бирүче егет тә борылып карады. Беренче промыселның операторы Суфиев икән.

— Мәхмүт! — дип дәште парторг.

— Исәнмесез, абый! — Мәхмүт кире борылып килде. — Дәшми киткәч, әллә сез миңа ачуланасызмы дип торам.

— Нигә ачуланыйм икән. Ачуланырлык эш эшләмәгәнсеңдер бит?

Суфиев кинәт кызарды, борынын тартып куйды, аның сөрмәле зур күзләрендә каушау чагылды: алар тынычсызланып елтырыйлар иде. Шуны парторг та сизгәнне аңлап, Мәхмүт тагын да ныграк каушады, кинәт башыннан кепкасын йолкып алып, маңгаена бәреп чыккан тирне сөртергә тотынды.

Мәхмүт унынчыны бетергәннән соң промыселга килеп, әйләнеп, бик тиз күзгә күренә башлаган оператор иде. Сөйләшү сәләте булганга, Тажи аны агитаторлык эшенә тарта, үстерергә тырыша иде. Шушы арада аны промыселның башлангыч партоешмасында партиягә кабул итәргә тиешләр иде. Егетнең һич көтмәгәндә каушавын күреп, Тажи үзе дә уңайсызланып калды.

— Нәрсә, Мәхмүт, әллә берәр күңелсезлек килеп чыктымы?

— И, әйтмә инде, Тажи абый...

— Нишләп? Әллә алмадыలармы?

— Әй, син лаеклы түгел, диләр. Коммунист исемен пычратасың, — диләр.

— Ни булды соң?

— Вэсилэ белэн аерылдык бит.
— Ни булды? — диде Тажи, аптырап. — Бик матур яши идегез бит әле.
— Эни карчык белэн тыныша алмадылар.
— Э син ике бозауга кибэк аера белмәдеңме?
— Белмэдем шул...
— Бэлки, сэбэбе ул түгелдер? Бэлки, син хатыныңны яратмыйсыңдыр?
— Нишләп яратмыйм ди!.. — Мәхмүт партком секретаре алдында шуны авыз күтэреп әйтеп торуына кинәт бик уңайсызланып, күн итек башы белэн жиргэ сызыклар сызарга кереште. — Тату яши алмадык шул...
— Әллә эниең авырыймы?
— Юк, эни сау-сэламэт.
— Эниең белэн килешэ алмаганга гына аерылдыгызмы?
— Эни белэн араны өзсэм дэ, партиядэ торырга лаек кеше булмас идем.
— Синең эле кая барышың?
— Вэсилэлэргэ. Әйбэтлэп әйтсэм, бэлки кайтыр.
— Белэсеңме, нэрсэ, Мэхмүт, давай, без башта сезгэ барыйк. Син hаман Иске Кэлимэттэ торасың бит, эйеме? Үзегезнең йорттамы?
— Шунда инде. Үзебезнең бер иске куыш булганга, квартир бирми тилмертэлэр бит. Әллэ кайчан чыгып киткэн булыр идем дэ... Минем генэ кулдамыни ул.
— Вэсилэ кайчан китте?
— Бер атна була инде...
— Нишлэп соң моңарчы миңа әйтми йөрисең аны?
— Әй, абый, кыен бит ул, сезнең эшегез ул гынамыни!
— Юк, әйтү кирэк иде. Партия рекомендациясен мин бирдем түгелме соң сиңа?
Мэхмүт дэшмэде, иренен тешлэп, тагын күн итек башына төбэлде.
«Юк, хэзер сүз озайтып тору мэгънэсезлек, — дип уйлады партком секретаре. — Өйлэренэ барыйм әле, үз күзем белэн күрим. Нигэ тыныша алмадылар икэн?»
— Киттек, — диде Тажи аңар. — Өеңне карап кайтыйк әле.
Беренче номерлы автобус аларны Иске Кэлимэткэ илтеп куйды. Раймаг янында автобустан төшкэч, уңга борылып, үзэнлеккэ таба киттелэр. Кечерэк бер күпер аркылы чыгып, машиналар актарып бетергэн шактый ук былчырак бер урамга килеп керделэр. Тажига бала чагы берьюлы килеп бөркелгэндэй булды: урам ярым караңгы, капка-коймалы өйлэрдэ сары утлар жемелдэшэ, кайдадыр этлэр өрэ иде.
— Гобэйдуллиннар ягында торасыз икэн, — диде Тажи, корырак урыннан барырга тырышып.
— Арслан Шэвэлиевичлар хэзер монда тормыйлар бит.
— Элек монда торалар иде. Әтилэре эле дэ шушында яши. Энэ теге аргы урамда. Анда, бэлки, аулаграктыр, машиналар күп йөрми торгандыр.
— Әй, абый, машинаның йөрмэгэн жире юк инде аның хэзер. Ике йортка бер шофер. Урамнарның элэ-танагын калдырмадылар инде, яралар да керэлэр. Ичмасам, таш жэйсэлэр...
Түбэсен шифер белэн япкан кечерэк бер йортның капкасыннан эчкэ уздылар. Ишек алдын тэрэзэдэн төшкэн ут кына яктырта — кая кереп батасыңны белерлек түгел иде.
— Кесэ фонарең юкмы? — диде Тажи.
— Абый, курыкмагыз, таш жэйдем мин ишек алдына. Минем арттан барыгыз.

Тажи рәшәткә буйлап бара торгач, ниндидер бер каралты янынннан узды, каяндыр эчтән мышнаган, печән кушәгән тоныk тавыш ишетелде. «Сыер да асрыйлар, ахрысы», — дип уйлады Тажи.

Чолан ишеген шакуга, ялт итеп ишек башында ут кабынды. Өстенә плюш жикет кигән, башына бизәкле яулык бөркәнеп, яулык өстеннән бүрек бастырып куйган илле яшьләр тирәсендәге нык гәүдәле бер апа килеп чыкты. Кыеклап төшкән ут яктысында Тажи аның бер генә мизгел каушап, аптырап калганын күрде. Апа башындагы бизәкле зур яулыгы белән авыз читен каплаштырып, өйгә үтәргә чакырды.

— Әни, бу безнең Тажи абый, партком секретаре, ничек яшәгәнне карарга килде, — диде аңар Мәхмүт.

— Ә, шулаймыни? Бик әйбәт, бик әйбәт, кунакның килеп торганы яхшы. Тормышларыбыз алай зарланырлык түгел, — дип, авыз читен әле һаман яулыгы белән каплаган көе, апа Тажины эчкә үтәргә кыстады, өйгә килеп керүгә, кучкар өстендә торган бәләкәй ак самавырны алып, аңар тиз генә су салды, телеп куйган бер көлтә чырага ут кабызып, торбасыннан төшерде дә кече учак төнлегенә торбаны тыгып куйды.

Ул самавыры белән кайнашкан арада Тажи өй эчен күздән үткәреп алырга өлгерде. Күпертеп җыйган, өстенә ак мендәр өеп, ак челтәр каплаган зур гына тимер караваt, тәрәзәсез стена ягында шәһәр йортларында була торганча зур шифоньер, әйбәт урындыклар, зур приемник — бу йортта шактый ук мул тормышлы кешеләр яшәгәнне әйтеп тора иде. Ә иң күзгә ташланганы тагын шул: мич ап-ак итеп агартылган, идәннәр сап-сары итеп юылган, сайгаклар өстенә кулдан суккан озынча паласлар җәелгән: тәрәзә төпләрендәге яран гөлләр инде чәчәк атарга да өлгергәннәр. Үтә чисталык, пөхтәлек күзгә бәрелеп тора иде бу өйдә. Күрәсең, Вәсилә — уңган килен булгандыр. Әллә каенана кулы белән эшләнә микән болар?

— Киленегез Вәсилә кайда соң? — диде Тажи, табын янына утыргач, белмәмешкә салынып.

Әни карчык чәй агызган җиреннән кинәт туктап калды.

— И-и, хәзерге яшьләрнең серкәсе бер дә су күтәрми бит, китеп барган булды әле, кыланчык, — диде әни кеше. Бу юлы ул нигәдер авызын яулыгы белән капларга онытып, бик җитез сөйләп алып китте: — Без дә килен булып яшәдек, каенана ни әйтер икән дип, авызына гына карап торганыек. Хәзер заманасы бүтән шул: килен әнәтерәк сыер караудан җиксенеп, иптәш кызлары янына үбши торакка китеп барган булды.

— Сыер да асрыйсызмыни? — диде Тажи.

— Асраган булабыз: сыйлы көнең сыер белән дигәндәй, минем инде битун күтәреп, кибеттән сөт эзләп йөрер заманнарым узган, үзебезнеке булсын дип тырышкан көние лә...

— Сыерны кем сава соң?

— Килен сава торганые. Ул киткәннән бирле аптыраган, сыерыбыз бик көйсез, мине якын да китерми, әллә инде үземне ятсына, әллә шунда карт кешенең бармакларын килештерми дигәндәй, тыпырчынгандай итенә... Бик кыйты китерде әле киленебез китеп...

— Сыерга курмы каян табасыз соң? — диде Тажи, аларның хәленә кереп.

— Шул инде, килен тырышадырые. Бәрәңге бакчабыз бар, Иске Кәлимәттән калган.

— Күпме?

— Күпме дип, күп түгел... егерме сутый диләрме...

— Егерме биш, — диде Мәхмүт, әнисен төзәтеп.

— Ел саен бәрәңге утыртасызмы?

— Ел саен утыртабыз инде. Ел саен утыртмасаң, сыерга кирәк бит. Чи килеш тә турап бирәдерие килен, пешереп, онга туглап та бирә торганые. Ул киткәннән бирле ике кулсыз калдым мин.

— Кайтыр чамасы бармы соң? Киленегезне әйтәм.

— Кайтырмы дип... ашаган җиренә сыер да кайта бит. Көенә килгәч, кайтмый кая барсын, кайтыр, аллаһы боерса.

— Кайтмаса? — диде Таҗи кинәт кенә.

— Кайтмаса, ни хәл итмәк кирәк? Дөньяның кендеге аңар гына тэрәлмәгәндер. Үзенә үпкәләр тагын... Өйләнер Мәхмүт: төшеп калган малай түгел бит, буе-сыны бар, кулында һөнәре, уч тутырып акча ала, — диде әни кеше. Ул сөйләгәндә Мәхмүт кысылмады, әммә бу сүзләрне авыр кичергәнлеге аның тирә-якка тәгәрәшә башлаган сөрмәле зур күзләреннән күренеп тора иде.

— Алай икән... — диде Таҗи, мәгънәле итеп.

— Шулайрак шул, — дип, әни кеше дә көрсенеп куйды һәм, кинәт исенә төшеп, авыз читен яулыгы белән каплады.

Өйдә барысы өчен дә кыен бер тынлык урнашты.

Таҗи бер нәрсәне бик яхшы аңлап алды: бу йортта Василәне ат урынына җиккәннәр. Ул көне буе промыселда эшли, кичке техникумда укый — анысы да җиткән бит инде. Юк, өйгә кайткач, ул әле идән юа, кер юа, мунча яга, бәрәңге бакчасы казый, бәрәңге ала, сыерның ашарына пешерә, сыерны сава. Моңа ат көче булган килен дә түзә алмас. Ул, әлбәттә, шуларга түзә алмый киткән, ире ягыннан яклау тапмаган.

Таҗи күңеленә килгән уйны ачыклап бетерү өчен әни кешегә түгел, аның улына сорау бирде:

— Я, Мәхмүт, нишләргә исәп?

— Мин тагын барып сөйләшәм инде, — диде Мәхмүт, уңайсызланып.

— Сөйләшү аз монда. Син шуны әйт: кайчан Василәгә кеше итеп карый башлыйсың?

— Ничек кеше итеп?

— Синең үзеңнең өч смена эшләгәнең бармы?

Мәхмүт дәшмәде.

Аның өчен әнисе бик ашыгып сөйләп алып китте:

— Әй, балакаем, көфер сүз сөйләмәсәнә, булмаганны! Өч смена дип инде... Яшь чагында эш нәрсә ул. Мин үзем дә булышырыем, олыгайдым бит менә...

— Сезгә ничә яшь, апа? Гафу итегез.

— Олы инде мин.

— Шулай да? — диде Таҗи, аның хәтерен калдырмаска тырышып.

— Илле бер тулды инде быел.

Таҗи гаҗәпләнүдән хәтта сызгырып куйды.

— Соң бит сезгә әле, апа, пенсиягә чыгарга да дүрт ел бар. Ә сез инде картлар исемлегенә керергә чамалап торасыз. Мин менә әниемнең төпчек баласы, әни авылда яши минем, аңар хәзер җитмеш яшь, өй эшләрен ул эшли әле.

— Юк инде, балакаем, мин Мәхмүтемне әтисез үстердем. Хәзергесе заманда закунда да әйтелмәгән әти-әнине каксыннар дип. Минем дә инде картаймыш көнемдә түр башында утырырга хакым бардыр.

— Түр башында утырырга хакыгыз бар, — диде Вилданов. — Ләкин киленегезне укудан туктатырга хакыгыз юк. — Таҗи эчә торган чәен эчеп бетермичә, урыныннан торды. — Мин мин партком секретаре, яшьләрне укырга өндәп йөрим, ә сез аларны укудан аерасыз булып чыга. Бу эш сезнең кебек олы кешегә килешеп бетәрме соң?

Карчыкның кем икәнлеген абайлап алганга күрә, Таҗи аңа тәмле тел белән аңлату мөмкин түгеллеген төшенеп, закон сүзләрен дә кушып,

бераз өркетмәкче булды. Ләкин аның беркатлы ул хәйләсе барып чыкмады.

Карчык Тажидан хәйләкәррәк иде.

— Соң инде, балакаем, мин әйбер әйтәммени, үз күннәрен үзләре күрсеннәр, мин ничек тә үз көнемне үзем күрермен, — диде ул, малае белән килененең бүген урамга чыгып китә алмаслыкларына ишарәләп. — Ике иңем, бер түбәм дигәндәй, дүрт яклары кыйбла. — Сүзен әйтеп бетергәч, көлемсери биреп, я, син моңа ни дип әйтерсең икән дигәндәй, Тажига төбәп карап тора башлады. — Бирегез үзләренә әйбәт фатир, газлы, ванналы. Берүк китә генә күрсеннәр...

Аның хәйләсен сизеп алган Тажи якын арада операторлардан кемнәргә һәм кайданрак квартир биреләчәген күңеленнән барлап чыкты. Кемнәрнең әле тагын бераз түзә алачагын исәпләде. Андый кешеләр бар иде. Һәм шуннан соң ул Мәхмүтнең әнисенә аның үзеннән дә битәр төбәп карады:

— Яхшы алайса, апа, без промыселдан улыгыз белән киленегезгә квартир бирәбез.

— Кайчанрак? — диде әни кеше.

— Бер айдан квартирлы булырлар.

Бер айдан ук квартир биреп булмаячагын белә иде партком секретаре, ләкин ул моны хәйләкәр каенананың табигатен ачыклап бетерү өчен әйтте.

— Бәрәкалла, бик шәп! — диде әни кеше. — Үз көннәрен үзләре күрсеннәр. Тик аның бит, балакаем, бер ягы бар, картаймыш көнендә әнисен япа-ялгыз калдырып киткән өчен, партиунныйлар Мәхмүтнең башыннан сыйпарлар микән соң? Фатир алу белән генә эш бетми бит әле... Сез, алайсам, бик әйбәт уй белән йөрисез, болай булгачыннан, минем улымны, әниеңне ташлап кит, дип котыртырга килгәнсез икән, бәрәкалла...

— Юк, апа, бик ялгышасыз, мин сезнең улыгызны да, киленегезне дә котыртмыйм, котырта торган булсам, мин Мәхмүтне судка биргән булыр идем.

— Бәрәкалла, ни өчен?

— Василәне эксплуатацияләгән өчен. Көнлекче хәлендә яшәткән өчен. Сез әле үз көчегездә. Пенсиягә чыкканчы да дүрт ел эшләрлегегез бар. Бу йортны дөбердәтеп алып бара аласыз. Улыгыз сезне ташлар дип тә юкка борчыласыз. Ул сезгә ярдәм итеп торыр. Кышлыкка утын кайтарырга дисәгез, ул ягына без машина бирербез. Идарә ярдәм итәр. Аңлашылдымы?

Шушы чандыр гына, бөтерчек чаклы гына кешенең житмәсә тел очы белән сакаурак итеп сөйләшә торган адәмнең шулкадәр кинәт һәм көтмәгәндә үзен төп башына утырта алуына исе-акылы киткән каенана, ни дип тә җавап бирергә гаҗиз булып:

— Ярый инде, бик рәхмәт инде, аңлашылмаган кая инде... — дип кенә әйтә алды.

Тажи, саубуллашып, өйдән чыгып китте.

Аның артыннан ияреп Мәхмүт тә чыкты. Ул каушаган, йөзендә шатлык-сөенеч тә бар, бераз гына хәвефләнү, ышанып житмәү дә бар кебек. Партком секретареның җиңеннән тотып алганын да абайламыйча:

— Рәхмәт яусын, абый, квартир чыннан да була инде, имә? — дип сүз башлаган иде, Тажиның өйдә, олы кеше янында көч-хәл белән тыеп торган нервысы кинәт котырып китте:

— Нәрсәсе рәхмәт? Нәрсәсе?! — дип кычкырып диярлек әйтеп салды. — Ни өчен сине ун ел буе укыттылар, комсомолда тәрбияләделәр?! Ә?! Ник дәшмисең? Бер әниеңә аңлатып бирә алмагач! Күрәләтә, икәүләшеп, ярдәмчесез Василәне төпкә җигеп, каезлыйсызмы? Бик шәп

анлыйсың икән син намус дигән нәрсәне! Имеш, аны әнисен ташлап китсә, халык гаеп итәчәк! Табылган монда аналарга хөрмәтле кеше! Ә хатыныңР Ул да бит ана буласы кеше! Менә нәрсә, Мәхмүт, — ул, кызып киткәненә үкенгәндәй, әкренрәк сөйли башлады: — Әниең синең бик үткен, законга да бик остарган. Бел аны, Василәне рәнҗетсән, миннән рәхим-шәфкать көтмә. Ишеттеңме? Бүген үк барып сөйләш хатының белән. Җәлил урамындагы яңа йортны файдаланууга тапшырырга торабыз. Мин партком белән сөйләшеп карармын. Ышандыра алсам — синең бәхет. Ярый, бар, кер өеңә, тынычландыр әниеңне, олы кешегә катырак орындым бугай...

Тажи кайтышлый Арсланнарга керде. Мәхмүт мәсьәләсен кузгатырга яхшысынмады. Исәбе — шофер Дугинцев хакында белешә алмавын әйтеп чыгу гына иде.

Арслан ул турыда сөйләшеп куйган икән инде.

— Автохуҗалык директоры Ивашкинны күрдем. Әниләрдән кайтышлый урамда үзе очрады, — диде ул, Тажины тынычландырып.

— Соң?

— Тәртипсез егет булып чыкты. Инде ике мәртәбә иптәшләр судында тикшергәннәр. Грузотаксига төяп Чупай карьерыннан таш алып кайткан.

— Үзенәмени?

— Йорт салучы частникка.

— Нишләтә инде ул аны?

— Кем?

— Ивашкин.

— Судка бирә.

— Иптәшләр судынамы?

— Нишләп? Халык судына. Бүтән шоферларга да сабак булыр. Юкса бик узына башладылар. Егерме операторны ике сәгать буена суыкта бастырып торуны чүпкә дә санамыйлар.

— Үзебездә дә гаеп бар, Арслан Шәвәлиевич. Барлык цехларның да төгәл эшләвен таләп итә алганыбыз юк. Контора башлыкларын партбюрога чакырып сөйләшми булмас, — диде Тажи һәм, таба белән чыжылдап торган күкәй тәбәсе күтәреп чыгып килгән Сәгыйдәне күреп, китәргә ашыга башлады.

Арслан белән Сәгыйдә, ирле-хатынлы, ай-ваена карамый, аны табын янына утырттылар.

— Бик авыр көн булды бүген, — диде Арслан. — Әйдә берәр йөз грамм тотыйк булмаса...

Төнге сәгать уннарда, саубуллашып чыккан чакта, Тажи Арсланга әйтте:

— Әллә, мин әйтәм, Арслан Шәвәлиевич, Дугинцев мәсьәләсендә иптәшләр суды белән чикләнәбезмеР Соңгы тапкыр. Бала-чагасы күп бит.

Арслан моңсу гына елмайды.

— Усал да, нечкә дә күңелле кеше син, Тажи, — диде.

## 8

Гобәйдуллин промыселларны әйләнеп кайтканнан соң ерактагы һәм якындагы бурычларын билгеләде. Ерактагы бурыч — завод һәм шәһәр салу хакында төзүчеләр белән сөйләшә башлау иде. (Корбанов белән очрашканнан соң аның ышанычы кабат ныгыды.) Ә якындагы, кичектергесез бурыч — идарәнең нефть чыгару планнарын, хәрәкәтсез фондларын барлау, операторларның көнкүрешен яхшырту чараларына керешү иде. Беренче квартал тәмамлау алдында тора, итәк-чабуны бик нык



жыярга кирәк, юкса эшчеләр арасында ризасызлык көчәеп бара, шуның өстәвенә парткомның отчет-сайлау җыелышы борын төбендә, идарә коммунистлары еллык отчетка тулы әзерлек белән килергә тиешләр.

Теге чакта Мөстәкыймов белән аяк терәп сөйләшсә дә, җыелыш көне якынлаша барган саен, Гобәйдуллинның хәвефләнүе арта, Вилдановның партком секретаре булып калу-калмавы аны бик борчый иде. Хәлләрне ачыклау өчен ул урынбасарларын рапортка чакырып алды.

Баш механик Гайдуков рапорт вакытында Күлле Чатыр авылы янындагы ЭЛОУ корылмасының бер мичендә «хлопок» булганны хәбәр итте. Болай җиңел генә әйтелсә дә, бу — шактый ук куркыныч хәл. «хлопок» дигәннәре мичтә шартлау булган, димәк, установка эштән чыккан дигән сүз иде.

Арслан, авария булган корылманы үз күзләре белән күрергә теләп, бер минут кичекми Атнабайны чакырып алды.

«Бәла өстенә бәла, аны төзәткәнче тагын күпме вакыт әрәмгә үтәчәк»,— дип уйлады Гобәйдуллин юлда барганда. Ләкин бәла ул көткәнчә зур булып чыкмады. Мичнең өске көймәсен генә умырып аткан, эшчеләр имгәнмәгән иде. Сварщиклар инде установканы ремонтлап яталар, бер-ике көннән ул тагын сафка басачак.

Ләкин шушы сәяхәт Арсланның болай да көйсез тормышына тагын да зуррак борчу алып килеп, аның җан тынычлыгын бик озакка бозып куйды. Ул бер атна чамасы хатыны Сәгыйдә алдында үзен уңайсыз тоеп, балалары алдында кыенсынып, эченә бикләнеп яшәде.

Эш болай булды.

ЭЛОУдан өйгә кайтып барганда көн бозылды, җирне-күкне бер итеп, дөньяны тоташ соры пәрдә белән томалап, ябалак-ябалак кар ява башлады. Машинаның каршы тәрәзәсенә кар шундый күп сырыша, Атнабайның пыяланы сөртер өчен бик әйбәтләп корып куйган стрелкасы ничаклы тырышса да, аны сөртеп бетерә алмый, шуңа күрә тизлекне бик нык киметеп, машинаны үз җаена гына алып барырга, өстәвенә, Атнабайның үзенә әледән-әле машинадан төшеп, кар ябышкан тәрәзәне чүпрәк белән сөртеп алырга туры килә иде.

Күлле Чатырга өч-дүрт чакрымнар кала, юлда бөкрәя төшеп атлаган хатын-кыз күренде. Бәхетгәрәев янәшә утырып кайткан тонык йөзле начальнигына күз сирпеп алды: нишлибез, юлчыны утыртабызмы? Арслан баш кагып кына ризалык белдерде. Туктадылар. Атнабай, ишеген ачып, килүче хатынны көтеп алды. Юлаучы — әллә машина туктаганны сизмәде инде — һаман да бөкрәя төшкән көйгә, йөзен кулы белән каплап, каршыдан бәреп яуган карга каршы атлый бирә иде әле.

— Әй, апасы, утырасызмы? — дип дәште аңа Атнабай.

Юлчы туктады. Аның өстендә яшькелт пальто, башында ак шәл иде,

Шәл читләренә һәм йөзенә сырышкан юеш карны кулы белән сыпыра-сыпыра, дәшүчегә таба борылды.

Тәрәзәдән карап торган Арсланның йөрәге чыгардай булып тибәргә тотынды. Машинага таба Мөнәвәрә атлый иде. Хатын машинага кереп утырды.

— Мөнәвәрә... — диде Арслан, әкрен генә.

Мөнәвәрә башын күтәрде. Юеш кардан мәк чәчәге төсле алсуланган озынча сабыр йөзендә озын кара керфекләре тетрәнеп китте. Үзе дә сизмәстән, ул алга сөрлекте, кысылган иреннәре арасыннан гаҗиз булып бер сүз тышка бәреп чыкты:

— Арслан! Я ходай! Бу нинди көтелмәгән очрашу?

— Ә без... кайтып киләбез менә. Саумы, Мөнәвәрә! Ничә ел бит. Әйдә, күрешик хет.

Мөнәвәрә, утыргычына ябышкандай, кузгалмады. Аннары кинәт аңына килеп, юешләнгән йон перчаткасын салырга азаплана башлады, каушавыннан ул аны тиз генә салып бетерә алмый, тешләре белән тарта иде. Шушы күренешкә шаһит булып торган Атнабай, уңайсызланып, машинасын үкертеп алды.

«Менә нинди очрашулар да була. Бу инде бүгенге авариядән хәтәррәк», дип уйлады ул. Арсланның әллә кайчангы яшьлек мәхәббәтен исенә төшереп. Ул үзе дә аңардан ким дулкынланмый иде бу минутта. Арслан белән Мөнәвәрә ягына борылып карарга батырчылык итмичә, руле өстенә ятып, әле генә күргән гүзәллекне, тетрәнеп киткән озын кара керфекләрне, зур булып ачылган күзләрне, хыялый төш сыман, күз алдыннан үткәрде.

— Кузгалдыкмы? — диде әкрен генә. Һәм алар кузгалдылар. Шул минуттан башлап, ул тәрәзәне сөртергә, машинаны сак кына алып барырга икәнен онытты.

Күлле Чатырның урта бер җирендә, нинди дер бер йорт янында Арслан машинаны туктатырга кушты. Атнабай туктатты. Ләкин Мөнәвәрә машинадан чыгарга ашыкмады.

Атнабай Арслан бүген рульдә үзе генә булмавына үкенеп куйды. Әгәр үзе генә булса, алар менә хәзер җаннары туйганчы сөйләшә алырлар иде. Болай ул аңардан уңайсызлана инде, билгеле. Машинаны читкә алып китәргә нинди сылтау табарга соң?

Ничаклы гына түзәргә тырышса да, ул алар ягына карамый булдыра алмады. Дөресрәге, ул Мөнәвәрәгә күз төшерми булдыра алмады. Мөнәвәрәнең йөзен ачып җибәргән ап-ак шәле, чамадан тыш уңайсызланып һәм каушап, дәү гәүдәле Арслан янында тыенкы гына утырып торуы Атнабайның бик тиз тәэсирләнүчән күңелен ут кебек өтеп алды.

Атнабай алдан чыгып, Мөнәвәрә ягындагы ишекне ачты.

— Рәхим итегез, — диде.

— Дустым... — диде аңа Арслан, уңайсызланып. — Без бер ярты сәгатькә генә туктый алмыйбызмы? Мөнәвәрә өйләренә чакыра, кермәсәң — кыен... Сәгыйдәнең апасы бит.

— Ул турыда нинди сүз булуы мөмкин. «Алмачуарымның» солысы да бетеп бара, иртән заправкага барырга оныта биреп килгәйнем, — диде Атнабай, аны ярты сүздән аңлап.

— Юк, син әллә ниткән сәбәпләр эзләп маташма, керсәк, бергә керәбез.

— Ярый, ярый, үзеңә ничек уңай, шулай эшлә.

Мөнәвәрә, ишек алдына кереп, зур капканың бастырыгын алды. Машинаны эчкә кертеп куйдылар. Ишек алдының кары бик чиста итеп көрәлгән. Верандалап салынган чолан буенда, баскыч күтәрмәсендә, озын саплы себерке белән агач көрәк тора, бүрәнә җекләре ак балчык белән сыланган алты почмаклы өйнең зәңгәр буяулы тәрәзәләре биек

һәм зур иде. Алар аякларын каккалап, баскыч төбендә таптанган арада болдырга төенчек чаклы гына гәүдәле, озын чуар күлмәгенең итәкләрен бөрмәсенә кыстырып куйган бер карчык килеп чыкты, кулларын каш өстенә куеп, төбәлеп карап алды да:

— Бәрәкалла! Кияү түгелме соң?! Арслангали, синме, балакаем? — дип, ике кулын берьюлы сузып, күрешергә килә башлады. — Менә син, агай, тамаша, менә син, агай! Ничекләр килеп чыгасы иттең?!

— Кияveңнең исендә дә юк иде әле, урамнан узып та кермәскә чамалый, — дип Мөнәвәрә, башын кыңгыррак салып, йомшак көйле тавышы белән әкрен генә көлеп куйды.

Өйгә керделәр.

— Түргә узыгыз, түргә, — диде Мөнәвәрәнең әнисе Мәйсәрә түти, алгы бүлмәнең пыялалы зур ишеген ачып. — Менә, кияү, без дә өй житкездек бит әле. Өй котларга да килә алмадыгыз.

Түр бүлмәдә Атнабайның күзенә беренче булып ташланган нәрсә — өйнең яртысын диярлек алып торган, ап-ак итеп агарткан зур мич булды. Пөхтә дә тоталар соң авылда мичләрне. Кучкарга бәләкәй ак самавыр куеп, өстен челтәр белән япканнар, каршыда — ике тәрәзә арасында зур көзге, стена буенда диван, шифоньер, тәрәзә төпләрендә яран гөлләре тезелеп тора иде. Үнган киленле татар өйләрендә була торган чиста-пөхтәлек, күкрәкне киңәйтә торган әйбәт саф һава Атнабайны нииндидер аулак һәм тыныч бер дөньяга алып кергәндәй булды.

Мәйсәрә түти белән Мөнәвәрә, мич буенда кайнашып, самавыр куеп жибәрделәр. Учакка ягып, шундук нәрсәдер чаж-чож кыздыра да башладылар.

— Белмәдем бит киләсегезне, жылкы итеннән аш пешереп куйган булырыем, быел яшь ат алып суйдык, — дип сөйләнде Мөнәвәрәнең әнисе. Аның кызыныкы төсле озынчарак йөзенә, ирен читләренә мул булып жыерчыклар кунган, ләкин ул картлык билгеләре аның мөлаемлыгын, ихласлыгын, эчкерсезлеген киметмәгәннәр, тагын да арттыра төшкәннәр иде.

— Сәгыйдәнең хәлләре ничек? Авырмыйсыгызмы? Рәфикъ белән Әлфия зур үскәннәрдер инде, әбиләрен бик сагынмыйлармы? Үзем менә үлепләр дә сагынам инде шуларны, исемә төшкән саен, үзәкләрем өзелеп китә. Югыйсәң, ерак аралар да түгел инде, килмисез бит, килмисез. Мөнәвәрә балалары дәү булдылар инде, минем итәктән төштеләр, дәү булгачыннан әби тирәсендә бик чуалмыйлар икән шул ул, үз дөньялары үзләре белән була икән аларның, — дип, әллә ни арада күңел тойгыларын, сагышларын бушатып ташлады Мәйсәрә түти, ул арада Атнабайның да кем икәнен, кайда эшләгәннәрен сорашып алырга өлгерде.

Атнабай үзен Арсланның шоферы дип кыска гына аңлатты. Ул бөтен күңеле белән Мөнәвәрәгә төбәлгән, Мөнәвәрәдән күзләрен ала алмый иде. Аның сизелмәс дәрәжәдә йомшак-нәфис атлап йөрүләре, Арсланга күтәрелеп карарга да базмыйча, табынга ризык куеп-куеп китүләре, күбрәк Атнабайга дәшеп, аны кыстаулары, маңгай турысыннан кысып, артка чөеп бәйләгән челтәр читле ап-ак яулыгы, ялкын сулап торган йөзе, дәшкән чакта уңайсызлана бирен елмаюы һәм вакыт-вакыт бит уртасының уймакланып чокыраюы, барыннан да бигрәк, тойгы белән тулып, көйрәп торган озын кара керфекле зур күзләре — болар барысы Атнабайны акылыннан яздыралар иде.

Шоферының өзлексез гашыйк булып тора алу гадәтен белгәнгә, әни карчык алдында аны хәзерге ахмак хәленнән коткарырга теләп, Арслан житди генә дәште:

— Аша син, Атнабай, аша. Юллар начар, тайгак, я берәр чокырга аударып куярсың...

— Аусак, бергә авабыз инде, Арслан абый! — дип, кетмәгәндә келеп җибәрде Атнабай.

— Аллам сакласын, андый көфер сүзне уйнап та әйтмә, улым, — диде Мәйсәрә түти һәм авыз эченнән генә догасын укып алды.

Арсланның бу йортта, Мөнәвәрә янында, озаклап утырасы, аның белән сөйләшәсе, һич югы, янында булуын тоеп торасы килә иде, ләкин, бердән, әбисе, икенчедән, шоферы Атнабайдан уңайсызланып, ул кузгала башлады. Мәйсәрә түти тагын хафага калды.

— Әбәү, нишләвең бу, кияү? Күргән күк тә булмадык бит әле. Нишләп соң кунып китмисегез, машина үз кулыңда бит. Менә хәзер җылкы итеннән аш салам, мичкә бәлеш куям...

— Юк, әби, рәхмәт, икенче килербез.

— Алайсам, иркенләп килегез, яме. Парлап килегез, балаларны алып. Машина бит үз кулыңда, түрә-карага ялынып йөрисе түгел. — Шундук Атнабайга таба борылды: — Син, улым, Атнабай дидеңме әле атыңны, башкорт ягыннан дидеңме әле, ай алла, бик рәхмәт, бик әйбәт. Син, улым, төя дә алып чык машинаңа Арслангали белән Сәгыйдәне, балаларын да калдырма, яме. И, Рәфигым белән Әлфиямне сагындым, бер күрергә тилмертеп үтерәсез бит инде. Мөнәвәрәгә ничәмә-ничә мәртәбәләр әйттем, барыйк әле Кәлиматкә, дидем. Бушамый шул, бер дә генә бушый алмый. Кышын мәктәптә балалар укытып көне уза, җәйләрен менә өй салып мәшәкатьләндек...

Мәйсәрә түти кияүне капка төбенә кадәр озатып куйды. Үз итеп, якын итеп, үзәкләре өзелеп, кунакка чакырды, әмма ул Арсланның бу йортка килүе нинди күңел тетрәнүләре белән бәйләнгәнен белми иде шул, белсә, менә хәзер, урамга чыкмыйча, өйдә генә саубуллашып калырга теләгән кызы Мөнәвәрәне, бу ниткән яңа гадәт тагын, кунакны шулай озаталармыни, дип тә тормас иде.

Арслан Мөнәвәрә белән баш иеп кенә саубуллашты, әбисе янында озаграк юанды. Мәйсәрә түтинең кияүне озатканда күзләре дымланды, каршы алгандагы кебек, бәләкәй ябык кулын каш өстенә куеп, капка төбендә моңаеп басып калды.

Бик озак тын кайттылар. Авыл ераклашып, машина асфальт юлга килеп чыккач, Атнабай авыр итеп бер көрсенде.

— Нинди гүзәллек әрәм ята. Юкка син аның сеңелесенә өйләнгәнсең, Арслан абый, — диде.

— Гөнаһлы уйларга өстерәмә син мине, Атнабай. Бар кеше дә синең кебек, адым саен гашыйк булып тормый бит.

— Анар гашыйк булмаган кеше таш йөрәк...

Арсланга болай да авыр иде. Мөнәвәрәнең ул ничек тетрәп китүен, ничек каушавын һәм, яшь кызлар төсле, алсуга кабынуын күз алдыннан үткәреп кайта иде. Шоферы аның ачылган ярасына тоз сипкәч, түзмәде:

— Ә нигә өйләнмисең син, Атнабай? Картаясың бит инде, — дип, сагышлы уйларыннан котылырга теләп, сүзне икенчегә борып җибәрде.

— Әй, өйләнгән идем лә мин... — диде Атнабай, уфтанып.

— Соң?

— Уңмадым хатыннан, ташлап китте. Үзем ише простой эшче-мазар түгел, укымышлы кызга өйләнеп хур булдым, — диде Атнабай, машина рулен катырак кысып.

— Дөресен генә әйткәндә, Уфада танышып кайткан идем. Артист булып йөргән заманнарда. Салаватка килеп, бораулау конторасына шофер булып ялландым, арттан хат җибәрә бу: фәлән дә фәсмәтән, тату яшәрбез, теге дә бу. Кайтсам, Салаватка — дөнья тулы үзем ише акны ак, караны кара дип танучылар. Ә бу укымышлы, юристлар институтын бетергән кыз. Әллә нәмә эшләп күңелгә ятмай бу минем. Эре бәрәңге ашаган кебек эреләнә башласа, дип уйлаем. Мәсьәләне берь-

юлы тәреп куярга да моның белән араны өзәргә исәп. Юк, агаем, бу миннән остарак булып чыкты. Каян белгән диген, минем инәй карчыкка хат язып җибәргән, и кучтәнәчләр. Корткаларның күңел кылы нечкә бит ул, каныкты бит инәй: кызы да бик инсафлы күренә, үзе яшь, үзе чибәр, үзе интеллигентный, ди. Гомер буе театрда уйнап, интеллигентныйның кем икәнен белеп бетергән кеше инде минем инәй. Ә атай минем — гомер буена мазутка буялып йөргән кеше, ягъни инәй карашынча интеллигент түгел. Әллә нәмәгә йомшаклык күрсәттем, инәй карчыкка яхшылык эшлисем килде, тоттым да өйләндем моңар: Салаватта квартир бирделәр. Туйлар ясадык — торабыз. Шәһәрдә сүзем үтми торган егет түгелмен: таныш-белештән тәмле сүзне кызганмыйча, нотариаль конторага эшкә урнаштырдым. Эшләр худта безнең, югыйсәң, пар күгәрченнәр кебек, гөрләшеп кенә торабыз. Үзем дә төшеп калганнардан түгел, буровойга боргычлап торба ташыйм, алдынгылар арасында алма булып йөримен. Укымышлы галим-голәмәнең дә эш бик тыныч, хезмәт иясе сыйныфына төрле белешмәләр биреп, җылы тыныч бүлмәдә рәхәтләнеп кенә утырасы. Юк, адәм баласы рәхәткә чыдай алмый, михнәткә генә чыдай бит ул. Әйле-шәйле бер ел тордык микән, өге-җөге айлар узып та китте. Судьялыкка керәм ди минем сөекле сөягем. Юк, мин әйтәм, кермәйсең. Керәм, ди, керәм булгач, керәм, ди. Ярар, дидем, керсен, ләкин, агаем, дөресен әйтим, теләмәй генә бит күңел: адәм баласына тиешле-тиешсез закон чыгарып, нахакка яптырып утыра башласа — вөҗдан дигәнең выжылдый инде, көйле машина кебек. Ярар, керде бу, ярым-йорты ярты ел эшләдеме икән, минем укымышлы бичәкәем мебель алмаштыра, минем белән театрларга барырга хурлана. Юк, хурлануын үземә әйтмәй, мин бит сукыр түгел, күреп йөримен. Бер көнне үзеген үзәккә аерып әйттем: хватит! Укымышлы бичәкәем статьялар белән генә авызны томалай, бер дә харап. Ә минем статья бик кыска, рульне бик капыл бора торган. Өстәл артыннан тордым да өстәлне судьясы-ние белән аудардым да җибәрдем.

— Ну-уу? — диде Арслан, гаҗәпләнеп. — Син шул эшне булдырдыңмы?

— Җаныңа тисәләр, булдырасың икән аны.

— Соң шуннан?

— Нәрсә шуннан — аерылдык. Тагын ярты ел уздымы икән, моны ялган хөкемдә тоттылар. Взятка алган. Өстәвенә, кайсыдыр бер трестның кара мыеклы, яшь кенә инженер белән урманга да барып кайтканнар. Гөнаһ шомлыгы — мотоцикл бишегендә моның судья печәте төшеп калмасынмы! Ул хакта шәһәр газетасында фельетон чыкты. Минем галим-голәмәмне дөбердәтеп судьялыктан алдылар, япмадылар. Катын-кыз булуы мишәйт итте. Ни дисәң дә, кызганыч бит, аннары теге кара мыек та яптырмас өчен акчаны күп түккән, диделәр. Мин һаман әүвәлгечә: машинада мәш киләм, буровойга боргычлап торба ташыйм, алдынгылар арасында алма булып йөрим. Шулай да бер мәртәбә очраштык без аерылган бичәкәем белән. Буровойга бара идем, күземә күренәме әллә дип торам, юл чатында минем сөеклем басып тора — йөрәк түзмәде, туктадым. Кабина ишегенә ятып елай, нишләттең син мине, ди. «Елама да, сыктама да, чибәркәем, алгы көнең турында аек акыл белән уйлап кара инде, — дидем. — Безнең юллар аерым, минем барыр юлым ерак, сау бул, бигайбә!» Киттем. Ул шунда басып калды. Бераз баргач, борылып карадым. Һаман шунда басып тора: кайсы юлдан китәргә белмәй икеләнә бугай...

Арслан рулен чытырдатып кыскан Атнабайга кырын күз салды. Егетнең йөзе уйчан, күзләре моңсу иде. Мәзәгрәк итеп сөйләсә дә, хатыны белән килеп чыккан драмасы чын иде, ахрысы. «Аңламассың хатын-кыз күңелен. Берсе алма кебек яшьлегеп исерек ир белән үткәрә, тукмала, җәнҗалларга түзә. Икенчесенә Атнабай кебек акыллы егет тә

ошамый... һич аңламассың... — дип моңаеп уйлады Арслан. — Менә бит нинди зур яра калдырган. Төзәлсә бик хуп, төзәлми торган яралар да була бит...»

## 9

Арслан белән очрашканның иртәгесен Мөнәвәрә, ниндидер сөенеч бар сыман, җиңеләеп уянды. Тәрәзә пәрдәләрен ачып җибәргәч, аһ итте — урамда ялт иткән аяз иртә! Өй түрендәге яшь бакча бәллүрдән коеп куйган төсле. Юка боз элпәсенә төренгән сәрби куаклары, яшь каеннар һәм миләш чыбыклары, кояшның иртәнге нурларыннан аллы-гөлле төсләргә кереп, күз явын алып балкыйлар, күңелнең әллә кайчангы истәлекләрен кузгаталар иде.

Мөнәвәрә тузмәде, җилкәсенә шәлен салып, бакчага чыкты. Көн шундый аяз, сулавы шундый җиңел, дөнья шундый да тын, әйтерсең, кичә буран булмаган, ябалак кар да яумаган! Миләш чыбыгыннан сары түшле бер кошчык пырылдап очты. Селкенеп калган чыбык, зыңлап, күршесенә килеп орынды. Күршесе күршесенә хәбәр итте. Һәм менә өй яны бакчасында гаҗәеп нәфис кыңгырау бик озак зыңлап торды. Дөресрәге, ул аваз күптән сүнде инде, аның кайтавазы, яңгырап һәм тирәнәеп, Мөнәвәрә күңелендә кабатлана.

Яз җиткән ләбаса! Дөнья артыннан куып, сизми дә калган ул — яз җиткән! Һавада чәер исе, өянке бөреләре исе, җылынган тупыл кабыгы һәм дымсу кар исе. Гомер-гомергә, адәм балалары белә башлаганнан бирле, мәңгелек яшәештән килгән инстинкт, табигатьнең каядыр өндәү, каядыр чакыру-ашкындыру инстинкты Мөнәвәрәнең дә күңелен кузгатып, күптәнге сагышларын яңартып җибәрде...

...Саташулы авыр көннәрдән соң, Кәримнең каберен Кәлимәттә калдырып, өенең тәрәзәләренә аркылы такта кадаклап чыгып киткәннән соң, җиде ел вакыт узды. Аккан сулар, искән җилләр белән санасаң гына да күпме гомер! Аның инде олы улы — Әнвәре җиденче класста укый, төпчек кызы — Миләүшәсе быел бишне бетерә. Әйе, Кәлимәттән алга-артка карамыйча, дөньясын каргап һәм йөрәккә мәңгелек үкенүләр төяп, качып диярлек чыгып киткән көннәрдән соң җиде ел вакыт узган.

Җиде ел! Җиде кыш, җиде җәй, җиде көз һәм җиде яз бит ул! Бик күп, бик күп гомер. Һәрхәлдә, баштан үткәннәрне, үтәчәкләрне уйлар бизмәненә салып карарга җитәрлек вакыт. Дөньяга ник туганың, ник яшәвең турында уйлап карарлык вакыт. Ә андый уйлар бәхетле тигез тормыштан түгел, сагышлы, җәрәхәтле йөрәктән туалар.

Җиде ел Мөнәвәрәнең холкындагы күп нәрсәне үзгәртте. Юашлыгын алып ташлады. Ихтыярсызлыгын. Кәримсез үткән җиде ел Мөнәвәрәне яңабаштан сүтеп җыйды. Авылда ул йорт җиткезде. Утын хәстәре артыннан чапты. Балаларын киендерү, укыту, аларның зәвыкларын билгеле бер якка юнәлдерү — барысы аның өстендә иде. Үзе укыта торган фән — ана теле белән дә эш шома гына бармады. Машина заманы, техника заманы, зур ачышлар һәм тетрәүләр заманы аның укучыларын, укучыларының ата-аналарын төрлечә уйлап карарга мәҗбүр итә. Алар: без татарча укып ерак китә алырбыз микән соң? Институтларга кирә алырбызмы? дип борчылалар иде. Моның өчен иң әүвәл туган телеңнең мәгънәсен, зурлыгын, газизлеген син үзең аңларга тиеш, аннары гына син аны бүтәннәргә аңлата аласың. Татарстанны нефть иле, химия иле, иген иле, диләр. Әмма иген белән, нефть сыгалары белән, дөнья күләменә чыккан машиналарың белән генә бөтен бер халыкны аңлатып буламы? Англияне Шекспир ватаны дип беләләр, Польша дип әйтү белән күз алдына Шопен килеп баса. Австрия кебек уч төбе чаклы гына илне дөньяга танытучы — Моцарт. Димәк, халыкны халык иткән, дөньяга таныткан сыйфат — аның күңел байлыгы, теле,

сәнгате. Балаларга мисал итеп Мөнәвәрә Тукайны, Муса Җәлилне китереп куйды. Татарстан — дөнья өчен иң әүвәл Тукай ватаны, Җәлил ватаны, Сәйдәш һәм Яруллин ватаны. Тукай да, Җәлил дә дөнья җәүһәрләренә килеп кушылган хәзинәләрен татар телендә иҗат иткәннәр. Сәйдәш белән Яруллин татар халкының күңел байлыгын туплап, алмаз кебек эшкәртеп, зур дөньяга чыгарып җибәргәннәр. Шуларны аңлау Мөнәвәрәнең эшләгән эшен мәгънәлерәк итте. Бу да аның Кәримнән башка яшәгән елларда үз башы, үз акылы белән ирешкән зур бер уңышы иде.

Гомумән, дөнья алып бару бөтенләе белән үз башына калгач, тормыш аны җебеп тормаска, үз хакын даулый белергә, гаделлек һәм гаделсезлекләр турында уйлап карарга өйрәтте.

Яшь һәм чибәр тол хатынның кичкә ут яктысына очып килгән көяз күбәләкләр дә булмады түгел. Мәктәпнең биология укытучысы, тасма телле Таһирҗан бер төнне аңа дөньяның яратылышын аңлатырга килгән иде. Күңел рәнҗеткеч шул вакыйгадан соң, Мөнәвәрә төне буе елап, гарьләнеп чыкты. Иртәгесен үтереп башы авыртты, дөньяда торасы килмәде. Мәктәпкә дәрес бирергә дә бара алмады. Үзенә карата кем дә булса тупас мөгамәлә кылыр дип ул башына да китерми иде.

Тора-бара тормыш аны Таһирҗан кебек әрсез ирләр һөҗүменнән саклана белергә дә өйрәтте: ир-ат белән япа-ялгызы күзгә-күз карап сөйләшергә туры килгәндә, ул андый адәмнәрнең кинаяләрен аңламаганга салыша, тиле кебек, аптырап тик тора; теләген аңлата алмаудан гаҗиз булган, тирләп-пешеп чыккан әрсез адәм, бу сантый хатынга ник бәйләнүенә үкенеп, үзен-үзе тиргәп кайтып китә торган иде. Шулай да мәктәптә аны аңлаган, аның кадерен белгән берәү бар, ул кеше — Сөнгать Хафизов — аның белән беркайчан да дорфа сөйләшми, кинаямазарга урын калдырмый, түбәнчелек белән, ихтирам белән, олылап сөйләшә, аның керсез сафлыгы алдында баш ия иде. Әллә икесе дә бер үк фәнне — ана телен укытканга, әллә холыклары белән тумыштан ук басынкы табигатьле булганга — алар бер-берен ярты сүздән аңлый алалар, педсовет утырышларында Мөнәвәрәне урынсызга рәнҗетсәләр, Сөнгать аны яклап чыга иде. Ятим үскәнгәме — моң-зарны күңеленә күп җыйган егет иде Сөнгать. Күзләре аның бик мәгънәле, рәнҗешне дә, сөенечне дә әллә каян әйтеп торалар; андый төпсез кара күзләр, үзгәнгә үтәрдәй итеп карый ала торган һәм дөньяның барлык сөенечен берьюлы җыеп елмая белә торган сабыр күзләр бер генә кешедә — Арслан Гобәйдуллинда гына бар иде. Әнә шул уртак охшашлыкны табу Мөнәвәрәнең күңел юанычына әйләнде, йөрәк ярасын киметергә, сагышларын баса төшәргә ярап куйды.

Сөнгать мәктәпкә башка укытучылардан алданрак килә, үзе җитәкли торган алтынчы «а» классының бүлмәсен карап чыга, аларның журналларын алып, кичәге көнге өлгерешләрен тикшерә, үз фәне өчен кәнә буена житәрлек күргәзмә әсбаплар әзерләп йөри һәм... Мөнәвәрәне көтә. Мөнәвәрә моны сизенә, Сөнгать белән япа-ялгызы очрашмас өчен, дәресләр башланыр алдыннан гына килергә тырыша, саф тойгыларын кеше теленә кертеп ямьсезлисе килми иде.

Сөнгатьнең булдыклылыгы көннән-көн ачыла барды. Яңа ел стенгазетасын ул бик күп шаржлар, карикатуралар, эпиграммалар белән бизәп чыгарды, яңа ел кичәсенә дөньяда булмаган мәзәк маскалар ясап алып килде. Шуларның барысы өстенә ул җыр җырларга да оста икән. Тик ул беркайчан да кычкырып җырламый, башын кыңгыр салып, акрын гына, уйланып кына җырлый, юк, ул хәтта җырламый да, гүя аның күңел тойгылары чак сизелерлек ачылган иреннәре арасыннан моң булып агылып кына торалар иде.

Сөнгать Мөнәвәрә эшли торган мәктәпкә, Күлле Чатыр авылына, үзган ел килде. Аның моңлы җырын Мөнәвәрә яңа ел кичәсендә ишетте.

һәм шул көннән башлап аның йөрәгендә Арслан белән янәшә Сөнгать образы да яши башлады.

Әйе, кичәге көнгә чаклы шулай иде. Әмма кичә, һич көтмәгәндә, җиде ел күрешми торганнан соң, яшьлек мәхәббәте белән кабат очрашу Мөнәвәрәнең моңлы күңелен айкап алды.

Бүген ул мәктәпкә янарып һәм сафланып, кичәге бик аз вакытлы, ифрат та кадерле очрашуын уйлап килде. Укытучылар бүлмәсе янында Сөнгатьне очраткач, уңайсызланып исәнләште. Дәрес биргән чакта, берничә мәртәбә Арсланны исенә төшерде, Сөнгатькә карата гаделсезлек эшләгән сыман тоеп, үз-үзен битәрләде.

Мәктәптән алар бергә кайттылар. Сөнгать, искерә төшкән дәү кара портфелен картларча култык астына кыстырып, баскыч төбендә аны көтеп тора иде.

— Мөнәвәрә, белмисезме, сезнең яктагы китапханә эшли микән бүген? — диде Сөнгать. Ул, гадәттәгечә, каушаган, тавышы да, моңсу кара күзләре дә бимазалырак иде.

— Белмим шул, бәлки, эшли торгандыр, — диде Мөнәвәрә, ачык кына җавап бирмичә.

— Бергә барсам, каршы килмәссезме?

Күңеленнән Сөнгатьнең бармавын бик теләсә дә, кырт кисеп сөйләшә торган гадәте булмаганга, Мөнәвәрә каршы килмәде. Алар сөйләшми генә янәшә атладылар. Мәктәптән чыккан бала-чага урамга сибелгән иде. Каршы очраганнары, укытучыларына юл биреп, читкә тайпылдылар, аларны куып җиткән Таһирҗан, бөтен урамга яңгыратып:

— Кайтабызмы? — дип дәшеп узды.

Көн күзләрне камаштырырдай кояшлы иде. Иртәнге бәллүр бозлар инде эреп юкка чыкканнар, иңкүлектән, Зәй тугайлары ягыннан дымсу җил исә башлаган; йорт буйларында, сыртларын кояшка куеп, сыерлар кызынып тора; карт-коры капка төпләрен көри, бала-чага гәрләвекләргә ермаклар ерып мәш килә — яз кояшы тереклек иясен үз яктысына чакырып чыгарган иде.

Китапханә яныннан узып киттеләр. Сөнгать анда керергә кирәклеген онытты, Мөнәвәрә аның исенә төшерергә уңайсызланды. Мөнәвәрәләр капкасы турысына җиткәч, тиз генә кире борылмакчы иде, капка төбендә кулын каш өстенә куеп аларны көтеп торган Мәйсәрә түтине күргәч, ихтыярсыз туктап калды.

— Исәнмесез, Мәйсәрә түти, таза-сау гына яшисезме? — дигән булды Сөнгать, сүзсез калмас өчен.

— Алланың биргәненә шөкер, үзеңдә ни хәлләр бар, улым? — диде Мәйсәрә түти, аның шулай дәшүенә күңеле булып.

Исәнләшү белән үк борылып китеп булмый бит инде. Юкса, Мәйсәрә түтинең: «Көпә-көндез бу тәти кош нишләп йөри әле минем кызым тирәсендә?» — дип уйлавы бар. Шул уй башына килү белән, Сөнгать каушады, китапханәне онытып китүенә үкенеп, әдәп өчен генә булса да, бераз сөйләшеп торырга булды. Ул арада Мөнәвәрә йортка ук кереп киткән, улы беләнме, кем беләндер сөйләшкән тавышы инде капканың тегге ягыннан ишетелә иде.

Мәйсәрә түти Сөнгать белән саубуллашырга ашыкмады. Җиләктәй яшь гомерен үзе дә япа-ялгыз үткәргәнлектән, Мөнәвәрәнең дә яшь-яшь көенә сагыш эчендә саргаюын теләми иде ул. Йокысыз яткан төннәрендә: «Йа раббем, минем балам кемнән ким, бир шуңа акыллы бер кияү», — дип, иң изге теләкләрен теләп ята иде. Ә монда асыл кош үзе килеп эләкте. Мәйсәрә түти, Сөнгатьнең сөйләшү рәвешләрен үк яратып:

— Кая ашыгасың, балам, әйдә, өйгә кер, өебез бик иркен, тормышыбызны күреп китәрсең, яңа өй салгач кергәнең юк бит әле, — диде.

— И, Мәйсәрә түти, өй котлап алып килгән күчтәнәчем юк шул минем, — диде Сөнгать, тагын да ныграк уңайсызланып.

— Нинди кучтәнәч ди ул. Кунак үзе — кучтәнәч. Хәзерге заманда бер генә нәрсәгә дә мохтаҗлык юк, ашыйм дисәң — ашы, киим дисәң — киеме... Юк, юк, булмаганны, синнән кем кучтәнәч өмет иткән. Еллар гына имин торсын, диген. Атың ничек әле? Ә, Сөнгатьмени, ә, ийе бит әле, Мөнәвәрә әйткәние шул. Сөнгатулла буласың инде, безнеңчәләп әйткәндә. Мөнәвәрә кызым белән бергә эшлисең бит әле, әйеме? Бик әйбәт, бирсен ходай. Әти-әниең бармы? Мондагымы? — дип, Мәйсәрә түти Сөнгатьнең тормышын, нәсел-нәсәбәсен дә сорашып алды. Ул арада үз балаларына да керешеп китте. — Бик уңдым кызларымнан, бик уңдым, — диде. — Каладагы Сәгыйдәм дә бик булыша, киявем Арслан да бик үз итә. Әле менә кичә нарушни машина яллап килгән кияү. Мөнәвәрәм эни дип өзгәләнеп тора, өрмәгән җиргә дә утыртмый инде менә, бик кече күңелле Мөнәвәрәм... — Мәйсәрә түти, оста ячы кебек, читләтеп-читләтеп кенә, кызын «булачак кияүгә» мактапмы-мактый. Аның да тавышы Мөнәвәрәнеке төсле йомшак, күңелне оетып, үз ягына аудара торган көйле тавыш. Кермәс җиреннән керергә туры килде Сөнгатькә.

Мөнәвәрә ул кадәресен үк көтмәгән иде, ул мәктәпкә киеп йөри торган платье-костюмын алыштырырга керешкән иде инде, капкадан әнисе белән сөйләшә-сөйләшә кереп килгән Сөнгатьне күргәч, каушап тиз генә гөлбәчкә йөгерде.

— Мөмкинме? — дип, башта Сөнгатьнең калынрак тавышы ишетелде, аңа: «Мөмкин булмыенча соң», — дип гөлдерәп кенә Мәйсәрә түти җавап бирде, аннары икәүләп, тупырдашып, өйгә үк килеп керделәр. Кергән кунакны куып чыгарып булмый: Мөнәвәрә самавыр кайнатырга, өстәл әзерләргә булды, ләкин Мәйсәрә түти аны самавырга якын да китермәде, әнә кунагың белән сөйләш, үзем карармын, үзем әзерләрмен дип, гөлбәч белән өстәл арасында ду килеп йөри башлады. Бер чыгуында Мөнәвәрә аның башында бүрек урынына өр-яңа шәлъяулык та күреп алгач, нишли бу әни, әллә, ходаем, мине кияүгә бирергә җыенамы дип, уңайсызланып уйлады.

Чәйнең бирәр чынаягын өчәү бергә эчтеләр. Аннары Мәйсәрә түти, юк йомышын бар итеп, ерак чишмәгә суга китеп барды. Әнвәр лапас астында, дөньясын онытып, кар көри, Миләүшәнең отряд сборы икән, ул атылып-бәрелеп кайтып керде дә, сумкасын бер почмакка ыргытып, бер сынык ипи белән колбаса кисәге генә алып, тагын чыгып йөгерде.

Мөнәвәрә белән Сөнгать табын янында икәүдән-икәү генә торып калдылар. Уңайсыз тынлык урнашты. Сөнгать сүзгә оста егет түгел иде, ул яңа өйнең сап-сары матчасына, тәрәзә төбендәге яран гөлләргә, почмактагы фикуска һәм ярты өйне алып торган зур мичкә күз төшереп алгач, алай гына да өйдәге уңайсыз тынлык бетмәгәч, тиледән туры хәбәр дигәндәй, эчендәгесен әйтте дә салды:

— Менә без икәү генә калдык тагын...

— Әйе шул... — диде Мөнәвәрә һәм кып-кызыл булып кызарынды. Күңеленнән ул Сөнгатьнең тизрәк китүен, аны бу авыр газаптан коткаруын теләп, әмма тегесе, үч иткәндәй, китәргә ашыкмый иде. Дөресен генә әйткәндә, аның Мөнәвәрәгә әйтер сүзе бар, әгәр ул аны менә хәзер Мөнәвәрә белән икәүдән-икәү генә, аулакта чакта әйтмәсә, гомер дә, үлгәндә дә әйтә алачак түгел. Мөнәвәрә моны сизенә һәм нәкъ менә шул сүзне ишетүдән, уттан курыккандай, курка иде. Акылы белән ул Сөнгатьнең әйбәт егет икәнен дә белә, аның ихласлыгын ихтирам да итә, әмма аңар Арслан белән бер генә очрашу, ярты сәгать кенә бергә утыру, хәтта бергә утыру түгел, күреп кенә калу да бетмәс-төкәнмәс бәхет китерә иде. Ни гомерләр үзен тыеп, хисләрен яшереп яшәде бит ул, сеңелесен күрер өчен генә булса да Арсланнарга бармады. Хисләренең сүнә баруы белән килешеп беткән иде инде ул. Истәлеккә әйләнеп барган хисне Арслан тагын чынга әйләндерде! Нигә шулай соң бу?

Нигә Арслан белән бер генә күрешү дә аның бар дөньясын айкап сала? Сөнгать кичә Арслан утырган урында утыра иде. Мөнәвәрә күңеленнән аларның икесен янәшә куеп карады. Кинәт ул бер хакыйкатькә төшенеп алды: Арслан көчле рухлы кеше, ул сине канат астына сыендыра, ул сине теләсә нинди бәладән коткара ала; хатын-кызга, бигрәк тә Мөнәвәрә кебек үтә нечкә күңелле, моңлы һәм ярдәмчесез кешегә бу бик мөһим иде. Сөнгать үзе өчен дә сүзен әйтә алмый, үзен дә яклый алыр дәрәҗәдә түгел.

Уңайсыз тынлык күңелне баса башлагач, Мөнәвәрә озын кара керфекләрен сирпеп, Сөнгатькә күтәрелеп карады. Сөнгатьнең күңелен яндырып алды бу караш, аның башында бер уй да, бер генә акыллы фикер дә калмады, теле аңкавына ябышты. Ул авыр итеп көрсенде дә, тагын, тиледән туры хәбәр дигәндәй:

— Кемнәр бәхетенә шулай чибәр булдың син, Мөнәвәрә? — диде.

Бу сүздән Мөнәвәрәнең бөтенләй кәефе китте. «Күзгә карап мактарлык примитив кешемени соң мин? — дип уйлады. — Арслан да булды кичә, андый сүз әйтмәде. Әйтәме соң! Табигать аңар күңелнең бик сизгерен биргән шул...»

Сөнгатьне җавапсыз калдыру аның әйткәннәрен чынга алу булыр иде.

— Сез мине уңайсыз хәлгә куясыз, Сөнгать, — диде Мөнәвәрә, елмаерга тырышып. — Дуслар алай сөйләшмиләр. Без бит дуслар, дөресме?

Әйтеп бетерүгә аның керфекләре тетрәнеп китте, Сөнгатькә хәтта алардан җил килеп бәрелгәндәй булды. Егет урынсыз сүз әйткәненә соң дәрәҗәдә үкенеп:

— Ярый, мин ни... нигә мин ни... — дип борын астыннан ботка пешереп алды да, гафу үтенеп, кайтып китте.

Мөнәвәрә ул киткәч, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, иркен сулап куйды. Сөнгатьнең портфелен култык астына кыстырып, картларча алга иелә төшеп, урамнан баруын тәрәзә аша озак кына карап торды, аннары сандыгын ачып, язгы пальтосын алырга, киемнәрен җилләтергә уйлады. Шулай да егетнең ихлас күңелдән әйткән сүзләрен киредән үзенә кайтарып бирү һәм аның нәүмизләнеп китеп баруы — күңел түрендә юшкын булып утырып калдылар. Нишли ала соң ул, нишли ала? Бәлки Сөнгать аңар, мин сине яратам, дип әйтергә килгәндер, бергә булыйк дип сүз башлавыдыр... Ләкин бит аның күңеле генә түгел, Мөнәвәрә күңеле дә бар бит әле...

Идәндәге палас өстендә утырган килеш, аякларын күлмәк итәге астына яшереп, сандыгын актарырга керешә; аңар язгы пальтосын алырга кирәк, пальто, үч иткәндәй, аста ук калган, хәзер бөтен сандыкның астын өскә китермичә аңа җитеп булырлык түгел иде. Актара торгач, ул мавыгып китте, киемнәрен кулына алып, аларның кайчан тегелгәнен, кайларда киеп йөргәнен күңеленнән барлый башлады. Күптәнге истәлекләре кузгалып, аны тәүге көче белән дулкынландырдылар. Йон кофтасының бер кесәсеннән конвертланган хат килеп чыкты. Мөнәвәрә, нидер сизенеп, конвертны тиз генә ертты да укый башлады. Хат Кәлимәтнең элекке комсомол секретаре Галимә Әсфәндияровага атап язылган, ләкин җибәрелми калган иде. Укыган саен, Мөнәвәрәнең йөрәге көчлерәк җилкенә, истәлекләре берсен-берсе кысрыклап, яңара башладылар.

«...Галимә апа, мин хәзер Кәрим белән аерылышу чигендә торам. Миңа аның белән кавышуның тарихын язып тору кирәкми, мин сезнең сүзегезгә ышанып, яратмаган кешемә тормышка чыктым. Тормыш! Ул нинди зур мәгънәле сүз, ләкин ул вакытта мин аңар бик җиңел караганмын, хәер, кыз вакытта бар кеше дә шулай буладыр, торып карамагач, каян белсең ди аны. Менә сез торып караган кеше идегез, сез димләгәч, мин риза булдым. Тормышыбызны гел якты итеп, бәхетле

итеп күз алдыма китердем. Киресенчә килеп чыкты. Кәрим белән җүнле-рәтле сүз сөйләшеп булмый, аның бит рухи дөньясы юк. Бар белгәне буровой да аракы. Биш-алты ел торып, безнең уртак тел таба алганыбыз да юк әле. Кайчагында күңелемә каһәрле уйлар да килә: ил өчен Кәримнең физик көче генә кирәк микәнни соң? Нигә аның рухи тормышы белән берәү дә кызыксынмый? Тагын шунысын әйтим: акча җәлләми, мин нәрсә алырга теләсәм дә каршы килми. Димәк, тормышның бөтен кызыгы акча дип карый. Дөресме бу? Миңа акча түгел, тормышны уртаклашып яшәүче кеше кирәк. Балаларыма чын әти булырдай кеше. Дөрес, аерылсам да мин андый кешене табармын дип уйламыйм, бер үк балаларга дөньяда ике ата булмыйдыр ул. Әгәр без аерылыша-нитә калсак, халык мине гаепләячәк, мин моны сизеп йөрим, кеше синең эчеңне ярып карый алмый бит ул. Ул тышкы күренештән чыгып кына эш йөртә. Ә тышкы күренеш начар түгел безнең.

Галимә апа, сезгә хат язуымның сәбәбе менә шул иде. Әйтмичә аерылсам, сез мине ачуланырсыз, гаепләрсез, дидем, безне кавыштыручы сез бит.

Соңгы үтенечем, зинһар, бу хакта газета материалына караган кебек карамагыз, эш кәгазьләрегез янына да теркәп куймагыз. Туганнарча киңәш сорап язган хат дип карагыз.

Сәлам белән — Мөнәвәрә. 16 сентябрь, 54 ел».

Мөнәвәрә хатны тәрәзә янында яктыга тотып укыды да, көрсенеп, конверты эченә кире тыкты. Конвертны кая куярга белмичә, кулында бераз әвәләгәч, кирәкле документлары саклана торган шкатулкага, Кәрим белән язылышкан таныклама кәгазе янына салып куйды.

Күптәнге көннәр, Кәлимәттә яшәгән хәсрәтле чаклар, энгер томанына уралып, күз алдына килделәр. Кәрим инде күптән җир куенында. Язмыш Галимә Әсфәндиярованы хезмәт баскычыннан күтәрә-күтәрә, Казан каласына чаклы илтеп җиткерде дә Кремльдә хөкүмәт йортына куйды. Аның исеме хатын-кыз бәйрәмнәрендә, Татарстанның туган көнендә өлкә газетасы битләрендә зур титуллар белән басылды. Һәм кинәт юкка чыкты. Баскыч түбәсе бик биек, анда тотынып тору өчен бик зур ихтыяр көче һәм рухи чыныккан булу кирәк, ахрысы, әзерлексез кешеләр анда озак тотынып тора алмыйлар, күрәсең...

Хат кузгаткан тойгыларын тәртипкә китермәкче булып, Мөнәвәрә комсомол секретаре Әсфәндиярованы, үзенең элекке димчесен искә төшерергә, аның күңелендә утырып калган сурәтен барларга теләде. Бик тонык, бик сүлпән иде ул сурәт, хат килеп чыкмаса, бәлки, инде бөтенләй дә онытылган булыр иде. Ә менә Кәрим аның каршысына зур булып, язмыш корбаны булып килеп басты.

Мөнәвәрә көннең калган ягын, арып хәлдән тайганчы, киемнәр җилләтеп, өй җыештырып, балаларының тамакларын туйдырып үткәрде. Гәүдәсен тота алмаслык дәрәҗәгә җитеп арыгач, урын өстенә ауды. Бүген үзен озата килгән Сөнгать турында уйлады. «Әгәр ул миңа тәкъдим ясаса, кияүгә чыгар идемме икән?» — дип уйлады. Уйлары нигәдер җавапсыз калдылар. Аның күз алдына бик тә якын, шул ук вакытта хыял иреше алмаслык ерак Арслан сурәте килеп басты. Ябалак кар яуган юл өстендә ничек очрашуларын, Арсланның ничек өздереп каравын, ләкин хисләрен сүз белән әйтмәвен, аның әнисе алдында ничек тыйнак һәм тыенкы булуын уйлап ятты. Күңелендәге сөенечне яз гына алып килмәгән, Арслан да алып килгән икән бит аның. Ул моны танымаска, үз-үзен алдарга юкка азаплана... Үзен бәхетле тоеп, елмаеп йоклап китте ул. Төшендә ул Арслан белән Сөнгатьне күрде. Рәхәт җылы яңгыр ява, тегеләр, кулга-кул тотынып, урамда йөриләр, өсләре манма су булган, имеш. Уянгач, мендәрен тотып карады, мендәре юеш, ул, димәк, төшендә елаган һәм хәзер дә әле елап ята иде...

*(Дәвамы бар.)*

## Ренат Харисов

# МУЛЛАНУР

1

Соңгы тапкыр нәрсә күргән Мулланурны?
Кеше күрсә — кайчан да бер әйтер иде.
Соңгы тапкыр нәрсә күргән Мулланурны?
Нәрсәнең соң болай каты хәтер биге?

Җир җиләге!
Синең хәтер кызыл төскә —
Кая тамды каны?
Ә син, болыт, мәңге-мәңге өстә —
Кая очты җаны?

Соңгы тапкыр нәрсә күргән Мулланурны?
Дар агачы?
Хәнҗәр очы?
Кургаш төше?..
Ник әйтмисең,
Табигатьнең һәр тузанын
Йолдыздай зур итеп карый алган кеше?!
Кая китте Казандай зур олы җаны?
Ил кебек зур тәнен ташлап кая ашты?
Син әйт, кеше,
Җан җан биргән шул мизгелдә
Иелмичә түзә алды кемнең башы?

Соңгы тапкыр нәрсә күргән Мулланурны?
Күбәләкме? Кырмыскамы? Балыкларны?
Ай яктысы? Төн карасы? Кояш нуры?
Кайсыгыз соң...
Соңгы тапкыр...
Күреп калды...
Мулланурны?..
Тарихка мин
Бирми торам бу сорауны —
Аннан җавап тиеш инде сораусыз да...
Ә син, күңел,
Мулланурның
Җәрәхәтле исән аңы булып сызла!..
Әлегә сызла!..

2

*(Мулланурны ату.)*

Бастырдылар.
Басты.
Кызганудан тетрәнде
Аяк асты.

4*

Бастырдылар,
Басты йөзләренә карап,
Керфекләре белән
Палачларны
Буш һавага кадап.
Әкрен генә күтәрелде кырык көпшә.
Һәм йомылды сиксән күзнең кырыгысы...
Ә ул торды
Җәя кебек иреннәре
Арасына уктай үткер җырын кысып.

Кырык палач
Эзләделәр бер йөрәкне,
Лупа итеп кан-сөремле мушкаларын...
Күрмәделәр,
Тапмадылар алар йөрәк,
Күрмәгәндәй,
Җирдә яшәп, бу җир шарын,
Төбәделәр маңгаена...
Аh, маңгае!
Җыерчык түгел — әнкәсенең ирен эзе...
Мулланурның укка әйләнгән керфекләре
Атылмыйча ничек тора икән түзеп?!.

«Башкаларның шунда иде бугай», — диеп,
Берсе әнә күкрәгенә көпшә төби...
Киерелеп куйды шунда Мулланурның
Керфекләре тамырында җәя җебе...
Яшергәндер,— дип,— йөрәген бармак очы,
Сул кулына төбәделәр әнә бишәү...
Сабый чәчен сыйпарга да өлгермәгән
Кулын аның биш көпшәнең күзе тишәр...

Атылып чыгар биш бармактан биш чишмә кан
Һәм кирегә — тәннән җиргә таба — агар.
Кара җиргә биш ярадай язылып калыр
Кара эшкә үлем таләп иткән карар...

Өстәлдәме,
Кесәдәме,
Куроктамы —
Үз ягына бөгелергә бармак әзер...
Сиксән колак тешсез авыз кебек ачылып
«Пли!» дигән канлы калҗа көтә хәзер...
Бу тынлыкка чыдамыйлар палачлар да —
Берничәсе бер-бер артлы тамак кыра.
Ә баш җәллад хәлсез тавышын ачар өчен
Кыз йөзедәй алсу алма ашап тора.

«Пли!»
Мулланурның
Укка әйләнгән керфекләре,
Иреннәре кысып торган үткер җыры
Палачларның
Йөрәгенә кадалдылар,
Каршы очкан
Кырык ядрә юлын ерып.

Гербарийга беркетелгән бөҗәкләр кук,
Барлык палач
Вакыт канатына кадакланды.

Ә Мулланур
Җиргә ауды.
Җирдә калды...

### 3

*(Мулланурны асу. Аркан монологы.)*

Мин бит аркан —
Елый да алмый калдым.
Яшим гарьләнеп.
Беләсезме,
Аркан елый ала
Бары бөгәрләнеп.
Мин ул чакта
Сузыла гына алдым...
Элмәк ясап
Ботак аркылы ыргыттылар —
Куркып качты төнге байгыш.
Яшь тамчысы кебек эленеп калдым —
Ләкин коры, котсыз һәм буш.

Күзе, кулы бәйләнгәнне
Минем аска китерделәр.
Мине — буш күз яшен —
Муенына кидерделәр.

Ак тәненә сыенып яттым,
Умрау сөяген яптым.
Тик ул никтер йөзен чытты,
Тәненә каз тәне чыкты.
«Большевикка шәп муенса!» —
Диде берсе, мине җайлап.
«Ашыгыгыз!» —
Дип кычкырды юан җайдак.

Күзе, кулы бәйләнгәне
Күкрәк киереп сулу алды,
Һәм тирә-юнь
Һавасыз калды...
Берсе иярне читкә типте,
Мин муенны буып алдым...
Барлык һава
Эчтә калды,
Палач, тончыгып, җиргә ауды,
Җайдак, тончыгып, җиргә ауды —
Тирә-юнь һавасыз калды,
Солдатлар да җиргә ауды...
Күзе, кулы бәйләнгәне
Басып калды.

Мин бит аркан.
Әлегәчә яшим гарьләнеп...
Муенын җылытмакчы идем —
Елан булдым бөгәрләнеп.
Будым...

## 4

*(Мулланурны суга батыру.)*

Бәйләделәр муенына таш —
«Так галстук, артык кысма!»
Су төбендә кулын уа
Үләксә ашаучы кысла.

Бәйләделәр аякларын —
«Төзәлсеннәр яраларың!..»
Су төбендә кара кысла
Чакырып алды балаларын...
Су тулганчы, авызына
Канлы чүпрәк тутырдылар...
Ә кыслалар шул вакытта
Кайчы кайрап утырдылар...
Бәйләделәр каерып кулын,
Беркеттеләр гәүдәсенә...
Авызларын ачып куйды
Кыслаларның һәммәсе дә...
Кансыз палачлар төркеме
Мулланурны суга атты...

Гәүдә дулкынга күмелгәч,
Идел суы кинәт артты,
Ташып чыкты ярларыннан,
Әйтерсең ай аңа батты.
Дулкын алып палачларның
Башын ташка бәреп ватты,
Ә Мулланур төпкә ятты.
Су төбенең өнен алып,
Кузгатып дуен бураны
Әле җанлы Мулланурны
Кысла өере урады.

Мәңге артка шуышуларын
Алар кинәт ташладылар,
Кайчыларын киереп ачып,
Кайчыларын киереп ачып
Арканнарга ташландылар.

Ә сүс аркан су сеңдереп,
Буар елан кебек катты...
Тук карынлы күк еландай
Идел акты,
Идел акты.

## 5

*(Мулланурның исән җаны.)*

Кортлар кимереп
Китапларга тишкән тишек
Вакытның үткәннәренә
Булды ишек.
Сораулардан торган яшен булып
Мин яшьнәдем.
Бөтен Болгарны йоткан тарих
Эндәшмәде.

Хәзер үзем әйтәм:
Каплап була кояш нурын,
Үтереп була һәр халыкның
Мулланурын,
Үтереп булмый
Үлемнәрдән туган җырын.

Мин сөйләдем өч үлемне —
Өч дәреслек.
Еладылар кортлар,
Җир карасын дер селкетеп.
Еладылар кошлар очкан чакта,
Канатларын ябына-ябына,
Дулкын елады,
Ярга абына-абына.

Үкси-үкси барысы әйтте:
— Мин,— дип,— күрдем:
— Мылтык үтерде,
— Дар үтерде,
— Су үтерде.
Ә мин әйтәм: ул исән:
Әгәр дә ипи теләнсәм
Арыш, бодай илендә,
Су теләнсәм телем салып
Идел-Чулман җирендә,
Калтыранcам мин суыктан
Каен, нарат илендә,
Тәрәзә рамын тыңласам
Мин читлек челтәренә,
Башым исәм ярым айга
Я шунда бер тәрегә,
Күзем белән һәр кешенең
Кесәсен кисеп калсам,
Каеш путалы гер тотып
Кабан бозына барсам,
«Чыңгылдый богауларым», — дип,
Кан яшьле шигырь язсам,
Стаканлап һава сатсам,
Я акча кебек аэсам,
Аның җаны
Миндә үле
дияр идем.

Тик
Җанын силгә биргән сулыш үләме?
Без бит җирдә силләр сулап киләбез.

Тик
Җанын суга биргән күз яшь үчәме?
Без Иделгә ятып дулкын эчәбез.

Тик
Җанын җиргә биргән ал кан череме?
Каннан икмәк шытканга бит тере без.

●

Хәрәкәттә безнең ан һәм безнең кан —
Мәңге исән синең җан,
Мулланур!..

**Нгуен Чунг Тхань,**

Вьетнам язучысы

# СА-НУ УРМАНЫ

ХИКӘЯ

...Бу хикәя 1966 елда Көньяк Вьетнамны азат итү милли фронты Президиумы тарафыннан Нгуен Динь Тиеу исемендәге премия белән бүләкләнде.



Авыл дошман тубының нәкъ ату радиусына урнашкан. Атышлар, гадәттә, тәүлеккә ике тапкыр: иртән яки кич, көндез сәгать уникеләрдә яки таң әтәчләре кычкырган вакытта була. Ә атылган һәр снаряд Са-ну тавы итәгенә, я булмаса зур елга ярына төшеп ярыла. Са-ну урманы — мәһабәт урман, андагы агачларның исәбе-хисабы юк. Тик рәхимсез сугыш гарасатлары аларның берсен дә кызганмый. Шуңа күрә урман агачларының күбесе, пычак белән кискәндәй, кырт өзелгәннәр, ә кайберләре соңгы тамчы каннарын коеп, җирдә аунап яталар. Урман һавасы яралы агачларның ширбәтле суыннан чыккан хуш ис белән тулган. Җәрәхәт алган агачлар тәненнән саркыган сагыз кояш кызуыннан кәүсә буйлап аска агып төшә. Ул бераз куелана төшкәч, коңгырт-сары төскә керә һәм балавыз сыман каты матдә белән каплана. Са-ну агачы — бик әрсез агач. Са-ну урманы кебек кояш нурларын комсызланып йота торган урманнар, ай-һай, бар микән дөньяда!

Яшь үсентеләрне рәхимсез сугыш гөрелтеләре яшәүдән мәхрүм иткәннәр. Аларның җәрәхәтләре тиз генә төзәлми, яра эзеннән озак вакыт үтә күренмәле су агып тора. Соңыннан, күп кан югалткан кеше сыман алар бер-бер артлы һәлак булалар.

Урманда башка агачлар да үсә. Ботаклары кеше биеклегедәй, куе бөдрә ылыслы агачлар бигрәк тә тиз үсәләр. Аларның кәүсәләре көннән-көн ныгый, шуңа күрә аларга инде ядрәләр куркыныч түгел.

Менә, шулай, өзлексез атылып, яраланып торган Са-ну урманы соңгы елларда тагын да куеланып, матурланып китте; туган җир туфрагына тамырларын ныграк һәм тирәнрәк җәйде, колачлары иксез-чиксез киңәйде һәм урман үз ышыгына бөтен авылны алды.

Әгәр Са-ну тавына менеп, ерак-еракларга күз салсаң, тирә-якта са-ну агачлары яшеллегенә чумган урман диңгезеннән башка берни дә күрмисең.

* * *

Өч ел рәттән Тху Азатлык армиясендә сугышты, шуңа карамастан аңа тик бүген генә туган-үскән авылына кайтырга рөхсәт иттеләр.

Тхуны кечкенә Хенг каршылады. Ул аны киткәндә дә озатып калган иде. Ул вакытта Хенг Тхуның биленнән генә иде... Ә хәзер аңа элек бер бәйләм утын да күтәреп кайта алмаган малай дип кем әйтер! Чүпрәк билбавын буып, ялангач көенчә олылар урман кискән җирдә буталып йөргән малай хәзер сиңа юл күрсәтсен әле! Җитмәсә, мылтыгы да бар кулында, шуңа ул үзен бик горур тота.

Тхуга туган яклар, әүвәлгедәй, якын һәм таныш. Бормаланып-сырмаланып маниока плантацияләре, су бананы куаклары һәм куе әрәмәлек белән капланган иске тар сукмак һаман шул таулар буйлап үтә. Аңа бөтенесе дә якын, бары да үз тоела. Шулай да, юл күрсәтүчедән башка, ул бу урыннардан үтә алмас иде. Чөнки борылыш саен үлем куркынычы бар, адым саен капкыннар, тирән чокыр-чакырлар һәм тозаклар куелган. Һәр куак артында сине винтовка көпшәләре, өстеңә ишелергә торган зур-зур таш кантарлары һәм авыр бүрәнәләр сагалый.

Иртә олыгайган Хенг — Со-мандагы авылдашларыдай, аз сүзле егет. Башында Азатлык армиясе солдаты бүләк иткән хәрби фуражка, курткасы тезләренә житкән, билендә иске генә билбау. Иңенә зур мылтык аскан, шуңардырмы, ул тәҗрибәле бер сугышчы кыяфәтендә. Ул кайвакыт артына борыла да каты сугышлар узган урыннарга күз төшерә һәм астыртын караш ташлап: «Я, Тху, кадерлем, бу турыда син ни әйтерсең?» — дигән сыман елмаеп куя.

Ә Тху, җавап бирәсе урында, я көлә, я башын гына селкә. Шул рәвешчә, алар Са-ну урманы юлыннан атлыйлар.

Бер чишмә янына килеп җиттеләр. Көмеш сулы тау чишмәсе бамбук улак буйлап ерак-еракларга агып китә. Хенг, туктап, болай ди:

— Аяк-кулларны юарга мөмкин, ә суын эчәргә ярамый. Югыйсә, Зит ападан шелтә алырбыз! Суны салкын көенчә эчәргә ярамый, ди ул.

Тху, елмаеп:

— Зит апаң әллә санитария дружинасындамы?

— Юк ла,— ди Хенг.— Беләсең килсә, Зит апа хәзер ячейка секретаре! Өстәвенә, саклану отрядында политрук та!

— Алай икән... Менә кая үрмәләгән диген, ә...

Тху су эчмәде. Каскасын салып, курткасын чеште дә улактагы суда башы белән битен генә юды. Салкын су аның яңакларын кызартып җибәрде.

— Димәк, менә кем булган синең Зит апаң! Ячейка секретаре диген, ә?!

Дөресен генә әйткәндә, Зитны ул хәзер күз алдына да китерә алмады. Апасы Май үлгәндә Зит бөтенләй кечкенә иде. Шуннан соң Тхуны армиягә алдылар. Ул вакытта Зитның өс киеме дә юк иде. Шуңа да салкын төннәрне ул күп вакыт йокламый уздыра иде, ә көндезләрен Май апасы белән дөге басуында эшләде. Эшләргә якты булсын өчен, Тху са-ну ботакларын җыеп учак якты, ә Зит авыр киледә дөге төйде. Соңыннан кабыктан арындырылган шул ук дөгене мискиләп киндер капчыкка салды. Тху аны авылга алып кайтты. Зит ул вакытта үзен бик тыныч тотты, шуңа күрә күзләре дә һәрвакыт коры була иде. Хәтта ул Май апасы үлгәндә дә еламады, ә бит бабай булып бабай хәтта күз яшьләрен тыя алмады.

* * *

Хенг аны ашыктырырга кереште:

— Тху абый, ашыгыйк! Салкын су белән озак шаярмыйлар... югыйсә бизгәк эләктерүең бар. Караңгы да төшеп килә. Китик!

Тху, башын да корытып тормыйча, Хенг артыннан ашыкты.

Алар юлга аркылы ауган юан агачка тап булдылар. Аны атлап чыгарга кирәк. Бер кырыйда партизаннардан калган озын окоп күренә. Тху армиягә киткәндә әле ул агач исән иде.

Тху кинәт туктап калды. Майны ул беренче тапкыр шушы урында очраткан иде түгелме соң?.. Икесе дә бер авылдан булганлыктан, алар бер-берсен бала чактан ук яхшы беләләр иде. Әниләре аларны аркасына асып йөрде. Төрмәдән кайтканда Тху Майны беренче тапкыр шушы урында очратты һәм шунда аның җиткән кыз булуын күрде. Май аның ярасыз кулларын үз кулына кысты. Хәтта ул бераз елап та алды. Кыз баланың бу — әдәп катыш назлану яшьләре иде. Боларны искә алганда Тху эсселе-суыклы булып китте, күз аллары караңгыланды, төрмәдәге кебек, тәненә бамбук сөңгеләр кадалгандай булды...

Кечкенә Хенг Тхуның борчылганын сизмәде, әлбәттә. Юлдагы агачны атлап чыкканда, ул аңа таба борылып, болай диде:

— Тху абый, син бу якларда күптәннән булганың юк... безнең юлларны онытып беткәнсеңдер инде...

Янә чокыр-чакырлы, тозаклар һәм киртәләр куелган бормалы-сырмалы сукмак сузылып китә. Боек йөзле Тху, тешен кысып, һаман алга атлый. Еракта-еракта ниндидер тавышлар ишетелә. Бу — авылдагы дөге төюнчеләрнең килсап тавышлары.

Тхуга моңарчы туган якларын сагыну сагышы белән тулы шушы тавыш җитешми иде. Штра [1] хатын-кызларының гомере, мактаулы, тынак хезмәте гел әнә шул тавыш астында кайнашып үтә. Шуңа күрә сабый чаклардан ишетеп үскән бу тавыш аңа якын һәм үз иде.

Тху дулкынлануын сиздермәскә тырышты, әмма йөрәге аның тынычтүгел иде. Авылга да ерак калмады. Шуңадырмы, ул саклану кагыйдәләрен дә онытты: Хенгны я узып китте, я тегесе, аны куып җитәргә теләп, артыннан чапты һәм:

— Тозак бар! Монда адым саен тозак! Саклан берүк! Монда бер дә элеккечә түгел! Минем арттан калма! — дип кычкырды.

Алар авылга килеп кергәндә, караңгы төшмәгән иде әле. Хенг, мылтыгына таянып, болай дип кычкырды:

— Э-э-эй! Тыңлагыз, тыңлагыз! Авылга кунак алып кайттым, кунак!

Өй тәрәзәләреннән гаҗәпсенгән шатлыклы йөзләр күренде. Дулкынланган авазлар ишетелде:

— И аллам!.. Үз бәндәләреңне ярлыка! Тху кайткан бит! Безнең Тхуыбыз кайткан! Тху энекәш кайткан! Яраткан Тхуыбыз! Әйе, ул кайткан! Әлбәттә — Тху бу!..

Түземсезрәкләре, бамбук баскычлардан да төшеп тормыйча, өйләрдән туп-туры җиргә сикерделәр. Ә өйләр җирдән шактый биек, субайлар өстендә. Әби-карчыклар: «Я ходай, Ленг әби дә төшеп килә»,— дип сөйләнеп баскычтан төшәләр.

Ә Ленг әбиләре сүзен дә әйтә алмый:

— И улым, күз нурым!.. Әниеңне бер кайтып күрим диденме?.. Рәхмәт инде, рәхмәт, улым!

Авыл халкы Тхуны уратып алды, ул аларның барын да яхшы хәтерли. Әнә, трубкасын кабып, Танг бабай да тора; тик трубкасының сабыгына бераз озая төшкән. Ул аны бәреп төшерелгән Америка вертолетының ватык деталеннән ясаган иде. Менә Пре агай, ул бераз олыгая төшкән. Әнә Блом апа, ул да бирешкән, чәченә бәс куна башлаган. Тегесе әнә Прой карчык, авызында бер теше дә калмаган бичараның... Әлбәттә, балалар да биредә, тик битләре, нишләптер, гел корым гына, са-ну төтенендә калганнар булса кирәк. Тукта, тукта... Мет бабай кайда соң? Тхуның күз карашы шунда ук җитди төс алды һәм, аның турында сорашмакчы булып, артына борылды. Ни күрсен, янында Мет бабай үзе

[1] Көньяк Вьетнамның Конг-тум яссы тавында яшәүче халык.

басып тора икән! Һәрвакыттагыча, елтыр кара сакалы аның күкрәген каплаган, шаян күзләреннән гүя очкын чәчелә, уң янагында узган сугыштан калган җәрәхәт эзе. Ә ялангач киң күкрәген Са-ну урманы диярсең!

Мет бабай Тхуны ярты адымга читкә этәрә дә, аңа баштанаяк карап чыга һәм куанычыннан шат елмаеп:

— Кайтып килдеңме, улым? Әллә автоматың да үзең белән инде!? Азатлык армиясе солдаты икәнең әллә каян күренеп тора! Тәртип бар! — ди.

Тху Мет бабасының бу сүзләрне шаяру катыш әйткәнен төшенә, әлбәттә. Мет бабай кешегә бервакытта да: «Егет икәнсең!» яки «Син дөрес эшләгәнсең!» димәс. Аның: «Тәртип бар!» сүзе — үзе югары мактау булып яңгырый.

Мет бабай сөйләгәндә, бар да тынып калалар, аның әйткән бер сүзе боерык булып яңгырый. Алтмыш тулып узуга карамастан, аның тавышы һәрвакыттагыча көр.

— Я, улым, командирларың күпмегә җибәрделәр? Бер төнгә дисеңме? Хуп! Бер төнгә җибәргәннәр икән — бер төн кунарсың. Ике төнгә булса — икене кунар идең. Боерык ул җиренә җиткереп үтәүне ярата. Бу төн миндә йокларсың!

Берәү дә каршы килмәде.

— Ярый, алайса хуп!— диде дә Мет бабай сүзен дәвам итте. — Ә хәзер барыгыз да өегезгә таралышыгыз! Караңгы да төште, ут кабызырга, ашарга әчәргә әзерләргә вакыт; ә бала-чагалар юынып кайтсыннар, тик бик шәпләп юынсыннар. Башка вакыт мин битләрендә корым-мазар күрмим! Ишетәсезме, тиз булыгыз! Кара син аларны, театр артистларыдай, битләрен буяп бетергәннәр. Яхшылап юынмаганнарыгызга миннән каты эләгер. Ишетегез аны! Тху, улым, син дә чишмәгә барып, аякларыңны ю. Чишмә юлын беләсеңдер бит? Әллә оныттыңмы? Кара аны, онытып кара, үзеңне урманда да кундырырмын...

Бу, әлбәттә, уен-көлке катыш әйтелгән сүзләр. Мет бабай Тхуның юл капчыгы белән автоматын алып, үзе үк аны чишмәгә озатып китте. Алар артыннан бер өер бала-чага да ияpдe. Чишмәгә килгән кызлар (Тху аларны танып белсә дә, исемнәрен хәтерли алмады) аларга бамбук улак янынан урын бирделәр. Курткасын салып, Тху улакта аркасын, аннары иңбашын һәм күкрәкләрен юды. Чишмә суына кече яшьтән үк күнеккән ул. Шуңа күрә чит-читләре кителгәләгән таш басма өстендә юынуы аңа бик рәхәт иде. Ә элек бу таш янына Мет бабай пычаклар кайрарга килеп йөрде.

Картның күз карашы Тхуның җәрәхәт тулы аркасына төште. Шунда аның яңакларыннан мөлдерәп ике бөртек яшь тамды. Кеше-мазар күрмәсен дигәндәй, ул күзләрен ашыгып учы белән сөртте. Тху моны сизмәде, ләкин балалар, күзләрен шардай ачып, аңа карап торалар иде.

Өй морҗаларыннан зәңгәр борау сыман төтен ургыла.

Мет бабай бүген табын хәзерләгәндә, тамыразык шулпасыннан соң, соуста пешерелгән балык та куйды. Мондый ашамлыкларны ул бик сирәк очракларда, ерактан кунаклар булганда гына әзерли иде. Тху юл капчыгыннан солдат паегын алып, Мет бабайга бер кашык тоз сузды.

— Безнең дә ярты галлон[1] чамасы тозыбыз бар, — диде Мет бабай аңа.— Ударниклар съездында Зит кызыбызны тоз белән бүләкләделәр. Ә ул аны барлык гаиләләргә өләшеп чыкты. Тик тозны һәммәсе дә авыруларга дип саклыйлар. Ә синекен авыз итеп карарга ярый.

Мет бабай тозны шулпага салмады, һәммәсе дә авыз итсен өчен, аны бөртекләп кенә өләште, ә кешеләр тансык тоз бөртекләрен авызларында бик озак суырдылар.

[1] Галлон — авырлык үлчәве берәмлеге.

Су бананына җиләк кушып пешерелгән дөге боткасы өстәлгә куелды. Карт, сөйләнә-сөйләнә, кулындагы мискиләргә шул дөгене салды:

— Быел уңыш, аллага шөкер, мул булды. Дөгебез дә янага җитәрлек. Шулай да бәрәкәтләп тотарга кирәк, һәр гаиләдә өч еллык азык запасы булырга тиеш. Син революция кешесе ич, Тху. Начальнигыгыз аңлаткандыр. Әйт син миңа: Америка көчекләрен тар-мар итәргә әле күп калдымы?

Бераздан Мет бабай сүзен башкага борды:

— Бармакларың һаман шул килешме, улым? Үсмиләр дәме? — Аның тавышы ачулы яңгырады: — Ә авылдашлар бу турыда беләләр микән? Белсәләр, хуп. Бармаклар бөтен булмасалар да, мылтык чакмасын басарга ярыйдыр ич? Син бүген Са-ну урманы аша үттең. Елга буйлап үттең, шулаймы? Димәк, Са-ну урманының яңадан тууын үз күзең белән күргәнсең. Са-ну кебек мәгърур агачларны җирнең кайсы почмагыннан таба аласың?! Ул агачның берсе ауса, аның урынына йөзесе аякка баса. Әйдә, дошманның көченнән килсә, Са-ну кебек урманны юкка чыгарып карасын әле!.. Аша, улым, аша! Штра халкы иккән дөге икәнен белеп аша. Ул безнең якларда иң яхшы дөге!

Аштан соң авылның җәмәгать өендә чаң каккан тавыш яңгырады. Өч сугу белән тавыш кисәк кенә тынып калды. Кешеләр тиз генә Мет бабай өенә җыелыштылар. Кыз-кыркыннар, кулларындагы факелларын сүндереп, баскыч буйлап өскә күтәрелделәр. Ә хатын-кызлар факеллары белән үк керделәр һәм Тхуны якын ук килеп карадылар. Күреп, күңелләре булганнары факелларын учакка ташладылар. Ишек алдында керә алмый калган картлар:

— Тху кая икән? Мет карт аны сыйлый алды микән? — дип кычкырыштылар.

Алар арасында бер әби-карчык тавышы да ишетелде:

— Әй, сез, Зит кызыма урын бирегез анда... Ай, рәхмәт төшкерләре. Кил, кызым, кил, утыр!

Тху шул вакыт башын күтәреп карады һәм үз каршында утырган Зитны күрде. Ул кинәт сискәнеп китте: аның күзенә Май күренгәндәй булды.

Зит үзенең әнисенә искиткеч охшаган. Элек аның борыны чак кына өскә күтәрелебрәк тора иде, хәзер, күрәсең, туп-туры, ясап куйган кебек. Куе каш астыннан янып торган зур күзләре дә тыныч һәм ачык карыйлар... Зит та Тхудан күз алмый, аңа текәлеп карап тора. Бераз вакыт узгач, Зит Тхуга болай дип эндәште:

— Сезнең, иптәш, документыгыз бармы?

Тху аны аңлап бетермәде:

— Нинди документ сорыйсыз бит?

— Командование биргән рөхсәт кәгазегез бармы? Ансыз авылга керү тыела. Урындагы комитетка шундый кәгазьләре булмаганнарны тоту хокукы бирелде.

Тху елмаеп куйды. Аның туган өен һәм авылдашларын күрү өчен бер көнгә генә частьтан качып кайттым, дип шаяртасы килде. Әмма батырчылыгы җитмәде. Зитның күзләре кырыс һәм бик таләпчән иде. Җитмәсә, башкалар да аңа гына карап торалар. Тху түш кесәсендәге кәгазьне алып, тиз генә Зитка сузды:

— Саклану отряды политругы! Мин сезнең карамакта...

Зит, документны алып, аны учак яктысында җентекләп карап чыкты. Кәгазь белән башкалар да кызыксындылар, кемдер андагы язуны иҗекләп укыды.

Зит аны өч кат укып чыкты.

Мет бабай, түземчә:

— Ничек, кызым, дөресме? Рөхсәт кәгазен әйтәм, дөресме? — дип сорады.

Кәгазь янадан хуҗасына кайтарылды. Зитның йөзендә елмаю балкыды:

— Дөрес. Командирның да имзасы бар. Тик, нигәдер, бер генә төнгә бирелгән? — Бу сорауга шунда үзе үк җавап кайтарды: — Артыгы кирәк тә түгел. Күреп сөйләшер өчен бер төне дә җиткән... Без, яшьләр, үзебез турында күбрәк уйлыйбыз шул!

Кечкенә бүлмә шау-шу белән тулды.

— Кара син аны, кәгазьгә командир үзе кул куйган диген!

— Эх, бер генә төнгә булган шул, иртәгә үк китәргә...

— Нигә алай бик азга гына икән?

Мет бабайның тавышы барысыннан да көчле яңгырады:

— Я, гөҗләмәгез... Бер төне дә җиткән! Исәнлегенә шөкер итегез дә май кабыгыз!

Бала-чагаларны торгызып, ул Тху янына ук барып утырды. Трубкасын каккалап, аны бамбук чырасы белән чистартты. Аннары сынаулы караш белән авылдашларын барлап чыкты. «Хуп! һәммәгез дә биредә икән, дәшми генә утырасыз».

Тышта вак яңгыр сибәли. Мет бабай тавышын күтәрмичә басынкы гына сөйли. Аны һәммәсе дә йотылып тыңлап торалар.

Мет бабай балаларга карап куя, алар тыннарын да алмыйча тыңлап утыралар.

— Менә Тху, безнең Тху туганыбыз шушы инде. Ул янадан безнең янда! — Мет бабай Тхуның иңбашына кулын куеп, сүзен тагын дәвам итте: — Минем Тху турында сөйләгәнем бар инде сезгә... Хәзер ул сезнең үз күз алдыгызда. Ул дошман яуларын туздырыр өчен Азатлык армиясе сафына киткән иде. Ата-анасы үлгәнгә шактый булды. Яшьтән үк тормыш авырлыгын күреп үсте, шулай да йөрәге, чишмә суыдай, саф калды. Мин сезгә аның тормыш юлын сөйләргә уйлыйм. Штра кешеләре, игътибар белән тыңлагыз мине. Туган якларына, туган иленә мәхәббәте булган һәркем моны колагына нык алсын. Мин үлсәм, минем сүзләремне яшь буынга тапшырсын.

Бүлмәдә тирән тынлык урнашты. Чылтырап аккан чишмә тавышы белән шыбырдап яңгыр явуы гына ишетелде.

Тху эндәшми. Ул уйчан күзләре белән төбәлеп, Мет бабайга караган. Төнге учак яктысында бу карт борынгы әкиятләрдәге ниндидер баһадирны хәтерләткән кебек. Тху да бала чагында әкиятләр тыңлап үсте. Аның карашы янә Зитка күчә. Буй-сыны белән ул нәкъ Май апасы! Тху Майны, үзе төрмәдән чыккач, урман аланындагы зур агач янында очраткан иде. Бу агач хәзер юлда аунап ята, партизаннар дошманны утка тоту өчен аны җайлы урын итеп файдаланганнар.

Зит та бабасын дикъкать белән тыңлый, зур күзләре тирән уйга чумган.

— Картлар барын да хәтерлиләр... Тик сугыш корбаннары гына бу турыда белми. Алар өчен исән калганнар хәтерләсен.

Ул вакытта безнең якларда америкалылар һәм дьемчылар хакимлек итә иде. Тыгылмаган җирләре юк иде мәлгуньнәрнең. Кыргый кабан дуңгызларыдай урман ботарлаудан башлары чыкмады, кеше канынннан кып-кызыл булган штыкларыннан кайнар пар чыгып торды. Штык очлары, башларындагы беретлары кебек, кып кызыл иде. Тху ул вакытта бидән генә иде әле. Ә өлгерлек, житезлек ягыннан тиеннәр белән ярышырлык малай иде. Әйе, картлар моны яхшы беләләр. Яшьләр дә онытмаган. Тху да хәтерлидер. Мет бабасының боты озынлыгындагы малай чакларын ул, мөгаен, онытмагандыр. Малай мәрхүмә анасыннан калган капчыкны асып йөрде. Капчыкның төбендә ике генә миски дөге, ә өстендә яшелчәләр була торган иде. Шул көенчә, йөгерек тиен сыман, ул партизаннарга азык ташыды. Тхудан кечерәк — Май

бар иде. Бармак очлары белән генә итәген күтәрер иде дә, кызылтүштәй, кыядан-кыяга сикереп, нечкә тавыш белән болай дип кычкырыр иде: «Тху-ху! Мине бераз көт! Тху-ху, көт инде ми-и-не!» Ә Тху аны: «Ник, Май, сөрән саласың! Нәрсәгә, урман куркытып, саескандай каркылдыйсың!» — дип орыша. Майның гарьләнүеннән елыйсы килә, тик ул тыелып кала, чөнки янадан Тхуның ачуы кабарудан курка иде.

Әйе, үткәннәр бар да хәтердә саклана. Әйтерсең, кичә генә булып узган кебек, һәммәсе дә истә, һәммәсе дә... Менә Тху һәм Май белән дә, Мет бабагыз һәм партиянең җаваплы работнигы белән дә шулай ук.

Аларның барысы да кичә генә булып узган кебек!

* * *

Са-ну урманында яшеренгән партиянең җаваплы работнигын Кюйет дип атыйлар иде. Американылар һәм дьемчылар монда килгәннән бирле һөҗүмсез янсә облавасыз калган бер көн дә булмады. Һәр төн урман яңгыратып дошман этләре өрде, аларга атыш тавышлары кушылды. Әмма Со-ман кешеләре түзделәр: биш елга сузылган оккупация чорында да бер партия работнигы да дошман кулыннан үтерелмәде. Са-ну урманы да үз оныкларына җил-янгыр тидермәде.

Яшеренгән кешеләргә азыкны башта яшьләр ташыды. Әшне сизенгәч, аларны да кулга ала башладылар. Башкаларга гыйбрәт булсын өчен, Сут энекәшне авыл кырыендагы инҗир агачына астылар. Оккупантлар: «Коммунистларны яшереп һәм ашатып яткырган һәркемне әнә шул агач башы көтә!» — дип куркыттылар. Яшьләргә урманда эшләү бөтенләй тыелды. Алар урынын картлар һәм карчыклар алыштырды. Революция эше өчен көрәшүчеләр элеккечә азык белән тәэмин ителеп тордылар. Мәкерле дошманга бу сер дә ачылды. Тиздән Нян карчык җәзалап үтерелде: аның кисеп алынган башын штык очына кадап авыл буйлап күтәреп йөрделәр.

Чират балаларга җитте. Тху белән Май алар арасында иң кыюлардан булдылар. Тху кырда эшләгәндә, азыкны Май илтте. Май — сенелесе Зит янында калганда, урманга Тху чапты.

Кайвакыт икәүләп бардылар, шунда йоклап та кайттылар, чөнки алар Кюйетны ялгызы гына урманда калдырырга куркалар иде. Тирәякта дошман, эзгә төшсәләр, аңа качарга да ярдәм итүче кеше юк бит...

Андый чакларда Кюйет, алар өчен борчылып, болай ди:

— Сөеклеләрем, ничек сез курыкмыйсыз? Сут абыегыз һәм Нян әбиегез кебек сезне дә тотып үтерерләр бит!

Тху утырган җиреннән сикереп тора да:

— Мет бабай безгә: җаваплы работник ул — партия бәрабәрендә, ә партия — ватанга тиң ул! — дип аңлатты, ди.

Май белән Тху укырга-язарга да башлап Кюйеттан өйрәнделәр. Ул аларга бамбуктан язу тактасы ясап бирде. Аны са-ну корымына буяп, өстенә куе сумала якты. Ә Тху Нгок-линь тавына барып, бер капчык ак балчык алып килде һәм ул язу акбурын алмаштырды. Ул тау бик ерак: анда барып-кайту өчен генә дә өч тәүлек вакыт кирәк. Май уку ягына Тхуга караганда күп сәләтле иде. Өч ай үтмәде, ул инде укырга-язарга өйрәнде, ә ике айдан соң ике урынлы саннарны кушарга һәм тапкырларга өйрәнеп җитте. Тхуның эшләре акрынрак барды, сабырлыгы җитенкерәми иде аның. Май уку буенча уза башласа, Тху, кызып китеп, бамбук тактаны бәрә дә вата иде. Шуннан инде көн буена чишмә буена китеп югала. Кюйет аны тынычландырырга тырыша, ә ул, кашларын җыерып, эндәшми тик утыра. Май иркәләнә башласа, Тху аны тотып кыйнардай була иде.

Көннәрдән бер көнне Май Тху янына килеп:

— Әгәр син дәрес укырга кайтмасаң, мин дә кайтмыйм... Беләсеңме, мин сиңа яңа такта ясадым! — диде.

Шул вакыт Тху очлы таш алып, үзенең башына китереп бәрде. Баштан кан китте. Ярый әле, Кюйет җәрәхәтне бәйләп өлгерде. Ә кич белән аны сынап карамакчы булды:

— Әгәр мине америкалылар, я дьемчылар үтерсә, син зур үсәрсең һәм мине алыштырырсың. Ә укый-яза белмәсәң, синнән нинди партия җитәкчесе чыгар соң? — диде.

Икенче көнне Тху Майны чакырып алды да, колагына шыпырт кына:

— Ыргаклы «о»ның әйтелешен аңлат әле... Аннары шуннан соңгы хәрефне, әнә теге — зур корсаклысын аңлатырсың! — диде.

Май, елмаюын ничек тә сиздермәскә тырышып, читкә борылды һәм үзе ясаган тактага «зур корсаклы» хәрефне язып куйды. Май сак булырга тырыша, шуңа күрә тавышы да аның бик ягымлы чыга иде:

— Син дәрес үзләштерергә оста икәнсең! Монысы менә «б» хәрефе, шулай бит?

— Әйе шул! Тик баш кына минем — тавык баш!..

Дөрес, Тху хәрефләрне тиз оныта, ә урманда юл эзләгәндә аннан да тапкыр кеше юк иде. Тху соңыннан Кюйетның якын ярдәмчесе булып китте, ә ул авыл партия комитетлары белән округ арасында элемтә алып бара иде. Тху иске сукмаклардан йөрергә бер дә яратмый. Чолганышта калса кала, аннан котылу җаен үзе таба. Ул биек агач башына менеп, тиз генә урынны билгели һәм дошманның борын астыннан ук чыгып китә. Ә елга аркылы чыгарга кирәксә, агымның иң көчле урынын сайлый. Аннары, лачын сыман суга атылып, күкрәге белән дулкыннарны ишәргә керешә. «Дошман мине агым җай җирдән эләктерергә чамалый, шарлавыклы урыннардан эзләргә, күрәсең, бер дә башына килми», — дип көлә ул.

Бервакыт шулай Кюйет округтагы иптәшләренә хат яза да аны илтеп тапшыруны Тхуга йөкли. Тху бу юлы суга да сикереп өлгерми кала, аркасына мылтык көпшәсе китереп терләр. Малай бөтенләй коелып төшә, авызындагы хатны да йотып өлгерә алмый.

Өч көн үткәч, Со-ман кешеләре аны, куллары бәйләнгән килеш, дошман солдатлары арасында күрәләр.

— Коммунистлар качкан җирне күрсәт, аннары сине җибәрәбез, — диләр аңа.

Авыл халкы да җыела. Мет бабай да йөгереп килеп җитә. Ул штра халкы телендә малайга:

— Кара аны, Тху, Со-ман авылының йөзенә кызыллык китерәсе булма! — ди.

Тху аңа карап күз кыса, ә Мет бабай:

— Хуп, алайса, улым! — ди.

Тхуның аркасын пычак белән телгәләп бетергән булалар.

Дошманнар аңа:

— Я, безгә коммунистларны күрсәт, малай актыгы! — дип җикерәләр.

Тху аларга:

— Башта кулымны чишегез, бәйләнгән кул белән ничек күрсәтим мин! — ди.

Солдатлар малайның кулын чишәләр. Ул бармагы белән корсагына төртә дә:

— Коммунист менә — мин ул! — ди.

Үзе асып йөргән капчык киңлегендә аркасыннан дошманнар тагын бер телем тире кисеп алалар. Пычак эзеннән кайнар каннар атылып чыга. Бераздан соң яра урыны, Са-ну сагызыдай, кара көеп кала.

Палачлар Тхуны авылга китерәләр. Май аңа ташлана да кочаклап үксеп елый башлый. Ә Тху орыша аны:

— Тукта елавыңнан! Укы син! Мине үтерсәләр, җитәкче булып син калырсың, — ди.

Өч елдан соң Тху Конг-тум төрмәсеннән кача. Аркасындагы җәрәхәтләре дә төзәлә. Төрмәдән кайтканда ул зур агач янында Майны очрата. Кыз аның белән кул биреп күрешкәндә, күзләреннән яшьләре мөлдерәп тама.

Аз гына вакыт эчендә Майның шундый танымаслык булып үсеп җитүенә Тхуның исе китә. Кич, караңгы төшү белән, Май аны авылга алып кайта. Ул төнне дә авыл халкы Мет бабай өенә җыела.

* * *

Мет бабайның тавышы көр яңгырады:

— Ул чакта да нәкъ менә бүгенге кебек иде. Без шушы бүлмәдә учак янында утыра идек. Бүгенге кебек яңгыр да сибәләп тора иде. Мин биредә, Тху әнә тегендә, ә Май — Зит утырган урында утырды. Шулай бит, Тху?

Мет бабайның хәтере — ат хәтере белән бер! Барын да хәтерли ул. Бары да ул сөйләгәнчә... Яңгыр да сибәләп тора иде, учактагы са-ну утыны да шулай яна иде. Тху Конг-тум төрмәсеннән качып кайткан төнне дә авыл халкы шушы бүлмәгә җыелды. Май да аңа хәзер, Зит кебек, күзен алмый карап утырды. Куе каш астындагы зур кара күзләре аның нәкъ Зитныкы сыман иде. Тик ул күзләр башкачарак, ягымлырак карагандыр. Ләкин шундый ук кискен һәм тыныч карый иде алар. Ул төнне Мет бабай берни дә сөйләмәде, тик болай дип кенә сорады:

— Май, кызым, Кюйетның язуын бир әле. Тху шул хатны укысын, ә без тыңлап торыйк... — диде.

Тху кулга алынгач, Кюйетны җиденче округка күчерделәр. Тик анда аны үлем сагалаган булган: юлда засадага эләгеп, авыр яра алгач, урманда үлеп кала. Үләр алдыннан ул Со-ман авылы халкына мондый хат язып калдыра:

«Минем булышчыларым, кадерле Май белән Тху! Со-ман авылындагы якташларым! Мин үләм. Ә сез озак яшәгез. Күп итеп корал хәзерләгез, сөңгеләр, уклар һәм пычаклар ясагыз, аларны дошман тапмаслык урынга, урманга яшерегез. Килер бер көн, шунда ул корал сезгә нык ярдәм итәр. Ә Тхуга килгәндә, ул инде күп нәрсәгә өйрәнде һәм алдагы көндә минем эшемне дәвам иттерер...»

Әйе, ул вакытта да бүлмәдә кеше күп иде. Танг бабай, Пре энекәш, Блом сеңелкәш, Прой түти, Ленг агай... Бүген тик шулардан Май гына арабызда юк.

Без бу хатны укып чыгу белән барыбыз да факеллар яндырып, урманга корал яшерелгән җиргә юнәлдек. Тху моннан өч ел элек ак балчык алып кайткан Нгок-линь тавы башыннан корал кайрау өчен кайрак ташлар җыйды. Андый ташлар Нгок-линь тавында йөз сугыштан да артып калырлык иде!

... Авыл халкы төннәр буе корал чүкеп, корал кайрады. Көндезләрен Мет бабай аларны кыр эшенә алып китте, алар басуда манион һәм су бананы утырттылар.

Ләкин Дак-ха фортындагы дошман со-манлыларның корал әзерләвен сизенеп кала. Басуда эшнең кызып җиткән чагы була. Җитмәсә, Май белән Тхуның яңа гына балалары туган чак. Менә шундый көннәрнең берсендә авылны дошманнар уратып ала. Аларның атаманы — кайчандыр Тхуны газаплаган кеше — Зук була. Башына кан төсендә кызыл берет кигән, ә үзе бәйдән ычкынган котырган эттәй бертуктаусыз кычкыра да кычкыра:

— Тху янадан таныш эшенә керешкән икән! Бу фәкать аның гына эше, башка беркемнеке дә түгел! Әгәр бу юлбарысны тотып алмасаң, бөтен тирә-якның астын өскә айкар!

Яшьләр, Мет бабай белән Тхуга иярен, урманга качып өлгерәләр. Алар авылдан ерак булмаган тау куышларына, куе әрәмәлекләргә яшеренәләр. Дошманнар аларны авылда дүрт тәүлек буена көтә. Авыл халкын мыскыллап, төрлечә көләләр. Тирә-юньдә шау-шу, елау авазлары яңгырап тора. Кулына револьвер тоткан Зук:

— Авылга кайтмаганнарның берсе дә исән калмаячак, эттәй атып үтерәчәкбез аларны! — дип, һәркемне куркытып йөри. Авылга чыгарга беркемгә рөхсәт ителми. Тик кечкенә Зит, житез кәлтәдәй, төнлә белән урмандагыларга ашарга илтеп кайта. Ә дүртенче көнне аның да эзенә төшәләр һәм тотып алалар. Ишек алдына бастырып, аңа өзлексез ата башлыйлар. Ядрәләр баш очыннан гына сызгырып үтә. Башта ул аткан саен кычкыра, соңыннан хәрәкәтсез бер урында катып кала, ә үзенең хәтта «ыһ» дигән тавышы да чыкмый. Ул үзенә төбәлгән автомат, мылтык көпшәсенә карап, секунд саен үлем көтә, аткан саен ябык гәүдәсе сиртмәдәй киерелә, шуңа карамастан, палачлар алдында сер бирми.

Кечкенә кыз баладан бер сүз алырга да көче житмәгән Зук иң соңгы карарга килә: ул Майны тотып алырга боерык бирә.

— Балалы ана юлбарысны кулга төшерсәк, ата юлбарыс килми калмас! — ди ул.

Бу сүзләрне Тху да ишетә. Ул чишмә янындагы инжир агачына яшеренгән була. Агач башыннан аңа мәйданданиләр булуы бик ачык күренә. Солдатлар хатыны Майны сөйрәп китергәндә, Тху, өзгәләнеп, агач ботакларына ябыша. Май аркасына йоклаган баласын аскан, ә аңа, күп булса, бер ай чамасы иде. Шулай да кешеләр аның турында: нәкъ әткәсе инде, диләр иде... Тху аңа әчке күлмәкләр алырга да өлгерми калды, курткасын ерткалап, әнисе аны иске-моски чүпрәккә төреп йөртте.

— Я, шакшы коммунист хатыны, иреңне кая яшердең? Әйт тизрәк! — дип кычкырды Зук.

Май, жанын кадерле йөген аркасыннан төшереп, дәшми-тынмый Зукка карап катты.

— Ник дәшмисең, албасты хатыны! — дип жикерде янә Зук һәм солдатларга: — Тимергә бастырыгыз үзен! — дип боерык бирде.

Солдатларның арада бер иң юаны начальнигына карап алды да, кипшенгән иреннәрен ялап, юан тимер чыбык белән Майның баш сөягенә китереп сыптырды. Май гөрс итеп жиргә ауды һәм баласын күкрәгенә дә алырга өлгермәде, сугу яңадан кабатланды.

— Кая Тху, әйт тизрәк!

Өченче кат сукканда аның күкрәгенә туры килде. Май шулай да сабыйны тиз генә аркасына яшереп өлгерде. Палач кулындагы тимер камчы тагын берничә тапкыр чыжлады. Ана сабыйны һаман күкрәгенә кочты. Сугылган чыбык саны ишәйгәннән-ишәя барды. Май инде кычкыра да алмый. Кинәт бала чырр... итеп куя һәм шуның белән тыны да бетә. Юан тимер чыбык бу юлы ике гомерне өзә. Тху агач башыннан жиргә атыла. Үзе дә белмәстән, берничә жимеш өзеп алып, авызына каба. Дошманга ташланырга дигәндә, Мет картның көчле куллары аны тотып кала:

— Кирәк түгел, Тху!.. Кирәкми! Мин үзем...

Тху аны читкә этәреп жибәрә.

— Тху...

Тху артына әйләнеп карый. Мет карт аптырап кала: аның күзләре янып торган факел кебек! Мет карт аны тоткарламый... Тху тиздән палачлар арасында була. Зук каядыр китәргә ашыга. Чакма тавышлары

ишетелеп кала. Тху һушсыз булып Май өстенә ава, үле баласын күкрәгенә кыса.

— Кеше ашаучы бәдбәхетләр! Сезгә Тху кирәкме? Менә ул, алдыгызда!

Бу урында Мет бабайның тавышы көчсезләнеп калды. Күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып, үзен кулга алды, сүзен дәвам итте:

— Тху сөекле хатынын да, газиз баласын да югалтты. Палач Майның эченә суккан икән, шуңа күрә ул, аның жуеп, баланы яшерә алмый калган. Хәтерендәдер, Тху, алар сине тотып бәйләделәр, ә кулыңда корал да юк иде. Мин бит барын да агач башыннан күреп тордым. Сине лиана сабакларына чорнадылар. Ләкин ярдәм итә алмадым, мин дә коралсыз идем. Тиз генә урманга — яшьләр янына чаптым. Без барыбыз да сөңге һәм пычаклар белән коралландык. Сез моны беркайчан да онытасы булмагыз, кешеләр... Хәтерегездә саклагыз! Бу турыда танышларыгызга сөйләгез. Дошман кулында — автомат, безнең кулда — сөңге!.. Лианалар белән чорнап бәйләнгән Тхуны жәмәгать йортына кертеп яптылар да ишегенә йозак салдылар, ә үзләре Брой өенә кереп дуңгыз ите тыгынырга керештеләр. Тху бәйләнгән килеш шулай ята бирде. Тышта караңгы төшеп килә, ә ул бу арада нәрсә булып узуын һаман башына китерә алмый. Монда ничек килеп эләктем дип гаҗәпсенә. Үз-үзенә ул: «Сабый үлде, Май үлде, тиздә үзем дә үләм. Житәкче булып кем калыр икән? Партия сугышка чакырып мөрәҗәгать иткәндә, Со-ман халкын кем җитәкләп барыр? Мет бабай карт инде. Тукта, яшьләр бар ич! Зит үсеп җитәр. Ул чыдам күренә, бер дә бирешерлек түгел. Шулай булгач, артык борчылырга урын юк. Тик шунысы аяныч, мин, Тху, коралга тотынган көнгә кадәр яши алмам...» — дип сөйләнә.

* * *

Зук Тхуны үтерергә ашыкмады. Элек ул жәмәгать өендә учак яктырды, аннары авыл кешеләренең берсен дә калдырмыйча шунда җыйды. Зук, Тхуга якын ук килеп, болай диде:

— Димәк, корал әзерлисез? Сөңгеләр, пычаклар кайрыйсыз? Ярый... Коралга тотынудан элек, ахыры ни белән бетәсен уйладың микән син?— Зук, халыкка карап: — Менә сезнең алда Тху ята. Хәзер аның кулларына күз салыгыз... — диде.

Зук баягы юан палачка ишарә ясады. Бары да алдан хәзерләп куелган. Палач са-ну сагызы сеңдерелгән чүпрәк алып, Тхуның ун бармагына да аны тыгыз итеп урап чыкты. Аннары факелны алды. Зук аңа:

— Бир әле үземә! — дип кычкырды.

Тхуның тавыш-тыны чыкмый. Нәфрәтләнеп янган күзләре Зукка төбәлгән иде. Ә Зук мыскыллап көлә генә, ул кулындагы дөрләп янган факелны Тхуның йөзенә үк китереп терәде.

— Я, коралга үрелгән бу кызылның борын асты кипкән микән? Мескеннәр сез! Сез кулыгызга сөңге алыр өчен тумаган! Хыял да итмәгез бу турыда!

Тхуның әүвәл бер бармагы, аннары икенчесе, өченчесе дөрләп яна башлый. Са-ну сагызы бензиндәй гөжләп яна. Тиздән Тхуның ун бармагы да янган факелга әверелә. Ул ут белән камалган күзләрен бер ача, бер йома. Бармаклары түгел, гүя эчтә йөрәк үзе яна. Авыз-борынына ачы төтен тыгыла, тешләгән иреннәреннән кан ургый, шулай да ул эндәшми, түзә. Кюйет иптәш: «Коммунист кеше сынатмый, дошманнар алдында үзен үзе кимсетми!» — дип юкка әйтмәгән. Тхуның да дошманнары алдында үзен хурлыкка калдырасы килми. Дошманнар аның «әһ» дигән тавышын да ишетмәделәр. «Эчем тулы ут... Эчтә бөтенесе яна!

Кадерле Кюйет иптәш! Мин тереләй янам, яныр үләм ич! Юк, юк! Барыбер сынатмам, сынатмам барыбер!..»

Зук эче катып кәлә. Картлар урыннарыннан сикереп торалар, солдатлар аларны яңадан үз урыннарына утырталар.

Урам яктан ниндидер тавышлар ишетелә. Тху ыңгырашкандай итә. Таныш тавышлар янучының ыңгырашуына бердәнбер дәва чарасы була.

Шул чак Мет бабайның дәһшәтле гәүдәсе күренеп кала:

— Турагыз, телгәләгез этләрне! Берсе дә исән торып калмасын!

Мет бабай бүлмәгә атыла. Аның кулында сөнге. Зук инде идәндә аунап ята. Яшьләр дә биредә, аларның кулларында Тху алып кайткан кайракта чарланган пычаклар.

Брой нәрсәдер эндәшә:

— Тху, Тху! Аңына килдеңме? Кара, без аларны кырып бетердек. Унысын берьюлы! Күрәсеңме безнең сөнге-пычакларыбызны!

Тхуның бармаклары күмерләнеп калганнар. Учак һаман котырынып яна. Идәндә дошман мәетләре аунап ята.

Мет бабай, сөңгесенә таянып:

— Я, башлавын хәерле сәгатьтә башладык,— диде.— Хәзер инде өйләрегезгә таралыгыз, ут кабызыгыз һәм яңадан бердәм рәвештә кулларга корал алыйк. Авылны чокыр-чакырлар, тозаклар белән уратып алыйк! Аны бирелмәс крепость ясыйк.

Чаң тавышлары ишетелде.

Са-ну тау итәгендә төне буе кешеләр тавышы ишетелеп торды, дөрләп учаклар янды.

... Кешеләр төн буена эшләделәр. Яңгыр көчәйгәннән-көчәя барды.

Мет бабай горур караш белән авылдашларын күзәтте.

— Менә, шулай, хикәям дә тәмам. Со-ман авылы ул төнне кулына корал алды һәм шуннан бирле кулыннан корал төшкәне юк. Тху, кулларны төзәлгәч, армиягә китте. Аның хәзер ун бармагында да берәр буыны юк. Ләкин бу аңа хәнҗәр тотарга да, мылтыктан атарга да комачауламый. Тху революцияне дә шул куллар белән каршылады. Нгоклинь аръягында да зуклар бар. Вьетнам халкы мондый зукларны дөмектерү өчен хәзер яңадан кулына корал алды. Безнең авыл аларга ярдәмгә Тхуны җибәрде. Тху, син озак кайтмый тордың. Кызлар үсеп килә, ә егетләребез юк та юк... Ярар, сүземне тәмамлыйм. Хәзер сүз, Тху улым, сиңа бирелә. Туган яклардан киткәч, өч ел буенаниләр күрдең, ниләр ишеттең, ничек яшәдең? Туган илебезнең, туган авылыбызның данын ничек сакладың, ничә янкины, күпме дьемчыны теге дөньяга олактырдың,— шулар турында сөйлә син безгә!

* * *

Тху, уйчан гына, учак алдына килеп басты. «Нәрсә сөйләргә соң? Ә, сөйләсәң, сүз күп...»

— Хөрмәтле авылдашлар! Хөрмәтле Мет бабай! Мин бит Зукны очраттым!

— Кайда ул?

— Бер фортта.

— Дөмектердеңме соң?

— Әлбәттә!

— Шул кирәк мәртәткә! Ә ничек, пуля җибәрдеңме?

— Юк.

— Ничек?..

Тху, автоматын салып, аны салмак кына итеп стенага сөяп куйды.

— Менә ничек булды. Бер фортка һөҗүм итеп, андагы солдатларның бөтенесен дә кырып бетердек...

— Бөтенесен дәме?

— Һәммәсен дә... Тик берәү генә калган иде, подвалга качкан, юньсез! Аның аннан бер дә чыгасы килми икән! Гранаталар да ыргыттык, чыкмагач чыкмый бит! Командирыбыз безгә: «Кем аска төшә?» — дип мөрәҗәгать итте. Уйлап тормадым: «Үзем!» — дидем. Аста дөм караңгы. Шулай да тегене эзләп таптым. Атарга да маташып карады, барып чыкмады, тиз коралсызландырдым. Җиргә егып салмакчы булам, юк, булдырып булмый, авыр, каһәрен! Тезләрем белән җиргә бастырып кыстым да кесә фонарен кабыздым. Ни күзем белән күрим, алдымда Зук тора.

— Я, дим, мин әйтәм... Мине танийсыңмы, Зук, дим?

Баш чайкый. Янәсе, танымый...

— Кулларыма кара, — дим. — Оныттыңмыни? Күр, корал тотарга гына ярый алар!

Күзләрен миннән яшермәкче була.

Шуннан мин:

— Кара, хәзер мылтыгым да, пычагым да бар. Ләкин сина пуля әрәм итмим, пычагымны да пычратмыйм. Мин сине, Зук, үзең гариплэткән шушы кулларым белән үтерәм. Эт кебек буып үтерәм!

— Будыңмы? — дип сорый Зит.

— Әйе.

— Шул Зукмы соң ул?

— Әлбәттә, шул... Хәер, зуклар алар, көчек балаларыдай, бер-берсенә бик охшаганнар!

Мет бабай аягүрә торып басты да Тхуның иңнәренә авыр кулын салды:

— Димәк, эшләр хуп, улым! — ди, ә үзе көлә.

Бүлмә эче яңадан җанланып китә.

* * *

Тху иртә белән китте. Аны Мет бабай белән Зит озата бардылар. Юлда барганда алар төн эчендә тагын да берничә са-ну агачының җәрәхәтләнүен күрделәр. Яра эзеннән саркыган сагыз, кояш нурлары яктысында җемелдәп, сары май сыман балавызга әверелә иде.

Яшь са-ну агачлары һаман югарыга үрлиләр. Юлдагы кешеләрнең карашы аларга төбәлгән. Әйләнә-тирә гел урман, ә са-ну агачларының очы да, кырые да күренми.

ӘДХӘТ СИНЕГУЛОВ тәрҗемәсе.

# Равил Фәйзуллин

●

Балачактан туры
без көрәшкә кердек.
Бездән көлделәр,
без кайтарып көлдек!
Без тәүге кат килдек.
Без тәүге кат күрдек, —
дөнья гаҗәп икән!
Мәйдан олы икән:
буының ныкмы дип
сорап тормый икән...

Канун, гадәтләрне
чыккан өчен атлап,
кире беткән чиру
китмәк булды таптап.

Кайсы тетәм, диде,
кайсы өтәм, диде,
искелек: өереп
эзгә кертәм, диде.
Ә без карыштык.

«Тамак, өс кенә —
безнең җанга, дидек, —
булыр кечкенә!»
Ә без көрәштек
нәни йөрәк белән!
Ышану дигән
бөек терәк белән!

Ашканда, чапканда
хөрлеккә йөз төбәп,
булды мизгелләр
капландык йөзтүбән...
Тик тордык янәдән
мең артык көч белән!
Ирлекне расларга
Эш белән! Эш белән!

Балачактан туры
без мәйданга кердек,
Без — үтә гайрәтле,
гаҗәп сабый идек.
Яшь күкрәккә ук
тиз кадала икән,
тик яшь тән барыбер
тиз янара икән.
Яшь кече, уй олы,
кайчак әрнү җанда.
Әмма шөкер —
хыял
исән-аман алда!

●

Ишетәсеңме,
әллә җил бу?
«Янсаң хөрлек
көрәшендә,
я кылычтай
калсаң сынып, —
офтанма бер дә!
Заманалар
үзе килер
юксынып...»
Җаныңныңваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.

Ә бит бар Кешеләр —
шәхесен ватмаган,
хаклыкны сатмаган,
вөҗданны саклаган.
Әйткәннәр: тарихтан
түгелсәм түгеләм,
изелсәм изеләм, —
әмма дә бөгелмәм!

Үзләре сеңсә дә,
рухлары калыккан.
Әнә шулар үлеме
җан өрә халыкка.

...Асылыңны яшереп
кыланма ни генә, —
буыннар хәтерендә
бары да чигелә!

Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга...

I

Күпсенмə, күк!
Дөрес, без күп...
Мəңгелек булсак та
гомерсез без,
болытың күк.
Күпсенмə, күк!

2

Сəерсең, дисең, яши
белмисең шул бер дə!
Мин бит җиргə яңа килдем,
һəм күпмегə генə!

Ə шулай да күпме сукмак,
дус, дошманым илдə!
Ə бит үзем яңа килдем,
һəм күпмегə генə...

3

Мəңгегə яратам димим.
Чөнки белəм,
бер көн китəчəкмен үзем...
Тизме, соңмы?

Мəңгелегем дисең еш кына
Чын яратып, чын күңелдəн.
Шул мəл карыйм да сиңа
моңсу гына көлемсерим.

4

Яктыга төшə күз, акка...
Күңел һаман алгысына
матурлыкның алгысына.

Сөю хисе меңəү икəн,
ə мин үзем берəү икəн.
Акыл моны белə кебек,
ə соң йөрəк белə микəн?
Ə соң үзем белəм микəн?

Яктыга төшə күз, акка,
күңел һаман алгысына
матурлыкның алгысына...

5

Күпмегə тулды тəүбəлəр!
Кирəккəме? Кирəккə...
Ə тəүбəдəн ни җиңеллек
имгəтелгəн йөрəккə?

Тəүбə — дəва! Көн дə тəүбə!
Җанны тынычландырам!..
Чынында йөрəккə кат-кат
сүтмəскə кəфен сарам...

6

Ул көннəрне инде даулап булмый,
сагынып кына була.
Сөю ни икəнен белми, гомрең узса,
каплан да бер ела.

Сүнгəн еллар исəбенчə тезеп
кара шəмнəр кабыз.
Ку кешелəрне! Хет тынлыкта кал, —
син, барыбер ялгыз...

Ул елларны инде даулап булмый,
сагынып кына була.
Үткəн беeклеккə кайтып булмый, —
табынып кына була...

●

(Карт шагыйрь)

Шəфəкълəр алсу-алсу.
Дөньялар ямансу.

Әй күклəр зəңгəр, зəңгəр!
Күзлəрдə яшьлəр, яшьлəр...
Ни кичкəнбез, ни уйда без
бик аз белəсез, яшьлəр.

Әй җирлəр яшел, яшел!
Күңелдə сагыш, сагыш...

Кем яд итəр үзегезне
Сез безне онытсагыз?..

Әй сулар ярсу-ярсу!
Эчлəрдə ялкын, ялкын...
Без китəбез, кала өмет,
акларсызмы ил хакын?..

Шəфəкълəр алсу-алсу...

●

«Хакыйкать ул — авыр.
Авырлыгын шунын белү —
җицеллек тә җанга!» —
дия иден, остаз.

Мена үлдең дә.
Бу — хакыйкать.
Моның авырлыгын белү —
тагын мең-мең авыр...

Әй, остаз...

●

Сөю көчле иманнан!
Чорнаса мәхәббәт — ялкын —
котылуың юк аннан!

Әхлак кануннарын көйләп,
тукысалар да туганнан,
Яз һәм Яшьлеккә вәгазь ни? —
Сөю көчле иманнан!

Яшен, күкрәүләр тын кала
ярсу хис ташса җаннан.
Җилләр калтырап кабатлый:
сөю көчле иманнан!

Кабынса мәхәббәт уты,
котылуың юк аннан!

●

Теләге бәхеттә иде,
хыялы тәхеттә иде,
йөргәне — бәрхеттә...

Моржага кош оялыймы!
Бәхет тә шулай икән:

төкергән тәхетенә!
Теләге иде бәхеттә,
хыялы иде тәхеттә;
хәзер ята ләхеттә,
тәне, дөрес, бәрхеттә...

●

Хәерлегә булсын,
син дә киттең...

Аяз көндә яшен димим
бу эшеңне,
әмма
арттан бәргән сөңге кебек булды
бу адымың.
Тик мәлҗерәмәдем,
йөзем дә бозылмады,
сабыр, горур булдым.

Күрәсең, олыгаела,
күрәсең, күрелә төрлесен...
Ни дисәң дә
минем дә бит инде
мәңгелеккә — кайтмас киткән
дусларым бар...
Ә болай киткәннәр —
исәннәр күпме!
Һәркайсының үз дөньясы,
үз сукмагы, үз түбәсе.
Күбесенең
артык тыныч,
артык тыйнак,
аквариум — бәләкәй тормыш.
Кыскасы —
яшьлеккә хыянәт!

Оят
антлардан,
хатлардан,
серләрдән...

Хәерлегә булсын,
ниятләгәч,
китүең яхшы.
Мыштым качу урынына
ирчә дулап китү
айбәтрәк булыр иде дә бит...

Бераүгә дә
«әлек дус идек тә,
хәзер сүндек», димәм.
Кемнәрнеңдер
дуслыклары зурлыгына
шик төшерүем бар.
Синең хакта
яман бер сүз әйтмәм,
яки сөйләмәм бөтенләй.
Тыныч бул.

Хәерлегә булсын,
син дә киттең!..
Хәерлегә булсын,
хәерлегә.

## Максуд Сөндекле

### Икмәк валчыгы

Кара икмәк кадерен белергә
Безне бабай
Яшьтән өйрәтте,
Төшермәскә аяк астына,
Ватып ашамаска икмәкне.

Безнең бабай —
Тырыш игенче,
Ул яратты эштә җыйнакны,
Тыңламасаң әйткән сүзләрен,
Бора иде безнең колакны.

Кисеп бирсә бабай икмәкне
Хәерчегә
Яки ялчыга,
Җыеп кабар иде валчыгын
Сөялләнеп каткан учына.

Саранлыктан түгел бу анык,
Аңладык без эшнең хикмәтен,
Иң кадерле нәрсә икәнен
Аңлаткан ул шулай икмәкнең.

Ак кәгазьгә тегәп күземне
Әле шуны
Уйлап утырам;
Башлана бит шушы валчыктан
Зур хезмәткә
Бөек ихтирам!

1967

### Бер генә

Йолдызлар күп —
Чулпан бер генә,
Ул елмая безгә гел генә,
Җир өстендә илләр, сулар күп,
Ә туган як фәкать бер генә.

Дөньяда күп,
Бик күп аналар,
Бәбкәм дими сиңа
берсе дә.
Үстерүче канат астында
Газиз анаң синең
бер генә.

Карама син гайбәт сүзләргә,
Хак юлыннан атлый бир генә,
Сукмак та күп җирдә,
юл да күп,
Хакыйкатькә маяк
бер генә!

1967

### Назим Хикмәттән

Ярамый сиңа, кеше,
Ярамый көнләшергә,
Мөмкинмени соң инде
Арпага тиңләшергә.
Җил булсам иде дисең,
Ярый, алайса, җил бул,
Тамчы бул әйдә — су бул,
Болары ярый әле ул.
Инде бу җирдә хәзер
Булам мин дисең орлык.
Юк, шагыйрь, орлык булма,
Кала күр кеше булып!

1968

Максим Глухов

# ТИБРӘНДЕРЕП КҮҢЕЛ КЫЛЛАРЫН...



Михаил Дмитриевич белән мин һәвәскәр музыкант Салих Вәлиев аша, ягъни «читтән торып», танышкан идем. Салих ага үзе — төрле гармоньнарда дисеңме, скрипкада яки курайдамы һәрберсеңнең күңелен әсир итәрлек матур итеп уйнаучы музыкант. Алай гына да түгел, ул әнә шундый музыка коралларын үзе менә дигән итеп төзәтә, көйли, хәтта яңаларын да ясый. Инде алтмыш яшьтән узуына карамастан, тынгысыз һәвәскәр, бөтен Арча районын шаулатып, гаилә ансамбле оештырып җибәрде. Бу гүзәл коллектив республика смотры лауреаты дигән мактаулы исем алуга иреште. Шуңа күрә дә Салих ага Вәлиевне Арча якларында гына түгел, бәлки республикабызның бүтән районнарында да бик күпләр белә һәм хөрмәт итә.

— Менә нәрсә,— диде миңа бервакыт Салих ага.— Барысы хак сүз: мин төрле музыка инструментларында уйныйм һәм аларның кайберләрен үзем ясаштыргалыйм да. Тик... Менә син Вараксин дигән кешене эзләп тапсаң икән... Ул, ичмасам, менә дигән алтын куллы оста! Аның һөнәре, әйтергә кирәк, ата-бабадан килә...

— Вараксин? Халыкча әйтсәк, Бараксин... Ул әле исәнмени?! — Мин гаҗәпләнүемнән кычкырып ук җибәрдем бугай, Салих ага, миңа карап, сәер елмаеп куйды. Чөнки күңелем, әллә ничек, дулкынланып киткәндәй булды. Мин бит ул кеше турында моңа кадәр дә күп мәртәбәләр ишеткән идем:

— Бараксин...

— Бараксин гармоне... Ә кем соң ул? Кайдан ул һәм хәзер кайда?..

...Казанның нәкъ үзәгендә, Куйбышев урамында, бик күпне күргән, искереп беткән бер катлы таш йорт тора. Беркем дә әллә ни игътибар итмәгән шушы йортта пөхтә генә киенгән, күрер күзгә сөйкемле генә интеллигент кыяфәтле бер карт яши. Үзе ул сүзгә саран, ләкин бик ягымлы кеше. Күршеләре һәм танышлары очраганда, ул һәрвакыт ихтирам белән баш ияр дә, гадәтенчә: «Сәлам бирдек...» дияр һәм юлында булыр.

Менә шушы инде ул Михаил Дмитриевич, гармонь ясаучы һәм көйләүче мастер Вараксин — халык арасыннан чыккан алтын куллы осталарның бик күптәнге традицияләрен, үтә нечкә эштәге «серләрен» безнең көннәргә кадәр алып килүче сирәк кешеләрнең берсе. Вакыт дигәнең агым судай һаман үтә дә үтә барган һәм инде аның чәчләрен бәсләндергән, йөзен җыерчыкландырган. Ләкин зәңгәр күзләрендә күңелне ничектер үзенә тарта торган ягымлы самими нур балкый. Гадәттә, мондый күзләр бик намуслы һәм үзенең хаклыгына ышанган кешеләрдә була.

Үзе янына килүчеләрне Михаил Дмитриевич кече күңел белән каршылый. Урындык тәкъдим итә, ни йомыш белән килгәнеңне сорый. Менә мин бу юлы килгәч тә хуҗа кеше газетасын җәһәт кенә өстәлгә куйды, гафу үтенгән сыман елмайды, «Сәлам бирдек...» дип, кул биреп күреште.

Гади генә, беркадәр борынгычарак җиһазланган бу тыйнак өйдә үзеңне иркен хис итәсең. Залда, куе коңгырт тестәге, тонык көзгедәй ялтырап торган бик күптәнге пианинодан тыш, байтак гомер кичергән комод, сырлап эшләнгән аяклы өстәл һәм берничә венский урындык тора. Урам як стенага татар композиторларының рәсемнәре, ә каршы якка Михаил Дмитриевичның әтисе — Дмитрий Иванович Вараксинның саргаеп беткән фотосы элеп куелган.

Вараксин. Милли татар гармоненың дөньяга килүе шушы исем белән бәйләнгән. Халык үзенең аһәңле матур моңнар сибүче күп телле беренче музыка коралын «бараксин» дип атаган. Әйе, Тула осталары чит илдән алып кайткан «тальян гармоньнарны» нәкъ менә Вараксиннар татар халык көйләрен уйнарлык итеп җайга салганнар. Революция алды елларында ук инде «бараксин» шәһәрдә дә, авыл җирләрендә дә киң таралган булган. Совет власте елларында исә, Казан гармонь фабрикасы оештырылу белән, гармоньнарны күпләп җитештерүдә аны нигез итеп алганнар. Һәм, әйтергә кирәк, аның конструкциясе бүгенге көнгәчә әллә ни үзгәрмәгән. Шуның өчен дә шул «бараксин» халык җырларында да яратып телгә алына. Ничектер шулай килеп чыккан инде, Вараксиннар турында әлегәчә берни язылмаган диярлек.

Шуны да әйтергә кирәк, бу йортка халкыбызның сөйгән композиторы Салих Сәйдәшев еш килгән. Ул, үзе генә аңлый торган ниндидер тирән уйларга чумып, Михаил Дмитриевичның тальянкасында сәгатьләр буе уйный торган булган. Күңелен бастыргачы уйнагач, Салих ага тальянканың каешларын эләктерә, аны саклык белән генә үз урынына — комодка куя да бәрхет белән каплый һәм йөрәгенең иң тирән җиреннән чыккан көрсенүле тавыш белән:

— Их, Михаил Дмитриевич! Үзем менә синең гармонеңны уйныйм, ә күңелем каядыр ашкына. Барлык вак-төяк борчулар юылгандай була... Әгәр шагыйрь булсам, мин болай дияр идем:

**Йөрәкләргә үтеп керә моңы,**
**Тибрәндереп күңел кылларын...**

Ничек кенә соң син шушындый могҗиза инструментларны көйли аласың? — ди.

Ә Михаил Дмитриевич андый чакта, зәңгәр күзләрен бер кырыйга төбәп, иңбашларын гына җыерып куя. Моны тел белән аңлатып биреп буламыни, янәсе.

Фәйзулла ага Туишев та бу гаиләнең якын дусларыннан берсе була. Сихри моңнары белән халык күңеленә кереп калган бу атаклы гармоньчы 1946 елда болай дип язган:

«Михаил Дмитриевич Вараксин—гармоньнар ясау буенча нәсел-бабадан килгән мастер... Аның инструментларына халкыбыз бик зур бәя бирде. Концерт белән районнарда йөргәндә миннән һәрвакыт: «Ул мастер әле исәнме? — дип сорыйлар...»

* * *

Ул көннәрдән бирле егерме елдан артык вакыт узды. Менә Михаил ага хәзер безнең белән бергә әллә кайчангы хәлләр турында хатыны Мария Гавриловна (күршеләре аны Мәрьям апа дип йөртәләр) сөйләгәнне тыңлап утыра. Кулы белән иягенә таянган хәлдә, уйчан кыяфәт белән, дәшмитынмый тыңлый, ара-тирә генә бер-ике сүз белән җупләп куя. Күптән мәгълүм булган нәрсәләрне бик сабыр тыңлау гадәте дә, пөхтә итеп кырынган йөзендә кайчак балкып ала торган хәйләкәр елмаюы, кыекча изүле кара сатин күлмәген билдән үрелмә тасма белән буып йөрүе дә, тездән югары балтырлы хром итекләре дә — гомумән барысы да заманында аның оста куллы кешеләр «университетын» үткәнлеген әйтеп тора.

Үз гомерләрендә Вараксиннарга бик күпне күрергә, әчесен дә, төчесен дә татырга туры килгән.

Иң башлап «бараксин» гармонен ясаучы өлкән Вараксин — Дмитрий бабай күптән инде дөнья куйган, һәм аның белән бергә бу гармонь осталары династиясе тормышында булып үткән бик күп гыйбрәтле хәлләр дә билгесезлек дәрьясына чумган.

Телдән-телгә йөргән риваятьләрнең аерым өзекләре генә Михаил Дмитриевич белән Мәрьям апаның хәтерләрендә калган.

Вараксиннар Казанга Киров өлкәсеннән күчеп килгәннәр. Кайчандыр фәкыйрь һәм экономик яктан бик артта булган Вятка губернасын вак һөнәрчеләр ватаны диярга мөмкин. Монда иген начар уңган, чәчүгә яраклы җирләр аз булган. Ә көн күрергә

кирәк. Һәм бирәдәге крестьян халкы нинди дә булса берәр төрле ярдәмче кәсепкә өйрәнгән.

Беренче пароходлар йөри башлауга күбәүләр лоцман, матрос яисә су түгүче булып эшли башлый. Болай дип тә сөйлиләр: навигацияләрнең берсендә Вараксы авылы крестьяны Иван Иванов ниндидер әкәмәт тартма алып кайткан, бу тартма «үзе уйный» икән.

Яңгыравык тавышлы бу хикмәтле нәрсә авылдагы күп кешеләрнең күңелен үзенә тарта. Аңа кушылып җырлау, ул уйнаганга бию, ниндидер быргыга караганда, бөтенләй җиңел икән. Ә вяткалылар — бик булдыклы халык. Син аларга берәр ят әйберне күрсәт кенә — башларын кашып алалар да шундыйны ук үзләре ясый башлыйлар. Әнә шулай итеп Вятка якларында гармонь ясау һөнәре тамыр җәя.

Әмма, ни генә әйтмә, гармонь ясау — чабата кайтару түгел инде ул. Шуңа күрә вяткалылар арасында да гармонь осталары бик күбәеп китми. Аеруча сәләтле кешеләр генә бу яңа һөнәрнең бөтен нечкәлекләрен төшенеп ала. Шундыйларның берсе Дмитрий Иванович Вараксин була.

Михаил Дмитриевич әтисе турында болай сөйли:

— Әткәй, мәрхүм (туфрагы җиңел булсын), беренче карашка бик кырыс холыклы, мастеровойларның иске гореф-гадәтләрен үзенә мирас итеп алган кеше иде. Аның алдында бер минут та эшсез утыра алмас идең. Үзе дә тиргә батып эшли, бездән дә шуны таләп итә. Ләкин бик тә намуслы, һәр яктан пөхтә кеше иде. Тәмәке тартмады. Аның бервакытта да эчеп исергән чагын күрмәдек без. Аның каравы шундый сәер яклары да бар иде: читлекләрдә матур-матур сайрар кошлар асрады, «агачлар җырлаганны» тыңларга ярата, шуның өчен бәйрәм көннәрне авылдан әллә кая, еракларга чыгып китә торган иде...

Стенадан, кара лаклы рам пыяласы артыннан, безгә Дмитрий Иванович үзе карап тора. Хәзерге заманда кайбер рәссамнарда һәм режиссерларда гына очрый торган озын чәч, күзлек кигән. Һәм ул менә хәзер үзе сөйли башлар төсле тоела.

Әйе, аның үз сөйләгәнен тыңлап карыйсы иде: ул гади рус крестьяны, татар халык көйләренең яңгырашын ничек сиземли алды икән, бөтен ихлас күңелен биреп эшләвенең төүге җимеше булган беренче «бараксинын» ничек ясады икән?.. Юк шул, сөйләтеп булмый хәзер...

Безгә бу очракта да гаиләдәге риваятьләр, хатирәләр белән генә канәгатьләнергә туры килә.

...1894 елда микән, 1895 теме була бу хәл. Көз көне. Тирә-юнь төнге караңгылыкка чумган, тәрәзә капкачлары да ябылган. Шулчак кемдер капканы шакылдата һәм:

— Бараксин хотел видайт. Гармунный мастер...— ди, русчаны аннан-моннан сукалап.

Дмитрий Иванович иңенә пиджагын сала да капканы ачарга кузгала, хатынына:

— Мөгаен, ерактан килгәндер... Самоварыңны куеп җибәрче, карчык, — ди.

Төнге кунак Кама буендагы ерак авылдан килгән бер крестьян икән. Исеме Йосыф. Култык астына бараксин гармоне кыстырган, аркасында — биштәр.

— Бер көн сәяхәт кылдым, ике көн, барыбер таптым,— ди кунак һәм, җиңел сулап:

— Инде гармоньлы булырмындыр, әʼ? — дип өстәп куя.

Дмитрий Иванович кунакның сүзләренә бераз сәерсенсә дә, назакәтле кеше буларак, сораулар биреп-нитеп тормый. Күңеле белән тоя: «сәяхәтче» барын да үзе төшендереп бирер әле, ә хәзергә бераз эче җылынсын, чәй эчеп алсын.

— Гармонең әйбәт синең, бик тә әйбәт,— ди кунак.— Тик миңа мондый гармонь кирәкми.

Менә сиңа мә! Дмитрий Иванович бөтенләй аптырап кала. Ничек инде ул алай? Ничәмә-ничә тапкыр Мәкәрҗәдә булды ул, әнә шундый ничәмә «хикмәтле тартмалар» кулдан-кулга йөрдә, әмма ул эшләгән әйберне кемнеңдер менә шулай кире кайтарып биргәннәрен аның күргәне дә, ишеткәне дә юк иде. Ни генә әйтмә, аның тальянкалары сизовскилар[1] белән тиң йөрдә нич...

— Һәй, Бараксин туган, төшенмәдең син мине, — ди Йосыф, Дмитрий Ивановичның сәерсенеп калуын күреп.— Мин ул турыда әйтмим. Без татарлар өчен мондый гармонь батмый, дим. Тарта алмый. Моңы килеп бетмиме, бүтән нәрсәсеме... Их, ясасаң иде син гармоньны чын без дигәнчә, әʼ? Дәр-р китереп «Әлипә»сен дә бииспе иде, сыздырып «Зиләйлүгә»н дә җырлап булсын иде...

Әһә... Хикмәт менә нәрсәдә икән!

---

[1] Сизов фамилияле Тула мастерлары эшләгән гармоньнарны шулай дип йөрткәннәр.

Ул чагында Дмитрий Иванович әле берни дип тә җавап бирми. «Вакыт соң инде» дип, сәяхәтчене йокларга яткыра...

Иртәгесен таң беленү белән үк Вараксин, гадәтенчә, урыныннан тора. Ләкин бу юлы инде яңа гармонь өчен детальләр ясауга керешми, ә, киресенчә, әзер диярлек гармоньны сүтәргә тотына. Бер сәгать үтә, ике сәгать... Төнге кунак күптән инде үз юлына чыгып киткән, ә Дмитрий Иванович һаман гармоне белән маташа. Шактый вакыт үткәннән соң, нәрсәнедер кинәт исенә төшергәндәй, әйтеп куя:

— Эх, менә син аны бит, ә... Кунагыбыз, димәк, киткән дә инде?.. Карчык, миңа да юл кирәк-яракларын әзерләче.

Дмитрий Иванович ике атналар үткәч кенә әйләнеп кайта. Татар авыллары буйлап йөри. Аның шуны беләсе килә: моңлы музыка сөючән бу халык ничегрәк җырлый икән соң, яраткан көйләре нindирәк икән?

Әйе, булачак яңа тип гармоньга бөтән телләр куярга, дөресрәге, аның төзелеше, җайга салынышы ук бөтәнчә булу кирәк икән шул.

Дмитрий Иванович татар гармоньчысының ничек итеп гармонь күреген тартып сузуларын күзәтә, уйнау манерын озак-озак карап тора, бөтенесен тирән итеп күңеленә сеңдерә. Моңа чаклы ул ясаган тальянкаларның тембр диапазоны татар җыры калыбына, аның мелодикасына, аһәңлелегенә туры килеп бетмәгән икән шул. Бөтенләй башкача фактурадагы инструмент ясарга кирәк булып чыкты. Мастер кеше иң әүвәл борынгы татар музыка коралларының — курай, кубыз, гөсләләрнең үзенчәлеген өйрәнүгә керешә; аларны ул «музыкага хирыслыгы» өчен мәдрәсәдән куылган бер шәкерттән сатып ала.

Беренче татар гармонен ясауга тотынганда, сизгер күңелле һәвәскәр ниләр турында уйлаган, ул чагында аны нинди хисләр биләгән — монысын без белә алмыйбыз. Ләкин менә хәзер без шуны аңлыйбыз: гади крестьян Дмитрий Вараксин чынчыннан халык остасы рәвешендә эш иткән, ул иҗади эзләнүләр белән яшәгән. Әгәр дә гадәти бер һөнәрче генә булса, күнегеп беткән, инде ансат кына башкара торган эшеннән — тальянкалар ясаудан ваз кичеп, ул бик күп вакыт, хезмәт, әллә никадәр акча түгеләчәген, ә бәлки уңышсызлыкка да дучар булу ихтималын алдан ук белә торып, яңа инструмент ясарга керешкән булыр идемени?

Әмма талантлы мастерның хыялы тормышка аша. Көн артыннан көн үтә, байтак сулар ага, ә барыбер Дмитрий Иванович татар милли гармонен ясап чыгаруга ирешә. Яңа музыка коралы халык күңеленә ятышлы булып чыга.

Гаҗәп тә түгел: «бараксин» үзен тудырган кешегә дан китерә. Һәм Россиядә генә түгел, 1900 елдан башлап бу гармонь иң зур халыкара күргәзмәләрнең барысында да диярлек катнаша. Карап торышка әллә ни «могҗиза»сы булмаган инструмент Чикаго, Брюссель, Париж, Льеж, Милан шәһәрләренең бик талымлы белгечләренең дә күңелләрен әсир итә. «Бараксин»ның сул як планкасы тышында «Тырыш хезмәт өчен», «Оста эшләнгән өчен» дигән медальләр алтын һәм көмеш нурларын балкыталар, алар арасында 1900, 1904, 1906, 1907... елларны укыйсың.

Вакыт үтү белән, гармонь да камилләшә бара. Мәсәлән, юкә агачын эшкәртүнең нинди генә юлларын эзләп тапмый ул мастер! Әйтерсең лә, ул аны «сихерли» белә. Һәм — менә могҗиза! — Вараксин кулында юкә агачы, яңгырашы ягыннан, акустик һәм фоник билгеләре буенча, кыйммәтле кызыл агач токымнары дәрәҗәсенә ирешә.

Гармоньның тышкы кыяфәте дә үзгәрә. Татарга хас булмаган орнаментлар туган як табигатенә, татар халык мотивларына якын әйбәт бизәкләр белән алыштырыла.

Ә шулай да бит теләсә кайсы гармоньның нигезе, асылы — аның уйный торган, көй, моң чыгара торган җире — планкалары, телләре. Алар да камилләштерелә. Бакыр планкаларны җиз планкаларга алыштыралар, гармонь телләрен аккургаш тамчысы эретеп ябыштыруны куллана башлыйлар, шуның аркасында татар гармоне октавасы өчен аеруча кулай яңгырашлар сайлап алырга мөмкинлек туа. Регистрлар һаман күбрәк кулланыла бара...

* * *

Гаиләләре зур, һәм, гәрчә, Дмитрий Ивановичның алтын куллы оста дигән даны булса да, тир түгеп алган хезмәт хакы очын-очка ялгарга көчкә җитеп бара. Шуңа күрә әтиләренә гаилә членнарын да «җигәргә» туры килә. Менә бөтен гаилә һөнәрчелек эше белән мәшгуль: берәүләр пластинкалар кисә, икенчеләре күрек ябыштыра, корпусны нур чәчәрлек итеп матурлап буйый.

Беркөнне шулай Михаил Дмитриевич (аңа әле ундүрт яшь тә тулмаган була)

остаlгә, әтисе алдына, үзе ясаган тальянканы китереп куя. Менә, күрдеңме, янәсе, алма агачыннан ерак төшми. Ярый. Әтисе инструментны ала, һәр яктан игътибар белән карап чыга. Әйе, гармоньга тел тидерерлек түгел. Ата кешегә, менә дигән ярдәмчем үсте дип, сөенергә генә иде кебек. Ә юк бит!

Аның чырае караңгыланып киткәндәй була, шулай да ул үзенең хисләрен ачып салмый, йомшак күңелле булырга тырышып, болай ди:

— Кил әле, Михаил, минем янымарак. Утыр әле... Шәп эшләгәнсең, рәхмәт. Тальянкаң менә дигән булып чыккан.

Мишаның күңеле үсеп китә. Ә инде әтисе егерме тиен акча да биргәч һәм иртәгесен шәһәргә барырга, анда теләсәң нәрсә сатып алырга рөхсәт иткәч, ул тагын да сөенә.

Бер көннән соң Миша яңадан өстәл янына килеп, инструментларны кулына алуы була, әтисе аңа болай ди:

— Ә син, Михаил, булмаса, аулак өйгә бар. Анда гармонь була, җырларсың, биерсең...

Миша бу сүзләргә хәйран кала, әллә шаярта инде әтисе? Юк, алай түгел кебек, күзләре җитди. Хәерле булсын дип, ул аулак өйгә китә. Әмма әтисе иртәгесен дә эшләргә кушмый. «Нидер бар, күрәсең»,— дип борчыла малай.

— Нишләп инде, әткәй?.. Тальянкалар ясый алырлык түгел микәнни мин? — дип сорый Миша, тартынып кына.

— Юк, алай димим... Кулларың оста инде. Ясый аласың. Тик ихлас күңелеңнән өйт әле: гармонь ясау эшен яратасыңмы?

— Ничек инде яратмаска ди? Шуның белән тамак туйдырабыз ич,— ди улы.

Дмитрий Иванович уйга кала. Егетең бөтенләй үк төшеп калганнардан түгел, күрәсең. Тик менә... Аның тальянкасы — әтисенекенең копиясе! Хәтта тавыш пластинкаларындагы киртләүләр дә — артыгы да, киме дә юк — нәкъ әтисенекенчә эшләнгәннәр. Ә үзеннән бер мыскал да өлеш кертмәгән. Картны әнә шул борчый.

— Менә нәрсә, Михаил,— ди, ниһаять, Дмитрий Иванович ягымлы гына итеп, һәм улын үзе янына утырта.— Син мине аңла... Бәлкем, мин кырысрак кешедер. Әгәр алай-болай икән, гафу ит... Теләмисең икән, төкер син бу һөнәргә. Җаның кайсын тарта, шуны сайла. Семеново ложкарларына[1] өйрәнчек булып булса да бар. Анда да ипи-тозлык эшли аласың. Их, улым... Тик, кайда гына барсаң да, әгәр җаныңтәнең белән бирелеп эшләмәсәң, хаҗәтең бер тиен булыр. Кулларың синең никадәр генә җитез булмасыннар, әгәр дә зиһенеңне салып эшләмисең, йөрәгең белән тоймыйсың икән, ясаганың җансыз нәрсә булыр. Әйтик, менә гармоньны син миннән дә ким ясамагансың. Ләкин кешеләр аның турында: «Нәкъ әтисенеке!» — дип әйтәчәкләр. Ә синең турыда онытачаклар, чөнки аңарга синең үзеңнән берни өстәлмәгән. Синең әле киләчәктә күн күрәсең бар. Хикмәт менә бит нәрсәдә!

Шушы әңгәмәдән соң Михаил Вараксин шактый вакыт эш өстәле янына якын да килми. Әтисе дә: «Үзе утырасы чаны тапсын»,— дип фикер йөртә. Әмма әтисенең сүзләре, күрәсең, Михаилның йөрәк түренә кереп урнашкандыр. Өйдәгеләр әледән-әле шуны күргәлиләр: Миша, аныморы сиздермәскә тырышып, гармонь корпусын ача, аннан тавыш телләре пластинкасын ала да, телләрне игәүли, кыра, аннары корпусны җыеп тавышларны тыңлаптикшереп чыга, шуннан соң яңадан ача, нәрсәнедер үзенчә маташтыра. Сәгатьләр буе шулай!..

«Егет дөньясын онытты бит... Болай булгач, эше барып чыгачак»,— дип шатлана карт мастер.

Озак та үтми, Михаил Вараксин, әтиләре белән саубуллашып, сәфәргә китеп бара. Саратовта, Тулада, Ростовта була. Гармонь ясауның бөтен нечкәлекләрен өйрәнә. Менә ул инде «венски», «хромка» гармоньнарын, баяннар ясый ала. Инде әйбәт кенә даны да тарала...

Империалистик сугыш окопларында ике ел. Аннары — гражданнар сугышы... Егерме беренче елга кадәр куллары винтовкадан башка берни күрми аның. Әмма шулай да 1923 елда Мәскәүдә булып үткән беренче Бөтенроссия күргәзмәсенә Михаил Дмитриевич Вараксин ул заман өчен бөтенләй яңа, күп регистрлы гармонь ясап китерә.

* * *

— Беләсезме, кайчак бик тә аяныч нәрсәләр була...— дип сөйләп кенә киткән иде,

---

[1] Нижегород губернасы (хәзерге Горький өлкәсе) Семеново авылының кашык ясаучы осталары. Бирелә бу һөнәр хәзер дә яшәп килә.

ләкин, күрәсең, тамагына ниндидер төен килеп тыгылды, ул тынып калды.

Озак кына сүзсез торганнан соң, Михаил Дмитриевич:

— Шунысы аяныч миңа: гомерем узды, ә үз морадыма ирешеп булмады,— диде.

Михаил Дмитриевич үз тормышында өтисенең ике теләгән гамәлгә ашырырга омтылган. Берсе: гармонь ясау эшенә чынчыннан гашыйк булган мастерлар күбрәк булсын иде, алар инструментны елдан-ел камилләштерә һәм яңаларын иҗат итә алсыннар иде; икенчесе: Казанда сирәк музыка кораллары күрсәтелә торган музей булдырылсын иде.

Бары тик ялгызак һөнәрчеләр генә икеөч дистә һәвәскәр өчен гармонь әмәлләп биргән заманнар инде әртта калды. Күптән инде гармонь фабрикасы эшли, меңә дигән инструментлар меңәрләп чыгарыла. Казан гармоньнарының моңнары Донбасстагы шахтер поселокларында, Уралда һәм Себердә, Кавказ авылларында һәм Урта Азия кышлакларында яңгырый. Әле күптән түгел генә Казан фабрикасы инструментлары Мәскәүдә Бөтенсоюз күргәзмәсендә дипломнар алды. Димәк, фабрикада менә дигән көйләүчеләр, тавыш сайлап куючылар, җыючылар бар. Алар гармоньны камилләштерә баралар, иҗади эзләнү рухы белән яшиләр. Яңа инструментлар — 30×30 лы һәм 18×12 гармоньнар ясап чыгарган өчен Николай Минякин һәм Николай Емельянов медальләр белән бүләкләнде, мастер Салих Шәйдуллинга күргәзмәнең дипломы бирелде...

Шулай булгач, вакыт дигәнең Вараксинның беренче теләге файдасына эшләгән булып чыга. Тик шунысы кызганыч, Михаил Дмитриевичка мастерлар белән кулга-кул тотышып эшләргә туры килми.

Утызынчы елларда Вараксиннарның тормышы көйсезләнеп китә. Игелексез һәм көнче кешеләр табыла, алар мастерлар династиясе белән исәп-хисапларын өзәргә маташалар. Ниндидер бер явыз, әшәке кешенең чагуы буенча, Михаил Дмитриевичны Казандагы дәүләт гармонь мастерскоеннан эштән чыгаралар. Сәбәбе дә адәм көлкесе бит: «Янәсе, үз эшен йомшак белгәне өчен».

Михаил Дмитриевич:

— Гармоньсыз мин нишлим инде? — дип, әле бер, әле икенче инстанциягә мөрәҗәгать итеп карый, үтенечләр яза...

Шул рәвешле Вараксинга яраткан эшен калдырырга туры килә. Әйтерсең, Михаил Дмитриевичның рус һәм татар көйләренең тулы тембрлары диапазонын сыйдырган күп регистрлы тальянканы беренче булып ясаучы булуында беркемнең дә эше юк. Әйтерсең, Дмитрий Ивановичның гражданнар сугышында катнашканлыгын, берничә еллар Ленинградтагы «Красный партизан» артелендә намус белән эшләгәнлеген, экспорт өчен баяннар көйләгәнлеген барысы да оныткан.

Кешене яраткан эшеннән аеру кошны канатсыз калдыру белән бер. Авыр кичерешләр, шик-шөбһәләр, хәтта рухи төшенкелеккә бирелгән минутлар да була. Дөрес, аның кулларын һәм осталыгын беркем тартып ала алмый. Әмма «базар өчен» эшләве... Бу эшкә бөтен гомере буенча шуның хакына күңелен бирдемени ул? Ә экспериментал мастерской турындагы, чын-чыннан иҗади эш турындагы хыяллар?

Ахыр чиктә Вараксиннарны Мәскәүдә яклап чыгалар, гаделлек җиңә. Ләкин бер кашык дегет үзенекен итә: бер-бер артлы туып кына торган мәшәкатьләр, йокысыз төннәр Михаил Дмитриевичны аяктан егалар. Ул каты һәм озак авырый, инвалид булып кала. Җитмәсә тагы, моңа өстәп, көнкүрештәге кыенлыклар борчый.

Кем белә, әгәр дә чын дуслар һәм аның гадәттән тыш талантын ихтирам итүчеләр булмаса, алдагы көннәрдә ниләр булган булыр иде икән. Иң читен минутларда аның янына дусты — шулай ук менә дигән гармонь мастеры Александр Александрович Сметанин еш килә башлый. Вологда яклары һөнәрчесе Александр Александрович — Казанда гармонь производствосын оештыручыларның берсе. Ләкин, Михаил Дмитриевич кебек үк, ул да, кемнәрнедер «куып җитеп узып китәргә» дип артык тырышучы һәм әйбернең сыйфаты турында онытучы кайбер җитәкчеләр «кулына» эләгеп, фабрикадан чыгарыла. Сметанин өйдә эшләргә керешә.

Сметанин тавышлар диапазоны бөтен бер оркестрга туры килә торган, оркестрдагы барлык инструментларның диярлек тавышларын хәтерләткән уникаль баян конструкцияли. Шушы баян уйнавына кушылып, бөтен дөньяга билгеле артист Иван Козловский җырларга ярата торган булып китә. Үзенең сыйфатлары буенча бу баян дөньядагы иң яхшы аккордеоннардан өстен булып чыга. Шушы гаҗәеп баянны ясаган өчен гармонь мастеры Александр Александрович Сметанинга Татарстанның

атказанган техника эшлеклесе диган исем бирелә [1].

— Зарар юк, Михаил,— ди ул Вараксинга.— Кулларың исән бит. Бары да онытылыр. Без синең белән дөнья шаулатырбыз әле. Шулай түгелме?..

Сметанин Вараксиннарга һәр килгән саен гүя үзенең ныклыгын, ышанычын калдырып киткән төсле була. Шуннан соң Михаил Дмитриевичның куллары бәләкәй чүкечләргә, җиз чыбыкларга сузыла. Мастер бу металл кисәкчекләрен матур көмеш тавыш белән җырлый торган пластинкаларга әверелдерә. Аннары тыңлап карый. Әгәр тавышлар югарырак яңгыраса, ниндидер алтынчы тойгыга — сиземләүгә бик тиз буйсынучан куллар пластинканың нигезен бераз гына, йөрәк сизеше белән тәңгәл яңгыраганчыга кадәр, игәүли...

Мастерның кечкенә генә бүлмәсендә яңгыраган тавышлар профессиональ татар театрларына, филармониягә, аерым башкаручыларга һәм композиторларга барып җитә. Бик күп заказлар килә башлый.

Җан тарткан эше инде канына сеңгән чын мастер шундый заказларны үтәүдән баш тарта аламыни? Бәлки, әйтик, театр премьерасының язмышы аның инструментына бәйледер? Чөнки кем генә музыка яратмый?! Музыкасыз премьера, спектакль кош-кортсыз, җәнлек-җанварсыз урман кебек бит ул. Сырхаулыкны җиңеп, Михаил Дмитриевич эшкә чума. Ул «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе» һәм башка күп кенә спектакльләр өчен тальян гармоньнар ясап бирә, алар тамашачыларның күңелендә тирән хисләр калдыралар. Әлбәттә, бу спектакльләрнең музыкаль аккомпанементы кемнең инструментлары белән алып барылганны күпләр белми дә. Тамашачы өчен моның әһәмияте, бәлки, зур да түгелдер. Аның каравы әсәрне сәхнәгә куючылар һәм режиссерлар халык арасында казанылган бу уңышларда пьеса авторының һәм рольләрне башкаручыларның гына түгел, бәлки музыка коралы остасының да өлеше зур икәнлекне яхшы аңлыйлар.

Ул вакытларны Вараксиннар гаиләсе тирән көрсенү белән искә ала. Шулай да вакыт дигәнең — агым су кебек: күп нәрсәне юып алып китә...

Вараксиннарда йөзләрчә хатлар саклана. Алар Михаил Дмитриевичның талантын хөрмәтләүчеләрдән. Шулардан иң кадерлеләре — Ватан сугышы фронты кырларыннан килгәннәре.

«...Артиллериядән атулар вакытында дошман снарядны кыйпылчыгы минем «бараксиным»ның күрегең ватты,— дип язган 1942 елда Сталинград яныннан бер кызылармеец.— Ә гармоньсыз монда бик читен. Миңа, Михаил Дмитриевич, яңаны җибәрсәң иде. Мин аны шул чаклы саклар идем, үзем белән Берлинга кадәр алып барыр идем...»

Андый заказларны Вараксин иң беренче нәүбәттә үтәргә тырыша. Хатлар Михаил Дмитриевичның рухын канатландыралар, алар аңа таныш булмаган, ләкин күңел белән якын булган кешеләрнең йөрәк җылысын җиткерәләр. Бу җылылык аның күңеленә яңа канатлар өстәп тора.

— Миңа инде хәзер күп кирәкми. Менә музей булдырасы иде дә бит... Бу турыда Салих Сәйдәшев тә хыялланды. Киләчәк буын өчен кирәк булыр иде ул. Бик тә кирәк,— ди Михаил Дмитриевич. Карт мастерның бу сүзләрендә шушы хыялының иртәме-соңмы гамәлгә ашачагына өмет, хәтта ышаныч яңгырый...

* * *

Вакыт соң инде. Мин китәргә кузгалдым. Нәкъ шул чакны, уң кулына зур чемодан тотып, егерме ике яшьләрдәге бер кеше килеп керде. Кузбасстан кайткан шахтер икән.

— Ялга кайттым, сабан туена...— диде ул. Аннары чемоданыннан инде күпне күргән «бараксин»ны алды.

— Бу гармоньда минем әтием, аңа кадәр бабай уйнаган,— дип дәвам итте егет.— Менә бераз туза төште. Моны сез үзегез... Нәкъ менә Вараксин кулы белән яңартып бирсәгез иде...

Михаил Дмитриевич күзлеген төзәтебрәк куйды. Инструментны кулына алган иде, аның сул як планкасында: «Мастеръ Дмитрий Ивановичъ Вараксинъ. 1909 ел»,— дигән язуны күреп, бик сәер генә чайкалып, бер алга, бер артка атлап куйды. Бер сүз эндәшми генә үзенең кечкенә бүлмәсенә — «мастерскоена» кереп китте. Берничә минуттан ул әйләнеп чыкты да, аңына килгәндәй, кунакка утырырга урын тәкъдим итте һәм йомшак кына тавыш белән:

— Өр-яңасыдай уйнар,— диде.

[1] А. А. Сметанин җитмеш бишенче яшендә Казанда үлде.

*Туган елым 1945. Туган җирем Башкортстан, Калтасы районы Касево авылы. Үскән җирем Агыйдел белән Кама елгасы кушылган урыннан ерак түгел Сауз авылы. Җилкәдә Игарка портының бүрәнәләре, Свердловск һәм Сарапул шәһәрләренең юллары, бер ел армия. Хәзерге вакытта Казан дәүләт университетының журналистика бүлеге студенты. Әле, шигырьне шигырьдән аера алмаганда, 5 классларда укыган чакларда ук шигырьләр яза башлаган идем.*

*Яраткан шагыйрьләрем, бик ошаткан шагыйрьләрем бар. Табынган шагыйрем Александр Блок. Ә кайбер шагыйрьләр бер карасаң бик бөек кебекләр, бер карасаң кечерәеп калалар.*

*Матур итеп, уйландырырлык итеп язасы килә.*



# Эдуард Мостафин

## Көймә көтеп утырабыз

Көймә көтеп утырабыз.
Ярларны җилләр капшый,
Дулкыннар камыр басалар,
Комнарны ашый-ашый.

Көймә көтеп утырабыз,
Ерак ярларны күзләп.
Акчарлаклар ак керләрдәй
Җилфердәшә җим эзләп.

Көймә көтеп утырабыз
Дулкыннарны кочарга,
Акчарлакның канатыдай
Канат булса очарга!

## Юллар чатында

Яр буеннан кызлар уза,
күлләрдә күләгәсе.
Әллә сызгыра-сызгыра
шуларга иярәсе?!
Зәңгәр күктә кыр казлары,
суларда күләгәсе,
Әллә инде канат кагып,
шуларга иярәсе?!

•

Ак каеннар сөттән ак булмаса,
Матур кызлар көлеп тормаса,
Иреннәргә пешкән алмаларның
Алсулыгы төшеп кунмаса,
Тол хатыннар ялгыз юксынмаса,
Чәчкә бераз кырау кунмаса,
Көз көннәре яфрак саргаймаса,
Салкын сугып гөлләр сулмаса,
Кайдан алыр идек бу моңнарны?!
...Ышык җирдә ярлар тын булалар, —
Тик тын ярны бик тиз ком баса.

•

Чәйгә салган шикәрмени,
иренендә карлар эри.
Суга төшкән очкынмыни,
иренендә кояш эри.
Иреннәреңә тиялмый
иренем тилмереп йөри.

## Авылда бер көн

Җир өстендә чуар бизәк —
күңелләрдән төшкәнме?
Баш очында сары кояш —
бакчаларда пешкәнме?!
Күк йөзенә зәңгәр күзнең
шәүләләре кунганмы?
Тәрәзәдә боз-сөңгеләр —
күз яшьләре туңганмы?

## Бер җыр килә

*(М. Кәримгә.)*

Бер җыр килә Юлай даласыннан —
Туп-туп иткән тояк тавышы.
Бер җыр килә — Урал бөркетенең
Кай якларга очып барышы?

Бер җыр килә Урал тауларыннан,
Оран сала-сала еракка.
Бер җыр килә таулар йөрәгеннән —
Курай моңы булып йөрәккә.

Бер җыр килә...
Таулар гына килми,
Бер урында килеш картая.
Урал тауларына чалма чалып,
«Өченче көн тоташ кар ява».

## Яңгыр тамды

Яңгыр тамды кипкән иреннәргә,
Иреннәрдә салкын дым калды.
Тамчылардан бәхет көткән кебек,
Кулын сузып кеше тын калды.

Яңгыр тамды кабер ташларына,
Юаргамы теләп тузанын?
Таш уйлады: тагын күз яшьләре!..
Белмәде ул яңгыр узганын.

●

Аккошлармы җир өстенә
Сагышын сыгып киткән.
Сагышларны күтәралмый
Чәчәкләр корып кипкән.

Яңгырлармы тамчы-тамчы
Бәхетләр сибеп киткән.
Аккош киткәндә тудыммы,
Яңгыр үткәндә микән?

●

Һавада кошлар гына,
Тауларда ташлар гына.
Каңгырып йөри җирдә
Тик ялгыз башлар гына.

Кошлар буласы иде,
Сатылмый шул канатлар.
Ташлар булсам — абынып
Егылыр чапкан атлар.

Һавада кошлар гына,
Тауларда ташлар гына.
Бөркет, шул тау ташларына
Канатың ташла миңа.

*Буа якларында җилләр белән уратылган, зәңгәр күк гөмбәзе белән ябылган Яңа Чәчкап дигән бер авыл бар. Сокландыргыч табигате, акчарлаклар уйнарлык елгалары булмаса да, минем күңелгә бик якын ул: мин мәнә шунда 1936 елда дөньяга килгәнмен. Бала чагыма аның киң басулары, тубыкны гына күмәрлек сулары шаһит булган, яшьли ятим калгач, шулар ук иңнәремнән сыйпаган, назлаган һәм юаткан, ә аннан олы тормыш юлына озаткан.*

*Урта мәктәп, университет, Апас район газетасы, Казан һәм Лениногорск телевизион студияләре — укуым һәм хезмәт юлым шулай.*

*Шигырьләр белән яшьли мавыгам. Республика газета-журналларында күренгәлим. Ләкин Парнаска юл кыен — кәеф төшкән чаклар да була. Шулай да поэзия белән дуслыгымны соңгы көнемәчә өзмәм, ахры. Чөнки бу үз-үземә хыянәт итү булыр иде.*

## Әхмәт Рәшитов

# Мунчадан репортаж



**Мунча...**
**Ләгән шалдыр-шолдыр...**
**Юына яшьләр...**
**Юына картлар...**
**Ялтырый тик шәрә ботлар,**
**Шәрә артлар,**
**Шәрә сыртлар...**

**Бер читтәрәк яшүсмерләр...**
**Оялчаннар житкән кыздай.**
**Юына кулсыз...**
**Юына сукыр...**
**Яралылар...**
**Ярасызлар...**

**Сабан туйда көрәшергә**
**Яраклылар...**
**Яраксызлар...**
**Душ астына баскан бергә**
**Аяклылар...**
**Аяксызлар...**

**Әнә бер карт. Ләгәнен дә**
**Тик онытгы ташый аның.**
**Заманында батырлыгы**
**Данга күмгән Мәскәү янын.**

**Кайчандыр без күрше идек,**
**Гел кительдән...**
**Погоннарсыз...**
**Сокландыргыч кыяфәте —**
**Хәрбиләрчә — сыны төп-төз.**

Шуннан беләм: күкрәгендә
Орденнары тулай тезем.
Ә биредә шәрә килеш
Салып тора протезын.

Еллар саклый яраларны,
Чүпрәк каплый яраларны.
Ләкин солдат оныта алмый
Утлы-сулы араларны —
Сталинградны, Мәскәү янын,
Ленинградның сүнмәс данын...

Берлингача алсу каны
Пунктирлар сызган аның.

Кеше тәне — җир күкрәге
Һәм язмышлар елъязмасы.
Күреп аның җәрәхәтен
Ничек күңелең сызламасын?!

Урамнарда һәр гөл көләч,
Урамнарда һәркем көләч.
Аңлыйсың ул көләчләрнең
Бар контрастын монда кергәч.

Еллар саклый яраларны...
Чүпрәк каплый яраларны...
Ләкин тарих һәр буынны
Шул язмыштан аралармы?!

...Егетләр чыгалар пардан...
Тәннәрендә мәрҗән төсе;
Мускуллары елкылдаган,
Һәркайсында Атлант көче.

...Сабый.
Суда чыпырдана.
Бигрәк наян,
Бигрәк нәни...
Рафаэль язган рәсемнән
Монда сикереп төшкәнмени?!

Аларның да алсу тәнен
Кыйпылчыклар ярырмыни?
Аларның да ярсу каны
Пунктирлар салырмыни?

Мин аларны күрер идем
Рингта яки сабан туйда.
Заводларда, төзелешләрдә,
Су астында, җирдә, Айда.

Антик дөнья Антейларын
Таң калдырыр буын үсә.
Җир-ананың яралары
Тарих битләренә күчә.

Еллар, күрми кара-акны,
Үз җаена ага-ага...
Киң күкрәкле, зур йөрәкле
Ирләр кирәк Планетага.

## Семей[1]

Европадан килдем сиңа, комлы Семей,
Синең хакта легендалар тыңлый-тыңлый,
Тик шапырынмыйм, кыргый Азия, дип лаф ормыйм,
Минә хәзер күкрәгемә шатлык сыймый:

Рәсәй кебек ягымлы як, сагынып як,
Рәсәй кебек аналарча назлап үптең.
«Ой, син ногай баласы гой», — диеп казакъ
Туганыдай якын күреп кунак итте.

Монда миңа бар да иске таныш гүя:
Этләрең дә койрык болгап сәлам бирә.
Күктән кояш авыз ерып көне буе
Нурларыннан сиңа рәеш күлмәк тегә.

Иксез-чиксез киңлегенә күзем йөртеп
Онытылам, шашкын хисләр канат кага:
Айналаен[2] ак күбеккә баткан Иртеш
Курмангазый моннарыдай ташып ага.

Килдем Тукай иленнән мин котлау алып,
Бәйгеләрең, сый-хөрмәтең кочагына.
Бәйрәм итә бүген уртак җиңүләрне
Европа да, Азия дә бер табында.

## Мәдхия

*(h. hейнегә ияреп)*

Мәңге сүнмәс чәчәк сыман
Яшьлегең гүзәллеге:
Җырлыймчы бер мактау сиңа, —
Ах, бетте түзәрлегем.

Яндырган да, көйдергән дә,
Сөйдергән дә карашың;
Мәҗнүнне тез чүктергән дә,
Таhирның да җанашы...

Кемнәр соң ул Ширин, Зөhрә,
Җульетталар — барысы да!
Мәшhүр Ләйлә — фәкать шәүлә
Син гүзәлем каршында.

Бар да әкият, бар да таш сын,
Берләштергән тик бер син:
Ләйлә дә син, Зөhрә дә син,
hәм Җульетта, hәм Ширин.

---

[1] Семей — Семипалатинск шәhәрен казакълар hәм татарлар шулай атыйлар.

[2] Айналаен — яратып, сөеп әйтү, тирәңдә әйләним, дигән сүз (казакъча).

❋ ❂ ❋

*1938 елда Татарстанның Питрәч районы Әлбәден авылында туганмын.*

*Быел Казан дәүләт пединститутын тәмамлыйм. 1962 елдан бирле туган авылымда 8 еллык мәктәптә татар теле һәм әдәбияты укытам.*

*Иҗат эше белән күптән шөгыльләнәм. 1957 елдан бирле газета-журналларда катнаша башладым.*

# Павел Апушев

## Күңелдәге һәйкәл

*(Шагыйрь кабере янында уйлану.)*



Килеп чыккач синең өстеңә,
Башым иеп тордым бер мәлгә.
Шигырьләрең җиңел ятласам да,
Кабереңне таптым көч-хәлгә.

Нәни генә такта уртасына
Ярый әле исемең язылган.
Чәчәкләр юк. Үзең күпме чәчәк
Бүләк иттең гомер языннан.

Кул кирәктер, бәлки, төзәтергә,
Кабер өстең инде юылган.
Шигырьләрең ләкин йөрәкләргә
Юылмаслык булып уелган.

## Владимир Комаровка

Галәмдәге иң зур йолдыз булып
Кабындың син дөнья күгендә.
Гасырларга тиңдәш гомерне бит
Яшәп үтә алдың бер көндә.

Батырлыгың җирдә яңгырап тора,
Әз хезмәтең күктә күкрәде.
Синең исем шигъри әрбитага
Алып чыгар әле күпләрне.

●

*(Хәсән Туфанга)*

Аның кыры ундырышлы,
Күп уйлар сыйдырышлы.
Бөртекләп җыя күңелләр
Ул үстергән уңышны.

Ил кырында чәчәк атар
Иде минем җырым да,
Бер бөртек булып шыталсам,
Шагыйрь Туфан кырында.

## Гашыйклар

Чибәр кыз яулык чигә,
Егет тарәзгә килә.
Тәрәзгә килә егет,
Йөзен күрмәмме диеп.

Егет машина йөртә,
Кыз борылышта көтә.
Борылышта көтә кыз,
Әйтмәсме дип берәр сүз.

Кыз елгадан су ала,
Егет көймәдә бара.
Көймәдә бара егет,
Шул кызда бөтен өмет.

Егет рәшәткә тота,
Кыз яшелчә утырта.
Яшелчә утырта кыз,
Гел егеттә ике күз.

Кызы ут йотып йөри,
Егет ялкында көйри.
Ялкында көйри егет,
Әйталмый сөям диеп.

# МЕНДЕЛЕЕВСК ХИМИЯ ЗАВОДЫНА 100 ЕЛ

Моннан нәкъ бер гасыр элек Кама елгасына коя торган Тойма үзәнлегендә, Бондюг авылы янында, бу якларга ят булган зур-зур биналар калкып чыга. Авыллар өстен кара-кучкыл төтен болытлары каплый, сулыш юлларын буа торган газ, сөрем җәелә. Әнә шулай сәүдәгәр Ушковның химия заводы эшли башлый. Завод өчен бик уңай урын биредә: зур су артериясе — Кама якында гына, чимал да ерак түгел. Иң мөһиме: кара халык эшкә аптыраган, ачлыкта интегә. Мондагы җирле халыкның җиде кат тиресен тунарга була.

Озак еллар биредә эшләгән картлар сүзе белән әйтсәк, «дөньяда ук тәмуг газапларын күрсәтеп», Бондюг заводы елдан-ел үсә, киңәя. Унтугызынчы гасыр азакларында инде ул иң зур һәм иң әһәмиятле химия предприятиеләренең беренә әверелә. Россиядә беренче булып, тимер, бакыр купорослары һәм башка химик матдәләр җитештерә башлый, бөтен илдә җитештерелә торган сульфат кислотасының 45 процентын эшләп чыгара. Мәскәү, Казан, Петербург, Чикаго, Вена, Филадельфия шәһәрләрендә үткәрелгән төрле промышленность күргәзмәләрендә завод продукциясе медальләр белән бүләкләнә.

Заводның мондый уңышларга ирешүендә бөек рус химигы Д. И. Менделеевның роле зур. Д. И. Менделеев яңа производстволар оештырырга ярдәм итә, хәтта 1893 елда үзе дә бу заводка килеп эшли. Ул биредә Россиядә беренче булып төтенсез дары — пироколлодийны таба...

РСФСР Верховный Советы Президиумы 1967 елның 11 августында Алабуга районының Бондюг эшчеләр поселогын шәһәр итеп үзгәртү һәм аңа Менделеевск исемен бирү турында указ чыгарды.

Завод кешеләренең революция, гражданнар сугышы, беренче бишьеллык чорларындагы тормышы турында укучылар Ш. Камалның «Тын таулар җилкәсендә» исемле очеркы буенча беләләр инде. («Казан утлары», № 10, 1967 ел.) Журналыбызның бу санында, заводка 100 ел тулу уңае белән, Т. Сәгыйтовның заводның бүгенгө хәлләрен сурәтләгән түбәндәге очеркын тәкъдим итәбез.

## Т. Сәгыйтов

# БУЫННАР ЯЗМЫШЫ

*«... Бондюг заводы эшчеләренең тормышы ялтырамый. Алар гомер буе нужада. Эш хакы түбән, хәерчелек зур. Эшчеләр заводтан арып-алҗып, агарынып, хәлсезләнеп чыгалар... Начар ашау, пычрак һәм кысан торак, интектергеч авыр хезмәт һәм агулы химик газлар — болар барысы да организмны һәлакәткә этәрәләр, вакытыннан элек картаюга, эшкә сәләтне югалтуга китерәләр һәм, ниһаять, интеккән, кимсетелгән татар эшчеләрен кабергә кертәләр...»*

«Прикамская жизнь» газетасы, 8 март 1913 ел.

* * *



Министрлыкта кадрлар буенча җаваплы кеше аның белән озак кына сөйләшеп утырды.

— Сезнең турыда ишеткәнем бар минем, очрашу җаен гына көтеп йөри идем, — диде ул, Тимерханга сынаулы караш ташлап. — Хәзер сез баш инженер урынбасары. Шул заводта эшләп диссертация яклагыз. Шәп факт бу. Безгә андый тәҗрибәле кешеләр бик кирәк. Беләсезме, бик кирәк. Сәмәркандтагы ашламалар заводының баш инженеры хезмәтен тәкъдим итсәк, ә! Барырсызмы!

— Нәрсә, үзләрендә белгечләр беткәнмени! — диде Тимерхан, гаҗәпләнеп.

— Әгәр монысына шикләнәсез икән, Ерак Көнчыгышны сайларсыз, бәлки! Завод яңа корыла, үзең төзисең, яшьләрчә, сезнеңчә итеп әйтсәк, үзе бер романтика. Сез

утыз дүртенче елгы гына бит әле, шулай шул... Себер күңелгә хуш килмәсә, Кавказны тәкъдим итәм. Махач-Кала. Анысы да сафка басып кына килә...

Бу сөйләшү көтелмәгәндә булды. Шуңамы, Тимерхан бераз каушап калды:

— Сез мине авыр хәлгә куйдыгыз, тиз генә берни дә әйтә алмыйм,— диде ул.

— Шулайдыр. Уйлагыз, бер атна-ун көннән җавап бирерсез. Соңлатмагыз...

Алар хушлаштылар. Тимерхан чыгып китте. Аның бу минутларда, башкаланың халык белән шыгрым тулы урамнарында, театрларына йөрүдән дә бигрәк, ничектер, тизрәк өенә, заводына кайтасы килә иде. Сәбәбен үзе дә белми, ә күңел дигәнең ашкына... Сания нәрсә әйтер икән... Бондюгта да начар яшәми ул. Бөтен шартлары булган квартира бирделәр. Аның эчен көзгедәй ялтырап торган мебельләр бизи. Эше дә әйбәт. Кешеләр дә ярталар үзен. Әмма, зур шәһәр, бер баскычка югары урынга билгеләргә теләүләрен ишеткәч, әлегә кадәр сиздермәсә дә, әйдә, Тимерхан, китик, монда ни бар, димәсме!. Ә Идрис дус ни дияр! Һаман да Казанга күчәргә үгетләрме икән! Үзе техника фәннәре кандидаты булып алгач, Сания белән Тимерханны бигрәк тә кыстый башлады бит әле ул. Очрашкан саен аның иң беренче сүзе шул: менә шунда доцент урыны бар, тагын тегендә урнаша аласың. Әйдә, юләр, ычкындырма, сине яхшы беләләр бит анда!.. Башлы егет ул Идрис, ләкин бу нәрсәдә Тимерханны аңламый. Ә менә гражданнар сугышыннан соңгы елларда бу заводны ябылудан, аны таркатудан саклап калган һәм шул чакта аның ил күләмендә кирәкле булуын исбат иткән хезмәт ветераннары — Мәрдән, Мөбаракша бабайлар кебек кешеләр моңа ничек карарлар! «Күбрәк акча, зуррак дан артыннан китүеңме бу!» — диярләрме. Аннары Тимерханның үз хезмәт юлы да шушы заводка, мондагы кешеләргә күзгә күренми торган йөзләрчә җепләр белән бәйләнгән бит...

* * *

...Тимерхан Карпов исемендәге Бондюг химия заводына институт бетереп килде. Яңа мастерга карата берәү дә башта үзенең фикерен тиз генә әйтергә ашыкмады:

— Килде генә, карасын, күнексен,— диделәр.

Әйе, күрәсе, өйрәнәсе нәрсәләр дөрестән дә күп иде әле.

Бер көнне, инде заводка шактый ияләнә төшкәч, кинәт аның янына бер абый килеп сөйләште. Уртача буйлы, таза гәүдәле, үзе олы яшьләрдә булса да, шактый нык күренә бу абый.

— Күрәм, цехта яңа мастер икән! Исәнме, улым. Мәрдән абыең булам мин. Биредә эшләп, пенсиягә чыккан идем. Менә шулай килеп хәлләрне белеп киткәлим инде...

— Онытып бетермәү бик яхшы инде, тагын килегез. Миңа да киңәшләр бирерсез. Минем исемем Тимерхан, фамилиям Әхмәтов.

Алар үзара кул бирештеләр. Әмма карт аның кулын тиз генә ычкындырмады. Бик төбәлеп карады ул аңа.

— Мин сине үземнең бик якын дустыма охшатам,— диде аннары.— Габдулла улы түгелме син!

— Әйе, минем әтине ничек белә идегез!

Мәрдән ага кинәт кенә җавап бирмәде, Тимерханны каты итеп кочаклап алды, аннан ике иң башыннан тотып тагын аның йөзенә текәлеп карап алды да әйтеп куйды:

— Әйе, атаңа охшагансың шул. Ул да синең кебек чандыр, ябык яңаклы иде. Бергә эшләдек без аның белән. Беләсеңме, ул нәкъ шушы ук цехта производство калдыкларын чыгарып түгүче булып эшләде. Ә син инженер булып килгәнсең!

Их, әти, әти!.. Менә ничек туры килә бит ул. Тимерхан аны бик томанлы гына хәтерли. Аның Бондюг химия заводында эшләве турында әнисе сөйләгәне бар барын. Әмма ул сугышка киткәч, авылга күчтеләр, шунда үстеләр, укыдылар. Өлгергәнлек аттестаты алгач, Тимерхан Казанга китәргә теләде:

— Химия-технология институтына барып карыйм әле, әни.

— Анда кем булырга өйрәтәләр соң, улым!

— Химия заводлары өчен инженерлар әзерлиләр.

— Бар, улым, бар, тырышып кара. Атаң да шундый химия заводында эшләгән иде...

Әтисе эшләгән урыннарны күрәсе, ул йөргән юллардан атлыйсы килә иде малайның. Шуңа күрә Тимерхан бу якларга бик теләп кайтты. Кара әле, кирәк бит, шул цехка ук җибәргәннәр үзен!

Мәрдән агадан әтисе турында сорашасы килде аның. Мәрдән ага үзе дә, моны сизеп булса кирәк, Тимерханның сменаны тапшыруын көтеп торды.

Завод хәлләре, әтисе турында сөйләшә-сөйләшә, алар Революция тавына килеп чыкканнарын сизми калдылар.

Революция тавында — бүгенге якты тормыш һәм гүзәл киләчәк өчен кан коеп корбан булганнарның туганнар каберлеге. Ул шәһәрдән бер читтә, киң үзәнлек артына урнашса да, ил сукмагы аңа өзелми. Олылар, урта яшьләрдәгеләр, укучылар анда еш йөриләр, чәчәкләр утырталар. Халык, монда килеп, гүя чал тарихның үзенә баш ия. Ә каберлек өстендәге чәчәкләр, аз гына искән җилдә башларын селкеп, шул дәһшәтле көннәр турында сөйлиләр кебек... Узган гасырда ук эш хакларын арттыруны һәм ризык бәяләрен төшерүне таләп итеп баш күтәрү... Берничә елдан соң тагын шундый ук хәл... 1905 елда ук РСДРП членнары монда партиянең беренче ячейкасын оештыралар... Шул ук елны эш хакын арттыруны даулап күтәрелгән забастовка. Ул җиңү белән тәмамлана... Биредә эшләгән һәм илебезгә танылган революционерлар һәм галимнәр: Карпов, Гассар, Збарский, Бах... Гражданнар сугышының монда атылган дистәләрчә батырлары... Бу — алар каберлеге.

Бер вакыйганы икенчесеннән аерып алып кына карау һич мөмкин түгел. Чөнки азатлык һәм бәхет өчен көрәш, узган гасырдан башланып, еллар буе үрелеп көчәйгән һәм кискенләшкән. Чыныккан эшчеләр гражданнар сугышы вакытында да искиткеч зур батырлык күрсәтәләр. Бондюг химиклары, кулларына корал алып, ак чехларга, колчакның кара өерләренә каршы көрәшәләр. Дошманга калдырмас өчен, заводның иң кыйммәтле җиһазлары сүтелеп яшерелә, ә кайберләрен кызыллар ягына чигенүчеләр үзләре белән алып китәләр. Химикларның күбесе легендар Азин дивизиясе гаскәрләре сафында сугыша.

Азатлык һәм бәхет өчен завод зур корбаннар бирә. Халык аларның истәлеген хөрмәт итә. Бирегә картлар — тарихның җанлы шаһитләре аеруча еш киләләр. Шунысы да бар: революцион традициянең дәвам итүе нәтиҗәседер инде, бу як егетләреннән җиде кеше Ватан сугышында Советлар Союзы Герое булдылар...

Революция тавына бару Тимерханга бик күпне белергә ярдәм итте.

— Безнең җилкәләргә авырлыкны аз күтәрергә туры килмәде,— диде Мәрдән ага, тирән генә сулыш алып. Аның күрсенеп куюында авыр тормыш, бәхетсез үткән балачак өчен әрнү сизелеп тора иде.

— Без әтиең белән бер авылдан,— дип дәвам итте ул. Бабаң Миңнеәхмәт Столыпин реакциясе елларында вафат булды. Ярлы яши иде. Мунчада тордылар. Шундый фәкыйрь, хәтта керфеге дә юк дип, «керфексез Миңнеәхмәт» кушаматы алган иде ул. Балаларның аякка баскан бере морзалар көтүен көтте, үндүрт-унбиш яшеннән бәхет эзләргә чыгып китәләр иде. Атаңның абыйсы — Мөхсин, атаң, мин бәхет эзләп Бондюгка килдек...

Ул еллардагы хезмәт шартларын да сөйләп үтте Мәрдән ага. Әйе, искиткеч авыр шартларда яшәгәннәр алар. Шулай да сыгылып төшмәгәннәр. Эшчеләр арасында революцион чыныгу алган Мөхсин, туган авылына кайтып, колхоз оештырган. Ә Тимерханның әтисе — Габдулла Ватан сугышына китеп корбан булды. Мәрдән ага Хәсәнов гомере буе Бондюг химия заводында эшләгән, тырыш хезмәтләре өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән. Инде хәзер аның балалары да химиклар сафына басканнар: кайсы инженер, кайсы институтта укый...

Алар, өйгә кайтып җиткәч тә, кермичә озак йөрделәр әле. Кичке караңгылык урамнарга үзенең канатын җәйде. Битләрне сыйпап, җылы җил исә. Акрын гына пепердәшкән яфраклар да гүя серләшәләр... Тимерханга аеруча рәхәт булып китте. Ничектер, эшче гвардиясенең бер вәкиле, әтисе буыны кешесе белән тормышта шулай иңгә-иң атлавы инженерга үзе бер зур таяныч иде.

* * *

Карпов исемендәге химия заводы хәзер утыз ике төрле продукция җитештерә. Ә күләме ягыннан ул соңгы елларда гына да 12 процентка артты. Яңа цехлар салу коллективка зур мөмкинлекләр ачты. Якты биналар бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек итеп эшләнгән, автоматлаштырылган техника белән җиһазландырылган. Фән казанышларының производствога шулай кыю керүе сыйфатны яхшыртуга да шактый этәргеч ясады. Бөтен илебез күләмендә мактау яулап алган хлорлы кальций да бары тик бирeдә — Бондюгта — Менделеевскида гына ясала. Ул ике йөзләп адреска озатыла. Чит илдә дә яхшы бәя бирәләр аңа. Гипосульфит, натрий сульфиды, бөртекләндерелгән хлорлы кальций, реактив хлорлы кальций һәм магний сульфаты экспорт өчен дә чыгарыла. Кыскасы, бу завод СССР химия промышленносте җитештерә торган товарлар төренә һәм күләменә әһәмиятле өлеш кертә. Әле соңгы телеграмма да нәкъ әнә шуны раслый иде.

Кинәт кенә: «Натрий сульфиды чыгаруны киләчәктә берничә мәртәбә арттыра алмыйсызмы!» — дип сорадылар. Бу продукт көн эшкәртү, текстиль һәм төсле металлургия промышленностьларында киң кулланыла. Күрәсең, ул тармакларны тагы да үстерү күз алдында тотыла торгандыр.

Завод директоры бүлек җитәкчеләрен үз бүлмәсенә шул мәсьәлә буенча чакырды.

— Әйдәгез, уйлашыйк, Мәскәүгә нинди җавап бирәбез,— диде ул, һәркемнең фикерен тыңларга теләп.

Күбесенең киңәше шуңа кайтып калды: эшне кызулатырга, шулай итеп, планнан тыш натрий сульфиды җитештерергә, инде бу гына да канәгатьләндерми икән, ул очракта натрий сульфидын чимал итеп куллана торган продукция чыгаруны туктатырга кирәк. Әйтик, гипосульфитны...

Аннары директор Тимерханга эндәште:

— Әхмәтов, ә сез!

— Барлык резервларны да эзләп, планнан тыш җитештерергә омтылу әйбәт, ләкин гипосульфитны туктатуга мин каршы. Натрий сульфиды кебек ук, ул да әһәмиятле. Халык хуҗалыгында, көнкүрештә, шул ук текстиль промышленностенда, фәнни-тикшеренү институтларында гипосульфит аз таләп ителәмени! Әгәр Мәскәүдән иртәгә гипосульфитны күбрәк сораган телеграмма килсә!! Тагын шулай җыелып берәр төрле продукцияне туктатуга юл эзләрбезме!

— Конкретрак әйт, нәрсә тәкъдим итәсең! — дип, кырыс кына бүлдерде аны директор.

— Юллар күп бит, эзләргә кирәк. Шул ук гипосульфитны башкача ясап булмыймы!!

Директор бу тәкъдимне ишеткәч, сәер генә елмаеп куйды, ләкин фикерен белдереп бер сүз дә әйтмәде. Башкаларның да карашларында ирония сизелеп тора иде.

Директорның елмаюы нәрсә аңлатты соң!!. Ышанып бетмәвеме! Алай дисәң, Тимерхан биредә бөтен баскычларны да үткән кеше бит... Барий хлориды цехының җитәкчесе, заводның производство-техника бүлеге начальнигы, баш инженер урынбасары дәрәҗәсенә кадәр үстерделәр аны.

Бу кадәр зур ышанычны хезмәте, инженерлык фикерләре белән акларга тырышты ул. Цехлардагы күп кенә мәсьәләләрне фәнни нигезгә таянып хәл итәргә кирәк иде. Тимерхан төннәр буе укыды, исәпләде, формулалар өстендә утырды, лабораториядә тәҗрибәләр ясады. Күбесе хакында үзе укыган химия-технология институтының фән эшлеклеләре белән киңәште. Алар аңа ярдәм иттеләр, читтән торып аспирантурага укырга чакырдылар.

Аспирантурага кергәндә үк диссертация темасы әзер иде инде. Анда яшь белгечнең цехта эшләү дәверендә туган хыяллары һәм практикада ачыкланган фикерләре тупланган иде. «Барий концентратын нефть тапканда чыга торган газ белән эшкәртеп, барий сульфиды алу ысулы» дип исемләде ул аны.

— Мөһим тема, сезнең завод өчен генә түгел, ә бөтен ил күләмендә әһәмиятле, — дип канатландырды фәнни җитәкчесе Лев Иванович Кузнецов-Фетисов. Эшләр

дә уңышлы гына бара иде. Әмма гипосульфит мәсьәләсендә Тимерханга заводта шикләнеп карадылар. Телең белән сукалыйсың, ә менә сөйләгәнеңне исбат итә алырсыңмы, янәсе.

Ике көнгә генә сорап, ул Казанга китте.

— Бик әйбәт,— диде Кузнецов-Фетисов, Тимерханны тыңлагач,— берәр кешегә алынсын да хәл итсен. Үзе бер диссертация ич, әһәмияте дә синекеннән бер дә ким түгел.

— Шуңа күрә, әгәр рөхсәт бирсәгез, үзем алыныйммы әллә!

— Ә нигә син! — дип гаҗәпләнде фәнни җитәкче. Ә аспирант һаман үз фикерен куәтләде:

— Минемчә, сода белән күкерттән гипосульфит алырга мөмкин. Бу исә меңләгән тонна натрий сульфидын янга калдыру дигән сүз.— Тимерхан беренче тәҗрибәне ясап каравын әйтте, моның экономик яктан да зур әһәмиятен үзенчә исбатлый башлады.

— Күрәм, син тәмам шушы мәсьәлә белән генә яшисең бугай. Әгәр бик телисең икән инде, ни эшлисең, сөйләшеп карарбыз. Иптәшләргә аңлатырмын,— дип килеште Кузнецов-Фетисов. Аннан, бер мизгелгә тынып торганнан соң, сүзен дәвам итте.— Дөресрәге, сез мине дә кызыксындырдыгыз әле. Нәтиҗәсе начар булмаска тиеш...

Эзләнүләр башланды. Төрле тәҗрибәләр ясалды. Баштагы алынган продукциянең сыйфаты ифрат дәрәҗәдә начар иде. Аның өстенә реакция дә озак барды. Яңадан төрле тәҗрибәләр, яңадан сынап караулар. Сыйфатны яхшырту, реакцияне тизләтү йөзеннән керткән өч зур тәкъдим өчен аңа СССР Министрлар Советы каршындагы Уйлап табу комитеты авторлык таныклыгы бирде.

Бу тәкъдимнәрнең өчесе дә диссертациянең аерым бүлекләрен тәшкил иттеләр. Ул ысуллар завод күләмендә производствога кертелде һәм алар, ил күләмендә йөзләрчә мең сум экономия бирү белән бергә, чыгарыла торган продукциянең сыйфатын Америка, Англия һәм Япониядә җитештерелгән гипосульфитка караганда бик күпкә өстен булуын тәэмин иттеләр.

Диссертация уңышлы якланды. Ленинградтагы органик булмаган матдәләр химиясенең фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру институты, Харьковтагы Төп химия фәнни-тикшеренү институты, Иваново химия-технология институты, Ленинград технология институты, Мәскәү химия-технология институты белгечләре һәм җитәкчеләре Тимерхан Әхмәтовның бу эшенә югары бәя бирделәр: «Илебездәге күп кенә заводларда натрий гипосульфиты производствосының яңа цехларын проектлаштырганда бу диссертациядә куелган мәсьәләләрне кулланырга мөмкин», дип таптылар.

...Директор бүлмәсенә халык күп җыелган иде: бүлек җитәкчеләре белән цех начальниклары да килгәннәр. Иван Григорьевичның йөзендә елмаю күренеп тора, шатлыклы, эчкерсез елмаю.

— Әйдә, түрдән уз, Тимерхан Габдуллович,— диде ул һәм, урыныннан торып, кулын сузып каршы килде.— Котлыйбыз, Тимерхан Габдуллович, котлыйбыз. Рәхмәт сиңа.

Бөтенесе дә Әхмәтовны фәннәр кандидаты булуы белән тәбрикләделәр. Сүзне тагын директор Иван Григорьевич Лексин дәвам итте:

— Озын сүзнең кыскасы шул: сине Үзәк лабораториянең начальнигы итеп билгеләргә исәп. Син фән кешесе, бездә практикаң да зур, әйдә, заводның эшен берничә елга алдан күр.

Тимерхан, һәрвакыттагыча уң як иңбашын җыерды да:

— Әгәр ышанасыз икән, мин каршы түгел,— диде.

Бүлмәдәгеләр кул чаптылар.

* * *

Шулай итеп Тимерхан Союз күләмендәге зур заводның баш инженеры булудан да, институтта эшләүдән дә баш тартты. Атасы эшләгән, инде күңеленә якын булып әверелгән үз заводында лаборатория начальнигы булып калды.

Ул Мәскәүдән кайтышка куанычлы яңалык бар иде: энесе Кәүсәр өйләнгән.

Кәүсәр Тимерханнарда яшәде. Армиядән Бондюгка кайткач та, заводка урнашырга теләде.

— Өйрәнчек булып керәсең. Әти эшләгән хлорлы барий цехына барасың,— диде Тимерхан, башта ук.— Кичке мәктәптә укырсың. Аннан тагын дәвам итәрсең.

Өйрәнде егет, һәр эшне җиренә җиткереп башкаручан булып чыкты. Хәзер өлкән аппаратчы иттеләр үзен, читтән торып химия-технология институтын тәмамларга җыена.

Өйләнү турында сүз чыккач та: «Югарырак курска җитим инде»,— дип йөри иде. Сүзендә торды.

— Бәхетле генә була күрсеннәр инде, ходаем,— диде әниләре Зөһрә әби.

— Кайгырма, әни, эш сөйгән кеше бәхетсез булмый ул. Ә кода буласы кеше Хәсәншиннарга бу турыда кем тел тидерә ала! — диде Тимерхан.

Әйе, Бондюг авыл чакта да, инде Менделеевск шәһәре булып үскәч тә, химик Хәсәншиннар турында буыннан-буынга мактау сүзләре генә сөйлиләр. Нәсел даны шулай килә. Ачы тир түгеп, сөялле куллар белән ялганган ул.

Хәерчелекнең аргы ягына чыккан ярлы-ябагай Хәсәнша 1885 елда Ушков заводына килеп эшкә яллана. Чаллыдан ерак түгел генә урнашкан Абдулла авылыннан бәхет эзләп килә ул.

Бирегә дә ачлык, ярлылык. Пычрак казармада өч семья бер бүлмәдә яшиләр. Базар көнне ярты калач сатып алырга да акчалары җитми.

Газлы цехта эшләп агулангач, аңын югалткан килеш, аны завод йортына «саф» һава исәргә чыгарып ташлый торган булганнар. Ә ул һаваның «сафлыгын» әле хәзер дә картлар оныта алмыйлар:

— Завод янындагы баракта яшәүчеләр юган керләрен кибәргә элсәләр, бөтен чүпрәк-чапрак челтәрләнеп чыга иде,— диләр.

Газлар, хлорлы известь белән агуланган һава Хәсәншаның гомерен кыскарткан, ул вакытыннан элек дөнья куйган.

Аның улы Мөбәракша заводта Совет власте чорында эшли һәм аны киңәйтүгә катнаша. Мөбәракша Хәсәншин — хөрмәтле кеше. Тырышлыгы өчен Совет хөкүмәте аны Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләде. Хәзер Мөбәракша Хәсәншин тыныч ялда.

Хәсәншиннар традициясен дәвам итеп, бер төркем балалары химиклар сафына бастылар, читтән торып химия-технология институтында укыйлар. һәрберсе — хезмәт алдынгысы. Кызларның олысы — контакт цехының өлкән аппаратчысы — Фания Хәсәншина менә кияүгә чыга. Аңа Кәүсәр Әхмәтов өйләнә.

...Көткән туй да килеп җитте. Тимерхан кунакларны гармонь уйнап каршы алды.

— Һәй, гармонеңны әйтәм, өйдә матурлык өчен генә утырмый икән,— диде кайсыдыр.

— Кара әле, гел китап та, химия эчендә генә күмелүче түгел, ә музыкаль кеше дә икән ләбаса бу Тимерхан.

— Күрмисеңмени, аның гармоне эчендә йөз сандугач кереп оялаган.

— Юк, алай артык мактасагыз, уйнамыйм,— дип, Тимерхан баянын читкә алып куйды. Кодаларны түр башына утырырга кыстый башлады. Әнисе Зөһрә әби, кодагый Зәкия белән кода Мөбәракша, алар янына ук Мәрдән ага рәттән туры килделәр. Аннан башкалар.

Ике химиклар династиясе кушыла.

Кәүсәр белән Фаниянең тормышы, туй кунаклары сүзе белән әйтсәк, тигез гомерле, матур булсын!

* * *

Өйдәгеләр, диссертациясен язып бетергәч, Тимерханның вакыты иркенәер, орынып ук торган Кама буена чыгарбыз, табигать кочагында ешрак булырбыз инде, иншаять, бераз үзе дә ял итә алыр дип өметләнгәннәр иде. Ә чынлыкта исә бөтенләй алай булып чыкмады. Үзәк лабораторияне кабул иткәннән бирле йокларга гына кайта ул. Көне-төне диярлек шундагы эшләр белән мәшгуль. Әле тезелешне тизләтсеннәр дип, төрле бусагаларны таптый, я булмаса лабораторияләр хәзерге заман техникасы

белән генә җиһазландырылсын дип, Казан, Мәскәү, Ленинград, Киев шәһәрләреннән яңа приборлар, аппаратлар кайтарту өчен чаба.

Шушы яңа үзәк лабораториядә завод, униләп институт белән килешү төзеп, төрле фәнни эшләр алып бара. Профессорлардан Г. Х. Камай, А. А. Афанасьев, доцентлардан Л. И. Кузнецов-Фетисов, А. И. Милютин, З. Ф. Зәйнуллин һәм башкалар, берничә мәртәбә килеп, гаять әһәмиятле киңәшләр бирделәр.

Андый иҗади дуслык лаборатория коллективын тагы да канатландыра. Фәнни-тикшеренү эшләре торган саен киңрәк колач ала. Галимнәрнең киңәшләрен тотып, үзәк лаборатория коллективы минераль тозлар алу буенча яңа ысуллар тапты. Мәсәлән, натрий тиосульфатын алуның яңа юлы дөньяда беренче булып биредә барлыкка килде... Фотография промышленностенда киң кулланыла торган барий сульфаты җитештерүнең дә тагын бер ысулы табылды. Сыйфаты да яхшы, арзан да, файдалы да.

Тимерханга фәнни яктан да, хуҗалык эшләре белән дә җитәкчелек итәргә кирәк. Ә шулай да, алар никадәр генә ялыктырмасын, берәр тәҗрибә уңышлы чыкса, бөтенесен дә юып алгандай итә. Ни генә булмасын, күзгә күренерлек уңышлар бар...

Әйе, эше күп аның. Өстәвенә тагын химия-технология институтыннан диплом эшләренең фәнни җитәкчесе булуын да үтенделәр. Ризалык бирмәсәң дә яхшы түгел. Студентларның һәрберсе күз алдында эшләп укыдылар. Завод цехларыннан торып ачышлар ясыйлар. Унҗиде кеше аның кул астында диплом әзерли. Унҗиде әһәмиятле яңалык, ачыш дигән сүз ул. Мондый нәрсәгә битараф карарга ярыймы соң!!

Ә алда никадәр планнар! Яңа цехлар корыла, чыгарыла торган продукциянең төре дә, күләме дә үсә бара. Бүгенге көндә яраксыз дип ташлап барыла торган производство калдыкларын эшкәртеп тә дистәләрчә исемдәге химикатлар җитештерергә мөмкин бит. Әнә заводтан ерак түгел генә нефть фонтаны бәрә. Республикабыз күләмендә азмыни алар! Ә шул нефть ятмаларында миллионнарча тонна тозлы су бар. Аны химик юллар белән эшкәртсәң, нинди генә продукция алып булмас иде! Сыек хлор, селте, сода, йод, бром, хлорлы магний, кальций хлориды, калийлы ашламалар дисеңме,— саный китсәң, исемлек бик озынга сузыла. Бу үзе искиткеч зур перспективалар түгелмени! Менә кайда ул фәнни ачышлар, производствога һәм фәнгә санап бетергесез файда китерә торган кандидатлык, докторлык диссертацияләре...

⁂

**Госман Бакиров**

# КАЛӘМ ҺӘМ СУГЫШ



Жәйнең матур көннәре. Иген кырлары, җимеш бакчалары кояш нурына коенып утыра. Сугыш полосаларында хуҗасыз калган игеннәр, саргаеп, тапталып беткәннәр. Кайбер урыннарда исән калган игеннәр, башларын селкеп, гүя хуҗаларын чакыралар. Каршы як тау битендә җан әсәре юк. Бүген нигәдер дошман да тынып тора әле. Шуннан файдаланып, мин батарея минометчылары белән политбеседа үткәреп ятам. Агач ботакларына яшеренгән батареялар ут ачарга команда көтәләр. Сигнал була калса, барысы да әзер. Яшел чирәм өстендә сугышчылар тезелеп утырган. «Кызыл Армиянең көче нәрсәдә?» дигән темага беседа бара. Авыр сугыш юллары үткән минометчылардан берәү әле кичә генә өйдән килгән хатны укып күрсәтә. Тылда көн-төн фронт өчен эшлиләр икән, дип нәтиҗә ясый ул.

Беседа күңелле генә барганда, землянка эчендә телефон шалтырый. Дежурный, чокыр эченнән башын гына чыгарып, мине чакыра. «Бюро утырышындыр» дип, эшемне бүләм. Полк партия оешмасында бюро члены булганга, мине шулай еш чакыралар. Трубканы алам. Телефонда иптәш «28». Бу «28»нең политик эшләр буенча полк командиры урынбасары майор Новиков икәнлеге миңа билгеле.

— Тыңлыйм, иптәш «28»! — дим.

Ул миңа, ярты сәгать эчендә партбюро эшләрен урынбасарга тапшырып, «Амур»га килеп җитәргә куша.

Ашык-пошык әзерләнеп юлга чыгам. Полк штабы бездән ярты километр чамасы арттарак. Ул да ташландык бер хутор тирәсендәге чокырга урнашкан.

Сталинградтан Польша чигенә кадәр авыр сугыш юлларын бергәләп үткән, бөтен шатлык һәм кайгыларыбызны бергәләп күтәргән якын дусларым яшел урман читендә мине озатып калдылар.

— Хушыгыз, дусларым!

Иген кырларындагы җәяүле сукмак буйлап, штабка киләм. Землянка эчендә, телефонистка янында, майор Новиков утыра. Честь биреп, каршына басам.

— Сезне фронт газетасына эшкә чакыралар,— ди ул, генерал Шатилов кул куйган кәгазьне күрсәтеп.— Эшне өзеп килдегезме?

— Нинди газетага, иптәш майор? — дим.

— Фронт газетасына!

— Алайса «Ватан намусы өчен» газетасына икән! — дим мин.

Бу газета миңа бик таныш, безгә килеп тора. Сугышчылар яратып укыйлар, көтеп алалар. Редакторы — Риза Ишморатов. Газета битләрендә күренгән шигырьләре буенча чамалыйм: М. Садри һәм Гали Хуҗиев иптәшләр дә шунда булырга кирәк. Туктале, алар минем бу частьта булуымны каян белгәннәр соң?! Хәер, бу газетага мин бик еш кына хәбәрләр язып тора идем, шуннан чамалаганнардыр инде. Шул турыда

уйланып торган арада, майор кечкенә генә бер кәгазь кисәгенә шапылдатып печать суга да миңа суза:

— Менә — маршрут. Фронт штабына,— ди ул.— Анда сиңа газета редакциясе урнашкан авылны күрсәтерләр. Эшегездә уңышлар телим!

Көн кичкә авышып бара. Караңгы төшкәнче берәр авылга җитеп булмасмы. Ялгыз барам. Әле генә сибәләп үткән җәйге яңгыр җәяүле сукмакны боламыкка әйләндергән, баскан саен аяклар тая. Бара торгач, артка да борылып карыйм. Күк читенә зәңгәр төтен җәелгән, һавада ялкын шәүләсе. Авыллар яна, кичке тынлыкны бозып, туп тавышлары гөрелди... Әйе, иптәшләрем ут эчендә калды, ә мин, атлаган саен, фронттан еракլаша барам.

Караңгы төшеп килә, алда ярым җимерек бер авыл күренә. Караңгылык куерганчы шул авылга җитәсе иде. Ашлык арасыннан турыга сыптырам. Авылда кичке тынлыкны ярып, солдатлар җырлый.

Урамга килеп кергән ят кешене күргәч, өй түрендә тәмәке көйрәтеп утыручылар аптырап калалар, шикләнәләр. Кай якка юл тотуымны сөйләп бирәм, язуымны күрсәтәм. Бу авыл Иске Беркути булып чыкты. Немецлар тирә-юньне миналаганнар, саперлар хәзер шуны арчып яталар икән, алар минем кайсы сукмактан килеп чыгуымны белгәч, аптырап калдылар. «Ничек син минага эләкмәдең?!» диделәр. Әҗәл җитмәгән, күрәсең!

Салам җәелгән идәнгә йокларга ятабыз. Йокыга киткәнче ерак тылда калган семьяларыбыз турында сөйләшәбез. «Кайчан немецларны илдән куып чыгарырбыз икән инде», диләр солдатлар. Иртәгесен алар мине бик якын итеп озатып калалар.

Фронт штабын эзләп барам, юлда бер машина очрый, ул мине утыртып алып китә. Менә Көнбатыш Украинаның кечерәк кенә бер шәһәренә — Тернопольгә килеп керәбез. Эх, Тернополь! Кыш көне, буран эчендә без сине камап торган идек. Атна буена дошман безне урамыңа кертми азаплады. Ниһаять, ул каршы тора алмады, бирелде. Без алга киттек! Тернополь, син болай да минем өчен бик истәлекле шәһәр: 1915 елда ук, беренче дөнья сугышында да мин синең капкаңны бер каккан идем инде. Ул сугышка да гади бер солдат буларак катнашкан идем мин. Күпме сулар акты, күпме җилләр исте, ә мин һаман исән...

Машина, бормалы урам буйлап, алга чаба. Ә мин шул үткән көннәрне күз алдыма китереп барам. Ерак та түгел, Чернеховка дигән бер авылга туктыйбыз. Фронт штабы шунда икән. Йорт алдына берничә җиңел машина туктаган. Капка төбендә кораллы солдат басып тора. Язуны күрсәтеп, кереп китәм. Ни өчендер ачык ишеккә плащ-палатка корылган. Рөхсәт сорап, эчкә үтәм. Балчык стеналы иркен өй эчендә берничә язу өстәле артында төрле дәрәҗәдәге хәрби кешеләр утыра. Чибәр генә бер кыз машинкада баса, түрдәге өстәл янында бер капитан телефонда сөйләшә, эше беткәнне көтеп торам. Шуннан соң каршысына басып честь бирәм дә язуны сузам. Ул, аңа күз йөртеп чыга да, урыныннан торып, эчке бүлмәгә кереп китә.

Мине озак тотмыйлар, тиешле язу тоттырып, якындагы бер авылга өйрәтеп җибәрәләр. Редакция Сокорика исемле поляк авылына урнашкан икән. Авыл тирәсендә ямь-яшел болын җәелеп ята. Шул болынны урталай ярып, шактый киң бер елга ага. Суы ярыннан ташып торса да, гадәттәгечә каз-үрдәк күренми. Сәбәбе билгеле: әле күптән түгел генә авыл фашист килмешәкләрдән арынган. Фронт моннан ерак түгел икән.

Ап-ак балчык стеналы хаталарның түбәләре кайсы чирәп, кайсылары салам белән ябылган. Урамнары тын. Җирле халык бөтенләй күренми диярлек. Ара-тирә хәрби киемлеләр күренгәли. Авылга килеп керү белән, мине шул нәрсә гаҗәпләндерде: кайдадыр машина гөрләвенә кушылып саф татарча җыр яңгырады. Аякларым ирексездән шул якка борылдылар. Якынлашкан саен, җыр ачыграк ишетелде. Кызлар җырлый иде.

**Зәңгәр күлмәгем чайкарга, Гөлзадә,**
**Зәңгәр күлләр тапмадым, тапмадым.**
**Башкаларда һич күңлем юк, Гөлзадә,**
**Сине сөям, аппагым, аппагым!**

Канлы сугыш юлларына баскан көннәрдән бирле, үз җырларыбызны ишеткәнем юк иде. Мин эреп киттем. Уйларым еракта калган Казаныбыз тирәсенә очтылар.

Ерак поляк авылларына бу татар кызлары кайдан килеп чыккан соң! Билгеле, болар фронт газетасы басыла торган типографиядә эшләүче наборщик кызлар инде, дип уйлап куйдым мин һәм чыннан да ялгышмадым: ишек алдында, агач яфраклары астына яшеренгән автомашиналарда газета басу, хәреф кою «цехлары» эшли, ачык тәрәзәләре урамга караган балчык өйләрдә кызлар җырлый-җырлый хәреф җыялар. Нәкъ өстенә килеп чыктым, ахры. Әнә, капкадан чыгып, бер хәрби урга таба үтеп бара, редакциянең кайда урнашуын сорамакчы булып, аңа дәшәм:

— Иптәш капитан!..

Шулай диюгә, ул борылып карады һәм... кочаклаштык. Ул — каләмдәш дусларымнан Мөхәммәт Садри иде.

«Ватан намусы өчен» газетасы алты почмаклап салынган чиста гына бер поляк йортына урнашкан икән. Бер почмакка хуҗалар кысылган, икенче яртысында — редакция. Түр тәрәзәгә каршы куелган язу өстәле янында газетаның редакторы майор Риза Ишморат белән капитан Гали Хуҗи эшләп утыралар. Кочаклашып күрешәбез.

— Таптык бит үзеңне! — ди Риза, елмаеп.

— Мин дә менә оягызга килеп җиттем! — дим.

Көндезге аш вакыты җиткән иде, күрше йортка урнашкан ашханәгә киттек. Анда рус, украин, казакъ, үзбәк офицерлары — газета эшчеләре утыра. Риза миңе рус газетасы редакторы полковник Жуков, украина шагыйре Андрей Малышко, үзбәк драматургы, ләкин үзе татар Зиннәт Фәтхуллин һәм башкалар белән таныштырды. Алар төрлесе төрле йортларга урнашып эшлиләр, ашау-эчү вакытында яки партия җыелышы булганда гына бергә очрашалар икән.

Редакция работниклары арасында атаклы рус шагыйре С. А. Безыменский да күренә. Ул 1919—20 елларда Казанда яшәгән һәм беренче әсәрләрен дә шунда иҗат иткән кеше. Ләкин шагыйрь кешеләр белән аралашырга бик үк яратмый, күрәсең. Һәрвакыт ялгыз йөри, күбрәк редакциядә машинистка янында утыра, нәрсәдер әйтеп яздыра, шуннан соң озын гәүдәсен сыгылдырып, авыл урамы буйлап, эш урынына юнәлә. Алгы сызыкка чыгып йөргәне дә сизелми, ә сугышның соңгы көннәрендә исә ул безнең тирәдә бөтенләй күренмәс булды.

Ашханәдән чыккач, әлеге «матбугат» йортына керәбез. Монда Хәят, Рәшидә исемле Казан кызлары эшлиләр икән. Авылдан-авылга, шәһәрдән-шәһәргә күчеп, бөтен Украинаны үтеп чыккан шат күңелле бу кызларга мең рәхмәт әйтәсе килә минем. Алар көннәр буе хәреф кассасы янында басып, ару-талуны белми эшлиләр, йөгерек куллар кырык төрле кассадан көннәр буе хәреф чүплиләр.

— Һай, матур җырлыйсыз икән сез, кызлар! — дим мин, алар белән исәнләшеп.

— Җырлыйбыз шул, абый, җырлагач, күңеллерәк була! — диләр алар, бер-берсенә карашып.

— Туган яклар искә төшә! — ди икенчесе.

Касса тирәсендә рус кызлары да бар. Алар да җырлыйлар, татарча бер авыз сүз белмәсәләр дә, татар кызларына кушылып җырлыйлар икән.

Кич булды. Күчмә электр станциясе көче белән өйләр яктыртылды. Тәрәзәләргә кара пәрдәләр эленде. Яктылык күрсәтергә ярамый, дошман самолетлары очкалап тора. Еракта туп тавышлары гөрелдәсә дә, баш очында снарядлар ярылмый әле, ләкин төнлә тынычлап гына йокларга туры килми икән монда. Бендеревчылар дигән сатлык җаннар авыл тынычлыгын бозып йөриләр. Кичә генә әле күрше авылларда күренгәннәр, запас частьтагы солдатларга һөҗүм иткәннәр. Бәрелешләр булган. Фронт газеталары урнашкан бу авыл да тыныч түгел. Шуңа күрә көне буе язу өстәлендә эшләп утырган Гали Хуҗи белән Мөхәммәт Садри, винтовкалар асып, урамга чыгып киттеләр. Риза белән икәү генә калдык, бер караватта икәүләп ятабыз. Күзгә йокы керми. Үткән көннәр, бергә укып йөргән чаклар искә төшә. Мин Сталинградтан алып бирегә килеп җиткәнче баштан кичкәннәр, канлы сугыш юллары турында сөйлим. Риза фронт газетасы эшләре белән таныштыра. «Ватан намусы өчен» газетасы биш телдә: рус, татар, украин телләрендә генә түгел, казакъ һәм үзбәк телләрендә дә чыгарыла икән.

Газета 1942 елның декабрендә Воронеж өлкәсендә чыга башлаган. Аның баштагы саннары шагыйрь Әхмәт Ерикәй җитәкчелегендә чыгып килгән. Шул көннәрдә Гали

Хуҗи да килеп кушылган. Ләкин газетаның беренче редакторы Әхмәт Ерикәйгә озак эшләргә туры килмәгән, аны ерак тылга күчергәннәр. Аннан газетага Риза Ишморатны редактор итеп билгеләгәннәр. Озакламый шагыйрь Мөхәммәт Садри да редакциягә килеп эшли башлаган.

Мөхәммәт Садри, газетага килеп эшли башлаганчы ук инде, каты сугышларны башыннан кичерә. Мәскәү тирәсендәге сугышларда катнаша, контузия алып, госпитальдә ятып чыга. Тагы сугышка керә. Дошман бомбалары астында калып, ул икенче кат контузия ала. Аннары СССР язучылары союзы идарәсеннән Фадеев аны фронт газетасына эшкә җибәрә. Мөхәммәт Садри бу газетага әнә шулай килеп эләгә...

Совет Армиясе көннән-көн шәһәр-авылларыбызны дошманнан азат итеп, һаман алга омтыла. Җиңүдән өметен өзгән фашист өерләре, авылларны яндырып, шәһәрләребезне җимереп чигенә. Редакцияләр дә, авылдан-авылга күчеп, фронтка иярәп бара. Бер урынга туктап, атна-ун көн эшли дә, тагы күченә, тагы алдагы сызыкка якынлашып эшли башлый. Әнә шулай Польша туфрагына аяк басканчы, ул егермедән артык авыл һәм шәһәргә туктап эшләгән...

Тынычлап йокыга китәргә дә өлгермәдек, төнге сактан Гали белән Мөхәммәт кайтып керде.

— Безнең чират тыныч үтте, алмашка Украина газетасы работниклары чыкты,— диләр алар.— Әйдәгез, бераз йоклап алыйк!

Иртәгесен мин дә эшкә утырдым. Атнага ике тапкыр чыга торган дүрт битле газетага материал өлгертергә, алгы сызыктан килгән хәбәрләрне эшкәртергә кирәк. Чираттагы санның корректурасы килгән, аны да күздән кичерәсе бар. Газетаның җаваплы секретаре Гали Хуҗи газетаның макетын төзи. Мөхәммәткә килсәк, ул бик тынгысыз икән. Командировкадан кайтып керми, диләр аның турында. Менә бүген дә, әпен-төпен иртәнге чәйне эчте дә, юл сумкасын асып, алгы сызыкка чыгып китте. Риза, биш редакциянең бергәләп үткәрелә торган утырышына барам, дип күздән югалды...

Фронт тагы кузгалды, без аның артыннан алга күчәбез. Фронтка якынлашкан саен, тынычсызлык арта бара, авылларда солдатлар команда көтеп яталар. Безгә урын да юк. Бушаган бер йортка кереп урнашабыз. Төнлә тревога. Без өстәлләрдән кузгалып, урамга чыгабыз, читән кырыйларына казылган чокырларга посабыз. Кемгә каршы? Бая әйткәнчә, тагын шул бендеревчылар кузгалган!

Мин инде — ике елга якын ут эчендә йөргән кеше. Тынычсыз төннәр меңә бер дә ят түгел. Ләкин бит безнең төп эшебез сугыш түгел, без — газета эшчеләре. Көн аралаш газета өлгертергә тиешбез. Шулай да сак булырга кирәк. Бер кулда каләм булса, икенчесендә корал булсын! Шундый көннәрнең берсендә хәбәрчеләр киңәшмәсе үткәрергә җыенабыз. Риза җыелыштан кайтып, доклад әзерләргә утыра. Тәрәзә ачык, күктә самолетлар шаулый, якыннан гына дөбердәп танклар үтеп бара. Радиоалгычлар китергән хәбәрләрне газетабызга кертергә ашыгабыз. Һава дулкыннары бик тиз хәрефләргә әйләнә.

Чия агачларына күмелеп утырган Польша авылы. Тәбәнәк кенә мәктәпкә хәбәрчеләр җыелган. Бирегә Беренче Украина фронты сугышчылары, Ватан сугышы геройлары килгән, күкрәкләрендә орденнар ялтырый. Танышлар, бер-берсен кочаклап, күрешәләр.

Җыелышта Украина газетасы хәбәрчесе майор Борзенко доклад ясый, язучы Борис Горбатов халыкара хәл турында сөйли. Аннан соң секцияләргә бүленеп эшли башлыйбыз. Татарлар да күп. Безнең секцияне майор Риза Ишморат алып бара, газетаның эше турында доклад ясый. Җыелышка алгы сызыклардан башкорт шагыйре Гыйлемдар Рамазанов, язучы Гали Ибраһимов, драматург Зәйни Шаһиморатовлар да килгән. Барысы да — безнең хәбәрчеләребез.

Рамазанов Беренче танк армиясенең механикалаштырылган унынчы бригадасыннан килгән. Ут эченнән газетага ялкынлы шигырьләр язып торучы бу гади солдатны мин беренче тапкыр күрәм. Ул Мәскәү тирәсендәге каты сугышларда әтисен югалткан. Аның кабере Бородино янында. Шуңа күрә фашист илбасарларга каршы нәфрәте аның бик көчле. Хәзерге көндә филология фәннәре докторы дәрәҗәсенә күтәрелгән шагыйрь Рамазанов бу җыелыштан соң безгә тагын да якынлашыбрак китте, газета-

бызга тагын да активрак катнаша башлады. Ул безнең барыбызның да якын дустына әйләнде.

Язучы Гали Ибраһимов та безнең актив хәбәрчебез булып китте. Хәзер дә күз алдында: ул винтовкасын иңенә салып килеп керә дә, куеныннан бер төргәк кәгазь чыгарып, өстәлгә куя, үзе кыюсыз гына читкә басып, безнең фикерне көтеп тора иде. Аның да хәбәрләре, хикәяләре газетабызда еш басылдылар.

Икенче көнне политбүлек начальнигы генерал-майор Шатилов һәм авиация генералы С. Рамазанов белән очрашу үткәрдек. Генерал Шатиловның «Без Берлинда булачакбыз!» дигән сүзләре һәммәбезне дә дәртләндереп җибәрде. «Ура» кычкырып кул чаптык! Бу җыелыш алдыннан Р. Ишморат, көн-төн утырып, Беренче Украина фронтындагы татар сугышчылары исеменнән тылга, татар халкына хат язган иде. Җыелыш бу хатны бик хуп күреп кабул итте, катнашучылар кулларын күйдылар. Бу хат ерак тылдагы туганнарыбызны яңа җиңүләргә дәртләндерде һәм җавап итеп газетабызга бик күп җылы хәбәрләр килде.

Бу киңәшмәдән соң, тагын алга күчендек. Гитлерга һөҗүм ясаганнар икән дигән хәбәрләр таралды. Ниһаять, икенче фронт та кузгалды. Союзниклар: «Болай карап торып кына эш чыкмас, ахры!» диделәр, күрәсең! Әйдә, иш янына куш булыр. Дошманның соңгы сәгате якынлаша. Ул, суы кибә барган күлдәге балыклар кебек, кая керергә урын таба алмый!

Фронт газеталарында эшләүче башка иптәшләребез белән йөрешә алмыйбыз, ләкин алардан сәлам хатлары өзелеп тормый. Дүртенче Украина фронтыннан Ибраһим Гази: «Фашистлар Кырым якларыннан үкчәләрен күтәрделәр, тиздән арт сабакларын укытырбыз аларның!» — дип яза. Беренче Балтик буе фронтында чыга торган «Алга, дошман өстенә» газетасында эшләүче Афзал Шамов, Абдулла Әхмәтләр дә: «Фрицларның әчләре китә, Россия икмәге килешмәде, ахры, сызалар бездән, ләкин белеп торсыннар, без аларны үз өннәрендә дөмектерәчәкбез», — дип, күңел күтәренкелеге белән шатлыкларын уртаклашалар.

Лейтенант Сибгат Хәким Курск дугасында алгы сызыкта взвод белән командалык итә. Бервакыт Гали Хуҗи аның эзенә төшә, эзләп таба, ләкин аның янына җибәрмиләр, чөнки Сибгат ут эчендә сугышчан сакта тора, аларга ашны да качып-посып кына китерәләр. Гали, ничек итсә итә, аш илтүче солдатка ияреп, үрмәләп, Сибгат янына килеп чыга. Ике шагыйрь кочаклашып күрешәләр, төн буе землянкада сөйләшеп утыралар. Сибгат үзенең яңа шигырьләрен биреп җибәрә. Шул очрашудан соң, без Сибгат Хәкимнән хат алгалап тора идек, бу арада аннан хат-хәбәр юк. Борчылабыз. Каләмдәшләребез М. Җәлил, А. Алиш турында да бернәрсә белмибез. Ф. Кәримнең яраланып кайтуын, госпитальдән чыккач, тагын фронтка китеп баруын ишеткән идек, шуннан соң аның белән элемтә өзелеп китте әле.

Хәбәрчеләр алгы сызыкларда йөргәндә, төрле хәлләр дә булып куя. Менә рус газетасында эшләүче хәбәрчебез майор Борзенко каты һөҗүм сәгатьләренә туры килә, ул, каләмен юл сумкасына кыстырып, кулына автомат ала да, сугышчылар белән бергә, ут эченә кереп китә, командиры һәлак булган батальонны әйдәп, дошман өстенә ташлана һәм каты сугыштан соң аның батальоны дошман өерен туздырып, әһәмиятле пунктны яулап ала. Хәбәрченең бу батырлыгына югары бәя бирелде: ул Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек булды.

Фронттагы уңышлы һөҗүмнәр безне чиксез шатландыра. Польша туфрагын иңләп йөргән көннәрдә безнең өчен тагын бер куанычлы хәл булды: Казаннан язучы Газиз Иделле белән журналист Фатыйма Галиева килеп төште. Алар туган Татарстан якларыннан бик күңелле хәбәрләр, кайнар сәламнәр алып килгәннәр. Ерак тылда калган яктәшләребез фронт өчен янып-көеп эшлиләр икән.

Газиз Иделле язучылар дөньясындагы яңалыклар белән таныштыра, Фатыйма үзенең ягымлы матур тавышы белән Сарман көен суза:

**Сарман буйлары киң ялан,**
**Печәннәре җитәр бер заман шул,**
**Печәннәре җитәр бер заман.**
**Кавышулары ла бик күңелле,**
**Әмма аерылышу бик яман.**

Без тыңлыйбыз, күңелләр еракта калган Татарстаныбыз якларында: аның яшел болыннары, ярларына кадәр тулып торган инеш-сулары, анда йөзеп йөргән казлары, үрдәкләре — барысы да, барысы да күз алдына килеп басалар... Якташларыбыз шулай күңелләрне күтәргән көннәрдә фронтта да зур шатлыклы вакыйгалар булды: I нче Балтик буе, I—III нче Белоруссия фронтлары һөҗүмгә күчте, ике меңләп авыл азат ителде.

Газиз Иделле җиң сызганып эшкә керешә, ул зур-зур очерклар язды, партия җыелышларында актив чыгышлар ясап, безне куандырды. Ләкин тыныч почмактан килгән кешегә монда бер нәрсә җитенкерәми — мунча юк, полякча әйткәндә, «вазня» юк, өйдә юыналар. Без инде күнегеп киләбез, ә Газиз көн дә шул турыда зарлана, хәтта ул Тукайчарак иттереп бер шигырь дә «иҗат» итеп ташлады:

**Ни сәбәптән бу Польшада**
**Хәтта тәнгә мунча юк!**

Күп йөри торгач, ул аңа ирешә.

Беркөнне машинага редакция җиһазларын, хәреф кассаларын төяп, күрше авылга күчеп барганда, дошман самолетлары килеп чыкты. Алар шаулап баш өстендә әйләнәләр, анда да, монда да бомба яудыралар. Менә сиңа мунча! Машиналарны туктатып, юл читләрендәге чокырга посабыз. Тирә-юнебездә бомбалар ярыла, баш очыннан сызгырып бомба ярчыклары оча. Ут көчәйгән саен, без җиргә сеңә төшәбез. Бәхет бар икән: дошман самолетлары безгә зыян китерә алмады, бомбаларын ташлап бетерделәр дә китеп бардылар. Без, чокырлардан чыгып, тагын машинага төяләдек. Төяләдек, ләкин Газиз әле һаман да күренми иде. Без, аптырашып, аны эзли башладык. Ул, бер дә исе китми генә, чокыр эченә посып утыра икән.

— Әйдә, Газиз, мунчаның пары бетте инде! — дибез.— Киттек, сине генә көтәбез.

Газиз өчен бу күренеш бер чиркәнеч алу гына иде, юлда артык борчу булмады. Чокырлы-чакырлы юллар үтеп, алга барабыз. Фронт сызыгына якынлашкан саен, туп гөрелтесе көчлерәк ишетелә. Авыллар яна, кырда ватык танклар, орудиеләр аунап ята. Кичә генә биредә каты сугышлар булып узган, кырга дошман солдатларының үле гәүдәләре сибелгән. Сугыш вакытында урман эчендә яки кар базларында яшеренеп яткан хатын-кызлар, көрәкләр тотып, кырга чыкканнар, үлекләрне күмеп йөриләр. Юл тулы тере мәетләр — немец әсирләре очрый. Пычракка баткан бу җан көекләре, башларын түбән иеп, көч-хәл белән генә атлыйлар. Машиналар юл пычракларын чәчрәтеп үтеп киткәндә, аларның өметсез күзләре озатып кала. «Менә, теләгегезгә ирештегез!» — дибез без, аларга күз ташлап.

Юллар пычрак, ара-тирә ябалак кар очкалый, ләкин язгы кояш нурлары бу мамык кар бөртекләрен бик тиз тамчыга әйләндерә. Яз җитә, без дә, язгы кояш кебек, зур җиңүләр белән дошман иленә якынлаша барабыз. Менә Польшаның соңгы авылы. Ак түшле тәбәнәк йортлар, очлы манарасын күккә сузган поляк костеле. Ул, сугыш сөременә исе китмәгәндәй, тын гына утыра. Кайнар көннәрдә урман эчендә яткан авыл халкы, кул арбаларына төялгән урын-җирләрен өстерәп, туган йортларына кире кайтып бара. Машинага юл сабып торганда, алар «Рус солдатларына зур рәхмәт!» дигән кебек, елмаеп калалар.

Алда тар гына инешкә салынган чуен күпер күренде. Аның янындагы ала-кола буялган баганага «Польша — Германия» дип язылган такта эленгән. Димәк, без Германия туфрагына, дошман җиренә аяк басабыз. Әйе, гитлерчыларның үз өенә үтеп керәбез. Хәерле сәгатьтә!

Идел ярларына аяк баскан, Урал тауларына үрмәләргә исәп тоткан гитлерчыларны илебездән кудык. Нинди утлы көннәр баштан кичмәде! Ростов, Сталино (хәзерге Донецк), Киев урманнарында канлы сугышлар. Хәтерлим: Сталинога килеп җиткәч, минометларыбызны шәһәр тирәсендәге бараклар янына куеп, дошманга ут ачтык. Таң алдыннан шәһәрне азат иттек. Урамнарда төтен, шәһәр театры яна. Төн буе йокы күрмәгән шәһәр халкы — урамда. Алар безне кочакка алалар, шатлыкларын уртаклашалар.

Урам уртасында туктап торган арада бер солдат капка төбендә басып торган балалы хатынны күрсәтте:

— Иптәш Бакиров, арагызда татарлар юкмы? — диде.— Якташларын бик күрәсе килә икән.

Баласын күкрәгенә кысып торкан бу хатын, татарча исәнләшкәч, елап ук җибәрде:

— Ике ел җәфа чиктек бу ерткычлар кулында. Мең рәхмәт сезгә. Ике елдан артык вакыт туган халкымны күрәсем килеп тилмердем. Сумкагызда татарча берәр китап юкмы?

Фронтка китәр алдыннан гына «Яшь патриотлар» исемле очерклар җыентыгын басарга биреп калдырган идем. Мин фронтта үткәргән көннәрдә шул җыентык басылып чыккан икән, бер данәсен миңа да җибәргәннәр иде. Шул китапны калдырдым. Бик тә куанды. Елап озатты...

...Машинабыз Германиянең беренче шәһәре — Крайцбургка килеп туктаганда, мин, уйларымнан арынып, күземне ачтым. Крайцбург Бреслауга килү юлын каплап торган көчле терәк пункты булган. Немецлар, рус гаскәрләренең үз җирләренә керүләренә ышанмаганга, соңгы чиктә генә шәһәрне ташлап качканнар. Шәһәрдә җан әсәре юк, хәтта эт-мәче кебек хайваннар да күренми. Ара-тирә җимерек йортлар пыскып утыра. Юл читләрендәге канауларда велосипедлар, урын-җирләр, паласлар аунап ята. Шәһәрдән ашык-пошык качып киткән җирле халык ташлап калдырган аларны!

Кайда туктарга? Урнашып эшләрлек уңайлырак почмак сайлыйбыз. Теләгән йортка кер, кем дә юк, ишекләр ачык. Тәрәзә төпләрендәге гөлләр чәчәк атып утыра, стенадагы зур сәгатьләр дә салмак кына йөреп торалар, аш өстәлендә тәлинкәләргә бүленгән азыклар калган. Күрәсең, эшләре бик тә ашыгыч булган!

Үзебезгә җайлы почмак сайлап йөргәндә, өч катлы зур гына парадный ишеге артында бер җан иясенә юлыктык. Ул — тәгәрмәчле арбага утырган авыру бер карчык иде. Бу авыруны үзләре белән алып китәргә уйлап урамга алып чыкканнар, ләкин ишек артында калдырып китеп барганнар...

Бу кызганыч хатынны үз бүлмәсенә урнаштырып китәргә уйладык, ләкин ул безне, без аны аңламыйбыз. Арбасы белән күтәреп, икенче катка менгезәбез, аның ишарәсе белән коридор буйлап барабыз. Бер ишекне күрсәтә — керәбез. Матур гына җиһазландырылган бүлмә. Карчык бүлмәдә үз арбасында йөри, ә күзләрендә яшь. Гитлерчылар безнең илебездә нинди генә вәхшилекләр эшләмәделәр! Шуңа да карамастан, ул кабахәтләр үз халкы арасында рус халкын, рус солдатларын ерткыч җанварлар итеп күрсәтеп килделәр. Шуңа күрә гөнаһсыз бу гарип хатын да рус солдатларыннан шундый ерткычлыкны көткәндер, ләкин кешелекле ярдәмне күргәч, ихтыярсыздан күзләренә яшь килгәндер.

Газета хезмәткәрләре өч катлы бер зур йортка урнашты. Бүлмәләр күп, ашамлыклар да җитәрлек. Ләкин шәһәрдә су юк, электр станциясе дә эшләми иде. Шәм яндырып кына утырабыз. Аның каравы караватларда мамык мендәрләр өелеп тора, эштән бушау белән шул чүмәләләр эченә чумабыз. Германиядә беренче кичне шулай каршыладык.

Фронт инде шактый алга китте, көнбатыштан икенче фронт та кысып килә. Кая керергә белмәгән дошман үлем алдында тыпырчына. Шәһәрне ташлап киткән җирле халык та, кая керергә урын тапмагач, яңадан тәвәккәлләп, шәһәргә кире кайта башлады.

Германиядә немецлар калдырып киткән типографиядә газетабызның беренче санын басабыз. Садри кичә генә алгы сызыктан бик күп хәбәрләр алып кайткан. Бүген Гали чыгып китәргә җыенып йөри. Аның Закир дигән бер батыр татар егетен эзләп табасы бар.

Бөтен фронт буйлап көчле һөҗүм барган көннәр. Хәбәрчеләр алгы сызыклардан кайтып кермиләр. Берсе кайтышка, икенчесе чыгып китә. Менә Венгриянең башкаласы Будапешт та азат ителде. Бер-бер артлы башка шәһәрләр дә азат ителә. Җиңү сәгатьләре якынлаша!

Крайцбургта озак торырга туры килмәде. Ашыгыч кына җыенып, алга, Германиянең үзәгенә таба күченәбез. Юлда төркем-төркем хатын-кызлар, үз кешеләребез очрый, алар — Германиягә көчләп алып кителгән Совет гражданнары. Хәзер үз илебезгә кайтып баралар.

Одер аркылы вакытлыча агач күпер салынган, шуның аша чыгып, юлыбызны дәвам иттерәбез. Юлда тәзек хуторлар очрый, урман читләре тебәнәк чуен киртәләр белән әйләндереп алынган.

«Германияне күрдек, сугыш исен дә бераз иснәдек, инде монда күргәннәрне тизрәк өлкә газетасында яктыртыйк!» дип, Газиз Иделле белән Фатыйма Галиева туган якларыбызга кайтып киттеләр.

— Туган Казаныбызга кайнар сәлам! — дип, аларны озатып калдык.

Беренче Украина фронты гаскәрләре Бреслауны чолгап торалар, урам сугышлары бара. Әнә шул шартларда М. Садри снайпер Газизов дигән бер татар егетен табарга тиеш. Хәбәрче бу егетне пуля яңгыры астында эзләп таба. Ул Садриның үз күзе алдында тагын берничә фашистны теге дөньяга озата.

Атаклы снайпер турында хәбәрләр басылып чыккач, Газизов «Тагын да дәртләнеп киттем әле», дип редакциягә җавап хаты язды.

Одер елгасы кардан-боздан арчылды, туп тавышлары тынып торган арада кырда тургайлар сайрый. Ләкин елгада бертөрле дә хәрәкәт юк, көймәләр, баржалар «Бөек Германия»нең хурлыклы җиңелүен күтәрә алмагандай, борыннарын ярга төртеп, тирән «йокыга» талганнар.

Тагын 150 километр алга күчеп, Заган шәһәренә туктыйбыз. Бу шәһәрдә каты сугышлар булган. Йортлар җимерелгән, урамнарда йөрерлек түгел — таш, кирпеч кисәкләре өелеп ята.

Берлин тирәсендә каты сугышлар бара. Безнең фронт — Беренче Украина фронты гаскәрләре, Беренче Белоруссия фронты белән бергә кушылып, Берлинны чолгап алдылар. Фашистларның соңгы көчләре утлы боҗра эчендә калды, Берлин яна. Безнең хәбәрчеләр көн саен ике-өч тапкыр Берлин тирәсенә барып кайталар.

27 апрель. Торгау районында безнең гаскәрләр союзниклар белән кушылдылар. Гитлер Германиясе соңгы сулышын ала. Йөрәк түзми, Берлин тирәсен йөреп кайтасы килә. Ләкин майор Риза ризалыгын бирми, янәсе, мин ут эчендә күп йөргән кеше, хәзергә калып торыйм. Бу юлы Берлин урамнарын ул айкап кайтсын! Риза, шулай сөйләнә-сөйләнә бил каешын кысып буа да, юлга чыгып китә һәм икенче көнне аны госпитальгә китереп салалар. Ул Берлин урамнарында барган сугышларда яраланган. Казакъ газетасы хәбәрчесе капитан Сугырбиков кулын югалтып кайтты. Канлы көрәш юлларын үткән бу иптәшләребезнең җиңү сәгатьләре якынлашкан көннәрдә генә болай яраланулары безгә бик күңелсез булды. Мин бу хәбәрне ишетеп, госпитальгә килеп чыккач, ак җәймәгә төренеп яткан Риза:

— Менә, Берлинга барам дип талпынган идең. Күрәсеңме, нинди хәлдә кайттым! — дип шаярткан була.

Ярый әле, ярасы ул кадәр куркыныч түгел иде, тиз терелеп чыкты, әмма Сугырбиков иптәшебез гомергә бер кулсыз калды...

9 майга каршы төндә газетабызның чираттагы санын әзерләп утырабыз. Тәрәзәләр томаланган, дошман актык сулышын ала, шулай да сак булырга кирәк, әллә кайларда яшеренеп яткан үләксә козгыннары килеп чыгарга мөмкин бит! Каләмебез җиңү сәгатьләре якынлашуын сизеп тибрәнсә дә, күңел тыныч түгел. Берлин урамнарында каты бәрелешләр дәвам итә, чарлакларга яшеренгән дошман калдыклары, кинәт ут ачып, котырынып алалар, ара-тирә яшерен тыкрыкларда автомат көпшәләре хәрәкәткә килә, дошман үлем алдыннан тыпырчына.

Кинәт көчле атыш башланды! Без, каләмнәребезне ташлап, урамга чыктык. Ишек төбендә безне капитан Зиннәт Фәтхуллин каршылады. Ул редакциядә радио буенча дежур тора икән. Радио дулкыннары гитлерчы Германия гаскәрләренең тулысынча капитуляция ясаулары турында хәбәр китергән. Капитан шул шатлыгын уртаклашу өчен йөгереп кайтып килә икән!

— Сугыш бетте, без җиңдек! — диде ул, безне кочаклап.

Шатлыктан күзгә яшьләр килә. Без бер-беребезне кочып үбешәбез, котлыйбыз. Әле генә күкне яңгыратып үткән атышлар безнең частьларның җиңү салюты булган икән. Төн караңгылыгын ярып, күктә ракеталар оча!

Төн йокылары качты, барлык хәбәрчеләр редакциягә җыелды. Соңгы хәбәрләрне тикшерәбез. Бөек Россияне яулап алу белән хыялланган Гитлер үзе дә дөмеккән, түгелгән кан, күз яшьләре аның башына җиткән!

Йокысыз төн үтә, сызылып таң ата, җиңү таңы килә! Бүгеннән соң күктә дошман самолетлары очмас, туп тавышлары яңгырамас. Инде кояшлы тыныч көннәр илне шатландырыр!

Бүген ике шатлык бергә килде. Җиңү бәйрәме итәбез. Шуның өстенә бүген фронт штабында газета хәбәрчеләренә хөкүмәт бүләкләре тапшырылачак!

Машиналарга төялеп, фронт штабы урнашкан күрше авылга барабыз. Яшел агачлардан яз исе аңкый, гөлләр чәчәккә бөреләнгәннәр. Шуларга карап:

— Агачлар, яфракларыгызны киң җәегез. Ал чәчәкләр, бакчаларга ямь кертеп, тыныч утырыгыз. Хәзер туплар тынды, җирдә дә, күктә дә тынычлык! — диясе килә.

«Ватан намусы өчен» газетасы, башкалар белән бергә, сугышчыларны партиябез кушканча тәрбияләүдә, аларны зур җиңүләргә әзерләүдә зур роль уйнады. Күп меңнәрчә совет солдатлары окопларда, землянкаларда газетабызны кулдан-кулга йөртеп укыдылар. Ул фронт сугышчыларының тирән мәхәббәтен казанды.

Газетабыз үз тирәсенә йөзләрчә актив хәбәрчеләр туплый алды, аларны үстерүдә, тәрбияләүдә төп чараларның берсенә әйләнде. Фронт буйлап канлы көрәш юллары үткәндә, газетабызның төп работникларыннан Р. Ишморат, М. Садри, Г. Хуҗи иптәшләр бергә эшләгән рус һәм Украина язучыларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә иттеләр. Шагыйрь Г. Хуҗиның «Россия», «Яу күрке», «Гражданин, солдат, шагыйрь» кебек матур поэмаларын һәм күп кенә ялкынлы шигырьләрен татар сугышчылары яратып укыдылар. Шагыйрь М. Садри үзенең иң яхшы поэмаларын, дәртле шигырьләрен ут эчендә иҗат итте. Аның Александр Матросов турындагы поэмасы, Хафиз батыр һәм Әнвәр Кәлиевләргә багышланган ялкынлы шигырьләре, башка бик күп хикәя һәм очерклары әдәбият бакчабызга кереп калдылар [1].

Драматург Риза Ишморат та дәһшәтле сугыш елларын чагылдырган әсәрләре өчен төп азыкны нәкъ шул елларда алды дисәк, ялгышмабыз. Зәйни Шәһиморат, Гыйлемдар Рамазанов, Гали Ибраһимов кебек язучылар да нәкъ шул елларда каләмнәрен чарладылар. Бу иптәшләр бер яктан сугышчыларыбызны патриотик рухта тәрбияләүдә зур хезмәт күрсәтсәләр, икенче яктан алар, турыдан-туры фронт белән бәйләнештә булып, үзләренең иҗат эшләрен үстерделәр. Газетабыз ерак тылда калган күренекле язучыларыбызның хикәя һәм шигырьләре белән дә сугышчыларыбызны таныштырып барды.

Кыскасы, башка фронт газеталары белән берлектә, «Ватан намусы өчен» газетасы да алдына куйган бурычны намус белән үтәде.

○ ◇ ○

---

[1] М. Садриның фронт сызыгында иҗат иткән шигырьләре хәзер «Мин Берлинны алдым» дигән исемдә аерым бер җыентык булып басылып ята. (Г. Б.)

# ТӘРӘЗӘГӘ КЕМ АТКАН?..

**Н. Ямалиев,**

юстиция советнигы, Республика прокуратурасының прокурор-криминалисты.

## Йокысыз төн



**К**айттыңмы, әтисе? — дип, Хәнәфине Сәҗидә ачык йөз белән каршы алды. — Хәзер чәй өлгерә. Әнә газеталарыңны караштыра тор.

Хәнәфи эндәшмәде. Бу хәлгә Сәҗидә сагаеп калды: нигә кәефсез кайтты икән? Күрәсең, эшендә берәр уңайсызлык килеп чыккандыр? Әмма Хәнәфинең гадәтен яхшы белгәнгә, хатыны да аны-моны сорашып, ирен борчып тормады.

Хәнәфи чишенеп, тегү машинасы өстеннән беренче туры килгән газетаны алды да диванга ятты. «Уф! Тагын күпме җәфа чигәсе булыр? Күптән куарга кирәк инде аларны»,— йорт хуҗасы күзләрен газетага төгәл, сап-сары түшәмгә төрәде.

— Я, әтисе, чәй эчеп алыйк, булмаса. Телевизорны да кабызып җибәр...

Зур корсаклы самовар түр яктагы сый-хөрмәт белән тулган өстәлгә менеп утырды. Хәнәфи дә теләр-теләмәс кенә өстәл янына килде.

Шул чак капка ачылган тавыш ишетелде.

— Җил ачты, ахры, — дип куйды Хәнәфи. Ул арада өй ишеген шакырга да керештеләр. Сәҗидә өйалдына чыкты.

Ишек артыннан:

— Хәнәфи өйдәме? — дигән тавыш ишетелде.

Керүченең күзләре акайган, авызыннан аракы исе аңкып тора иде.

— Әйдә, Хәйри, берәр чәшкә чәй эчәрсең. Туңгансың да бугай, — Хәнәфи аны өстәл янына чакырды.

— Юк, юк! Рәхмәт, борчылма! Без эчкән инде...— Хәйри хуҗаның тәкъдимен кире какты. Аннары Хәнәфи янынарак килеп, колагына пышылдады:— Йомыш бар иде сиңа, әй. Өйалдына чыгыйк әле...

— Йомышың булса, монда гына әйт, Хәйри, Сәҗидәдән серем юк минем.

— Миңа уңайсыз, понимаешь? Может безгә барырбыз? Ярты да бар... Бригадир булдым дигәч тә авылдашыңа бармыйсың дамы инде?

— Хәзер соң инде,— дип куйды бригадир.

— Юк, соң түгел! Беләм бит мин! Син мине яратмыйсың! Мин шундый яратмаслык, әшәке бәндәме?

Кичке кунак кесәсеннән бер пачка папирос чыгарды:

— Кая, тартыйк, булмаса. Йөрәк янганчы тәмәке янсын... Чыкмыйсың дамы? Бармыйсың дамы?..

Хәйри тәмәкесен суырып беравык сүзсез утырды да урыныннан торды.

— Ярый, дускай, гаеп итмә... Без синең белән очрашырбыз бит әле? — диде ул, тирән мәгънәле итеп. Аннан колакчын бүреген басып киде дә чыгып китте.

— Моның нинди йомышы булды икән? — диде Хәнәфи, үз-үзенә сөйләнгәндәй.

Күкеле сәгать, кичке тугызны белдереп, өйне тутырып тавыш бирде. Авылда инде бер-бер артлы утлар да сүнә башлады. Кәрамовлар йорты да караңгылыкка чумды. Әмма бу төнне аларга йокларга туры килмәде, урын җәеп ятканнар гына иде, яшен яшьнәгәндәй кинәт өй эче яктырып китте. Колак төбендә генә мылтык аткан тавыш яңгырады. Урам як тәрәзә челпәрәмә килеп коелып төште.

— Тәрәзәгә аттылар, ләгънәтләр! — Хәнәфи яткан урыныннан сикереп торды. Урам як тәрәзәгә ташланды. Тәрәзә аша сызгырып кергән җил битенә бәрелде. Өстенә фуфайкасын салып, ул ишеккә таба атылды, аткан кешене куып тотмакчы булды. Әмма каршысына Саҗидә килеп басты:

— Үзеңә атсыннармы тагы?

— Шул Хәйри эше генә бу, имансыз!..— дип, ачы сүгенеп җибәрде Хәнәфи...

## Беренче дәлилләр

Иртән, таң беленә башлау белән үк, Кәрамовлар йорты алдына район үзәгеннән «газик» машинасы килеп туктады һәм аның ике ишеге дә берьюлы ачылып китте. Машинадан дүрт кеше чыкты. Кызу-кызу атлап, алар бәләкәй капкадан эчкә уздылар.

Хәнәфи аларны өйалдына чыгып каршы алды.

— Сөйләгез әле, ничек булды соң бу хәл? — дип сорады район прокуратурасы тикшерүчесе, икенче класс юристы Рафаил Сәгъдиев. Урта гына буйлы, йомры битле, кара чырайлы, утыз яшен күптән түгел генә узган бу тикшерүче белән тагын милиция бүлеге начальнигы, милиция майоры, ир урталарындагы Иван Касьянович Андреев, җинаятьчеләрне эзләү бүлегенең өлкән оператив уполномоченные, милиция лейтенанты Сәфәр Шәрипов, милиция шоферы Юра Быстров килгән иде.

Урам як тәрәзә мендәрләр белән каплап куелган. «Менә кая атканнар икән»,— дип уйладылар килгән кешеләр.

Хәнәфи төнге вакыйганы башыннан ахырына кадәр сөйләп бирде. Аннан үзләре яткан кровать буена килеп, стенага эленгән чуклы келәмне күтәреп алды да:

— Күрәсезме, ядрәләр стенага ничек кергәннәр,— дип өстәде.— Дуамал гына атмаганнар...

Әйе, мәкерле бәндә тагын берничә сантиметрга гына түбәнрәк атса, бу хәлнең фаҗига белән беткән булуы һәркемгә ачык иде.

— Сәфәр, кая, ике понятой алып керегез әле. Хәзер җинаять урынын карый башлыйбыз.— Сәгъдиев фотоаппараты белән берничә рәсем төшереп алды.

Чакырылган кешеләр озак көттермәделәр.

Инде көн тәмам яктырган иде. Тикшерүчеләр җыелышып урамга чыктылар. Аларны бирегә дисталәгән күзләр каршы алды. Бу тәшвишле хәбәр яшен тизлеге белән авылга таралган иде. Олылар да, балалар да килгәннәр. Башларына шәл бөркәнгән берничә хатын-кыз да күренә.

— Табарсың хәзер! — дип куйды Шәйхелислам карт.

— Атучыны күрүче кеше юктыр бит? — дип сорады урамда җыелган кешеләрдән майор.

— Хәйрине кичен мылтык күтәреп йөргән, диләр! — дип кычкырды кемдер. Андреев бу кешене читкә чакырып, аның белән нәрсәдер сөйләшеп алды.

Тәрәзә турысында пыяла ватыклары ята иде.

— Аяк эзләре дә күренмиме? — дип сорады Шәрипов. Әмма бозланып каткан җир өстендә кеше эзләрен табу турында уйлыйсы да юк иде. Шулай да Сәгъдиев ватык пыялалар арасыннан йомарланып беткән бер кәгазь кисәге табып алды.

— Күрәсезме? — диде тикшерүче, җанланып.— Патронга дары тутырганда, өстенә төеп куелган кәгазь түгелме соң бу?

Майор белән лейтенант та бу кәгазь кисәген зур игътибар белән карадылар.

— Точно шул, факт,— дип куйды майор Андреев,— дәфтәр бите бугай.

Табылган әйберне Сәгъдиев, бик сак кына конвертка салып, портфеленә тыгып куйды. Нәрсә турында сөйләр икән бу кәгазь кисәге?

Сәгъдиев ватык тәрәзәгә башын тыгып карады. Аннары тагын берничә рәсем төшереп алды.

— Карагыз әле, Иван Касьянович,— диде ул, майорга карап,— бу урыннан өйнең теләсә кайсы почмагына атып була икән! Ә бит теге бәндә нәкъ менә кровать тирәсенә аткан. Очраклы хәлме?

Майор да аяк башларына басып тәрәзәгә башын тыкты.

— Факт, — диде ул, гадәтенчә, — дөрес сөйлисез.

Өй эчендә тагын нәрсәләр бар икән? Алар өй эченә керделәр. Идәнгә пыяла ватыклары чәчелгән иде.

— Әһә, тагын бер кәгазь кисәге! — дип кычкырып җибәрде тикшерүче. Әйтерсең, атучы бу кәгазьгә үз исемен язып калдырган! Күрәсең, эш өчен шушы кош теле шикелле кәгазь кисәге дә мөһим нәрсәдер инде.

— Менә нәрсә, Кәрәмов,— Сәгъдиев Хәнәфине үз янына чакырып алды.— Стенадагы ядрәләрне җыеп алырга кирәк бит. Ризамы?

— Кирәк икән, аласыз. Каршылык юк.

— Чүкеч белән өтерге бармы икән сезнең?

— Ник булмаска. Хәзер китерәм.

Тикшерүчеләр зур саклык белән бу ядрәләрне казып алдылар.

— Самоделка,— диде майор, русчалап.— Факт.

Казып алынган 11 ядрәнең һәркайсын аерым кәгазьгә төрделәр.

— Хәзер кулларыгызны куегыз,— диде Сәгъдиев, җинаять урынын карау протоколын язып бетергәч.

— Шулай да үзегез кемнән шикләнәсез? — дип сорады майор үзләрен озата чыккан Хәнәфидән...

## Барысының да шиге Хәйридә

Тикшерүчеләр колхоз идарәсенә килделәр. Биредә алар чәчләренә чал кергән, тулы гына гәүдәле, өстенә саргылт костюм кигән кешене — артель башлыгы Әмирхан аганы очраттылар. Ул район кешеләренә идарәнең бер бүлмәсен бирде.

— Бу авылда туганнан бирле торам,— дип аягүрә генә сөйләп китте ул, — ләкин мондый хәлнең әле булганы юк иде. Дөрес, колхозны аякка бастырган елларны кулак иярченнәре почмаклардан аткалый иделәр. Әмма ләкин хәзер ул заманнар түгел бит!..

Аннан ул тикшерүчеләр янынарак килеп, башка кеше ишетмәсен дигәндәй, әкренрәк тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Сез теге Хәйри Усманов белән ныклабрак кызыксыныгыз әле. Бик шикле күренә ул миңа. Эчкече бер бәндә шунда.

— Ни өчен, Әмирхан ага? — диде Сәгъдиев.

— Менә ни өчен...— Ул кичәге идарә утырышы турында сөйләп китте.

Анда әлеге Усманов Хәйри турында сөйләшү булган икән. Бу мәсьәләне бригадир Хәнәфи күтәреп чыккан. Ул болай дигән: «Балык тоту планы көннән-көн кими, ә алда зур бәйрәм. Эчкече бәндәләр белән мин эшли алмыйм. Менә өченчекөн дә эшкә чыкмадылар. Сәбәп? Шул инде, үзегез беләсез, баш төзәткәннәр! Хәйри Усманов белән Хәсән Әкбәровны минем бригададан чыгаруыгызны сорыйм. Я мин — я алар...»

— Әмма,— диде Әмирхан ага,— без аларны бригададан чыгармадык. Икенче идарә утырышына үзләрен чакырып тикшерергә булдык. Бу нәрсә Хәнәфигә ошап җитмәде. Шуңа күрә аның кәефе кырылды. «Мин алар белән барыбер эшләмим»,— дип, идарәдән ризасызлык белән чыгып китте. Бу сөйләшү, минемчә, Усмановка ба-

рып житкән булырга тиеш. Ә исерек башка күп кирәкмени? Торган да тәрәзәгә аткандыр...

— Без моны ныклап тикшерербез,— диде Сәгъдиев.

— Ярый алайса, вакытыгызны алмыйм. Эшегездә уңышлыклар телим,— дип, колхоз председателе чыгып китте.

«Ни өчен караңгы төндә Кәрамовлар тәрәзәсенә атканнар?» «Кем ул җинаятьче?» «Ничек кенә аның эзенә төшәргә?» Мондый билгесез сорауларның исәп-хисабы юк иде. Чыннан да, хуҗалыклар саны дүрт йөздән артып киткән бу зур авылда җинаятьчене ничек кенә аерып алырга мөмкин соң?

— Авылда барлык мылтыклы кешеләрне тикшереп чыкмый булмас,— диде лейтенант Шәрипов.

— Факт,— дип, аның белән ризалашты майор Андреев.— Аннан, мин әйтәм, каравылчыларны да истән чыгармаска кирәк.

— Мөгаен, атучы шушы авыл кешеләре арасыннан булырга тиеш,— диде Сәгъдиев, яза торган кәгазеннән күзен алмый гына.— Кыскасы, эшне башлап җибәрик. Мин хәзер Кәрамовтан, аннан Усмановтан сорау алам. Ә сез авылдагы барлык мылтыклы кешеләрне тикшереп чыгыгыз. Әлеге кичне алар кайда булганнар?

Аннан, телефон трубкасын алып:

— Я, сеңелкәш, тиз генә мине прокурор белән тоташтырыгыз әле,— диде.

Тикшерүче телефоннан берничә сүз белән генә җинаять турында сөйләп бирде. «Җинаятьчене тизрәк фаш итәргә тырышыгыз»,— диде аңа прокурор.

— Әлбәттә,— диде Сәгъдиев.

Әнә күзләре кызылланып, утырып калган Хәнәфи дә килеп житте. Төнге вакыйга әле аңа һаман тынычлык бирми икән. Ул керү белән үк, ашыгып сөйләргә кереште:

— Тикшереп тә торасы юк, иптәш Сәгъдиев. Хәйри эше генә. Тотарга да төрмәгә ябарга үзен. Бераз кыссагыз, барысын да сөйләр...

— Гаепле кешегә урын табарбыз. Минә сез үзегезнең эшегез, сезгә ачулы кешеләр турында сөйләгез әле.

— Мин сезгә шуны әйтә алам.— Хәнәфи Сәгъдиев янына якынрак килде.— Бездә бригадирның эше бик авыр. Кезләрен, кыш көннәрендә бигрәк тә яман...

Әйе, диңгез шикелле җәелеп яткан Кама елгасының аръягына урнашкан «Таң» колхозында ел буенча диярлек тынгылык юк. Басу эшләре бетү белән, артель члennары балык тотарга керешәләр. Салкын дими, буран дими, боз өстендә балык тотып туңып йөрү җиңел эш түгел, билгеле. Шуңа күрә дә үз ирекләре белән бу эшкә тотынучылар аз. Аның әле шундый кыен ягы да бар: бераз балык кердеме, балыкчыларның кайберләре үз кесәләрен калынайту ягын карыйлар. Әйтсәң, кешегә ошамыйсың. Бригадир бит кешене аркасыннан гына сөеп эш йөртә алмый. Каты сүзләр әйткән чаклар да, ризасызлыклар да булган.

— Ачулы кешеләр кемнәр иде дисезме? Берничә кешене әйтә алам. Дамир Әхмәтов, Сергей Конков, Гата Мифтахов, Сәлим Хәсәнов.

— Куршеләрегезнең берсеннән дә шикланмисезме?

— Юк, иптәш Сәгъдиев. Мин аларны яхшы беләм. Дөрес, Илшат кына бераз эчкәли. Әмма аның миңа үче булырга тиеш түгел дип уйлыйм.

Кыскасы, Сәгъдиев Кәрамовларны энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыкты. Шикле кешеләрне һәм вакыйгаларны барысын да протоколга язып алды.

Сөйләүләр бетте, әмма Хәнәфинең ризасызлыгы бетмәде. Ул болай уйлаган иде: районнан тикшерүчеләр килерләр дә Хәйрине алып китәрләр. Аннан ул үз гаебен икърар итәр дә, шуның белән эш бетәр. Хәзер инде аның фикере үзгәрде: эшне болай җентекләп тикшерә башлагач, аның озакка сузылачагы ачык...

## Тикшерүче әле шикләнә

Хәнәфине чыгарып җибәргәч, Сәгъдиев ике кулы белән башын тотып тагын уйга чумды. Бигрәк тә җинаять урынында табылган ике кәгазь тынычлык бирмәде. Җинаятьченең караңгы төндә тәрәзәгә атканын күрүче кеше булыр дип уйлыйсы да юк. Ә менә бу кәгазь кисәкләренең бары тик атучыныкы булырга тиешлеге шиксез.

Шуңа күрә дә: «Җинаять җебенең очы шул кәгазьләрдә булырга тиеш», дип уйлады тикшерүче. Ул аларны саклык белән генә портфеленнән чыгарды. Ялтыравыклы пенцет белән өстәлгә җәеп куйды. «Чү! Бу бит чыннан да дәфтәр тышы! Тукта, тукта! Монда бит укучының исем-фамилиясе дә булырга тиеш!» Портфеленнән кара кысалы лупасын алып, кәгазь кисәкләре өстенә иелде. Лупа астында хәрефләр ат башы шикелле күренделәр. Ул: «...иля... ова» дип укып чыкты: Ура! Бу бит — җинаятьченең эзе диган сүз! Дөрес, калган хәрефләр танылмый, корым каплаган. Шулай да аны эксперт укый ала ич!

Икенче кәгазь кисәге химия дәфтәреннән ертып алынган ярты бит булып чыкты. Ул төрле химик формулалар белән тулган иде. Әлбәттә, шушы авылда укучы кызның дәфтәре булырга тиеш. «Дәфтәр иясе табылса, җинаятьчегә дә бер-ике генә адым кала»,— дип фикер йөртте тикшерүче.

Әмма, аның уйларын бүлеп, бүлмә ишеге ачылды. Ишектә колакчын бүреген батырып кигән, битен сакал-мыек баскан кеше күренде.

— Шәрипов җибәрде. Сез чакырдыгызмы? — дип сорады ул, карлыккан тавыш белән.

— Усмановмы? Утырыгыз. Мин көтәм сезне.

Сәгъдиев керүченең башыннан аягына кадәр күз йөртеп чыкты. Бөтен гәүдәсеннән сүлпәнлек бәленеп тора иде бу кешенең. Шулай да ул тышкы яктан беркемнән дә аерылып тормый. Җинаятьчеләрнең барысы да әнә шулай инде. Фаш ителгәнче, рәшәткә артына кертелгәнче, безнең арада яши бирә. Без йөргән юллардан йөри, бер үк кояш астында яши, без сулаган һаваны сулый. Кыскасы, намуслы совет халкы өчен тудырылган бөтен игелек белән рәхәтләнеп файдалана. Шуңа күрә аны эзләп табу да җиңел түгел. Бусы бер. Ә икенче яктан, ул чынлыкны, үзе башкарган мәкерле эшне тикшерү органнарыннан яшерер өчен бөтен көче белән тырыша. Ләкин бернәрсәне аңлап җиткерә алмый: җинаятенең барлык эзләрен дә берничек тә яшереп кала алмый. Ул эзләрне тикшерүчеләр барыбер табачаклар. Тикшерүченең һәрбер адымы, кешеләр белән очрашып сөйләшүләре, телсез шаһитләрне җыйнавы — шушы күренми калган эзләрне табуга юнәлдерелгән дә. Менә хәзер тыңлыйк: Хәйри нәрсә сөйләр икән? Ничек үзен аклар икән?

— Кичә сез кайда булдыгыз? — дип сорады аңардан тикшерүче, коры гына.

Хәйри җилкәсен сикертеп куйды:

— Шул инде безнең. Балык тоттык. План куабыз...

Хәйринең дулкынлануы йөзенә чыкты. Кичә нык исерек булуы аны борчый иде. Эш беткәч, туп-туры алар кибеткә киткәннәр. Өч кешегә бер литр салганнар. Аның белән Дамир Әхмәтов, Рәшит Хафизов булган. Аз булган, күрәсең. Тагын яртыны бушатканнар. Эчкән баш белән Кәрамовларга кереп чыккан. Аның артык бүрәнәләре бар икән. Сатмасмы дип уйлаган. «Хатын-кыз эшкә тыгылганны яратмыйм»,— дип, бу турыда Ханәфинең хатыны алдында әйтергә теләмәгән...

Усманов аучы булып чыкты. Мылтыгы законлаштырылган.

— Патроннарны каян аласыз? — дип сорады тикшерүче.

— Үзем корам. Ядрәләрен кургаштан кисәм. Пыжын кәгазьдән ясыйм.

— Ә дәфтәрләрдән ясаганыгыз бармы?

— Булгалый. Кызыммы? 10 класста укый. Гүзилә исемле.

«Гүзилә!» — Яшен тизлеге белән уйлап алды Сәгъдиев. Менә бит ул дәфтәр тышындагы «...илә». Фамилиясе дә туры килә бит! «...ова» «Усманова»ны аңлата түгелме соң? Тикшерү дөрес юлдан бара бугай. Җинаятьче әллә кая китә алмас!

— Кичен сезне мылтык белән күргәннәр. Нишләп исерек килеш алай йөрдегез?

Хәйри чыраенда ясалма көлү билгеләре күренде.

— Сизәм бит мин, иптәш тикшерүче. Нигә мин Ханәфи тәрәзәсенә атыйм? Башка ат типмәгән ләбаса! Мылтык белән йөрүем дөрес. Мин аны Ханәфидән чыккач, тавык Шакирыннан алып кайттым. Әнә Җантимеровның үзеннән сорагыз.

— Нишләп мылтыгыгызны кешегә бирәсез? Ул бит законга сыймый. Хәвеф-хәтәр була калса, үзегез җавап бирәчәксез бит.

— Сорагач бирдем инде. Башкача бирмәм.

— Аннан сезне Әмирхан ага да эштән баш тарта, эчүчелек белән шөгыльләнә дип сөйләде. Дөресме?

— Булгалады инде.

— Шуның өчен сезне Кәрамов та бригадасыннан чыгарырга йөргән? Бу хәл сезгә билгелеме?

— Сөйләгәннәр иде. Белмим, нигә мине Хәнәфи яратмыйдыр?

Ул үзендә булган мылтык кирәк-яракларын китереп бирергә риза булды.

Сорау бетәр алдыннан гына тирләп-пешеп Шәрипов килеп керде.

— Бик яхшы булды әле,— дип каршы алды аны Сәгъдиев.— Менә нәрсә, Сәфәр. Хәзер сез Усманов белән барып, аның мылтык кирәк-яракларын, кызының дәфтәрләрен алып килегезче. Кызын һәм химия укытучысын бирегә җибәрегез. Шакир Җантимеров та килсен. Тракторчы икән ул. Өйдә диләр аны.

Җантимеров белән очрашуны тикшерүче түземсезлек белән көтә иде. Бу сөйләшү, бәлки, эшкә ачыклык кертер дип уйлый иде ул. Әмма бу очрашу эш өчен, дөресрәге, Хәйрине фаш итәрлек нәтиҗә бирмәде. Дөрес, Хәйри исерек булган. Килгән. Алган. Ул арада сәгать тугызлар да булган, ә тәрәзәгә сәгать уннарда атканнар. Бер сәгать чамасы салкын урамда нишләп йөрер икән Хәйри.

Аннан Усманов кызы Гүзилә белән химия укытучысы килеп керде. Бу чандыр гына кыздан:

— Кара әле, Гүзилә, кем дәфтәренә охшаган бу? — дип, тикшерүче аңа теге ике кәгазь кисәген күрсәтте.

— Белмим шул, абый.

— Ә синең дәфтәргә охшамаганмы?

— Әйтә алмыйм шул.

Укытучы Луиза Харисовна да берни әйтә алмады. Бары тик шул ачыкланды: бу формулалар 10 класс программасыннан икән.

Алар чыгып киткәч, күп тә үтмәде, мылтык күтәреп Шәрипов кайтып керде.

— Алып кайттым менә. Мөгаен, безнең версия дөрестер. Җинаять ачылды дисәк тә ялгыш булмас,— лейтенантның шатлыгы эченә сыймый иде.— Минемчә, Хәйринең тәрәзәгә атуы мылтыкны алып кайтканда булырга тиеш. Башы исерек, аны-моны уйламаган. Бах!..

Уналты калибрлы мылтыкны кулына алып, Сәгъдиев урталай бөкте. Көпшәсен лампочкага төбәп канал эченә карый башлады.

— Майлаганнар да икән,— дип куйды.

— Исегез китмәсен, Рафаил дускай. Бу озын төнне аны ун мәртәбә чистартып, ун мәртәбә майлап куярга була.

— Кая, Гүзиләнең дәфтәрләрен карыйк әле.

Тикшерүчеләр теге ике кәгазь кисәгендәге язулар белән Гүзиләнең дәфтәрләрен чагыштырып карадылар. Охшый да, охшамый да шикелле иде.

— Аңар карап торып булмый,— диде Шәрипов, бер дә исе китмичә.

Беравык тын тордылар.

— Я, мин әйтәм, Усмановны хәзер төрмәгә озатсак та була инде, — дип, кабат үзенең фикерен белдерде Шәрипов.

— Ә дәлилләр? Нинди дәлилләр бар сездә?

— Бездә алар бер йөк. Менә үзегез уйлап карагыз. Усмановның мылтыгы бармы? Бар. Кичен исерек килеш мылтык күтәреп Кәрамовлар яныннан үткәнме? Үткән. Аның алдыннан гына аларга кереп ызгышып чыгып киткәнме?

— Әйтик, киткән дип исәплик.

— Ә сез тагын Усмановның үзе ясаган ядрәләрен кая куясыз? Пыжын да бит ул дәфтәр битеннән ясаган. Кызының исем-фамилиясе дә туры килә бит! Гүз-илә Усман-ова. Сезгә тагын нәрсә кирәк? Тик аны җинаять урынында тотып алучы шаһит кенә юк. Үзегез беләсез, мондый хәл еш булмый бездә.

— Сез, Сәфәр, бөек рус язучысы Достоевскийның әйткән сүзләрен дә онытмагыз. Хәтерлисезме, ул нәрсә дигән? Йөз куяннан бер ат оештырып булмаган кебек, берберсенә туры килми торган йөзләгән шикләнүләрдән бер суд дәлиле ясап булмый, дигән. Ә менә бөек пролетар язучысы, зур гуманист Горькийны алыйк. Ул нәрсә дигән әле?

— Ун шикләнүнең тугызы ялгыш була,— дигән.

— Мин дә бит Усмановның гаебе юк дип әйтә алмыйм. Миңа да шикле күренә

ул. Дөрес, аны гаепләрле: кайбер дәлилләр дә бар бездә. Ләкин алар очраклы булырга мөмкин. Бу эшкә бәйләнмәгән булулары мөмкин. Аны сак астына алу, минемчә, иртәрәк. Әле аның кызы түгел, без дә ике язманы чагыштыра алмадык. Безнең өчен эшнең иң мөһиме — мылтыкка, кургашларга һәм дәфтәрләргә фән күзлегеннән карау, суд экспертизасы үткәрү.

— Аларны бик тиз генә эшләп булмый. Ә безгә авыл халкы нәрсә дияр? Булдыксызлар, кулларыннан эш килми дисеннәрме?

— Шулай да ашыгырга ярамый. Ашыккан ашка пешкән, диләр. Эшче, мастер, инженер үз эшендә ялгышып, брак әйберләр әзерләргә мөмкин. Аны соңыннан барыбер төзәтеп була. Ә менә безнең эштә бернинди дә ялгышу, брак булырга тиеш түгел. Гаепсез кешене син төрмәгә утыртып кара әле. Әйтик, соңыннан аның гаебе расланмады, ди, гафу үтенеп, аны сак астыннан азат иттек, ди. Әмма аның эчке кичерешләрен, газапланунын, дөреслеккә ышануын югалтуын берничек тә яңадан кайтарып булмый. Тән җәрәхәте кешедә төзәлә, ә күңел ярасын берничек тә дәвалап булмый. Мондый кеше безне, ягъни тикшерүчеләрне генә түгел, безнең законны да гаепле санаячак...

Бик дөрес, дәүләт тикшерүчеләр кулына бик үткен кылыч бирә. Аны алар кирәк урында гына, бик белеп кенә кулланырга тиеш. Кирәк урында ул бик җәһәт кисәргә тиеш. Ә менә кешенең язмышын хәл иткәндә, барыннан да бигрәк намус, җаваплылык тойгысы, объектив булу кирәк.

Сәгъдиев беравык ян тәрәзәгә карап уйланып торды, аннары өстәл янына килеп, сүзен дәвам итте:

— Безгә бик сак, һәрбер дәлилгә нык уйлап бәя бирергә, һәрнәрсәнең «уңай» һәм тискәре якларын төгәл үлчәргә кирәк. Шуннан соң гына җаваплы карарга килергә мөмкин. Ә бу эш буенча без барлык версияләрне тикшердекме соң әле? Менә, әйтик, каравылчылар турында нәрсә билгеле? Аннары майор нәрсә алып кайтыр?

— Каравылчыларны мин тикшердем инде. Аларда шик юк. Ләкин бит авыл халкы телендә һаман бер сүз: «Хәйри эше генә бу»,— диләр.

Сәгъдиев тагын тәрәзәгә күз салды.

— Әнә, майор кайтып та килә,— диде аннан.

— Менә мин мылтыклы кешеләрне алып кайттым,— диде Андреев, бүлмәгә керү белән.

Аның белән килгән кешеләргә коридорда көтеп торырга куштылар.

Сәгъдиев ачыклаган бөтен нәрсәләрне, үзенең шикләнүләрен майорга сөйләп бирде:

— Я, Иван Касьянович, Хәйринең язмышын ничек хәл итәбез? — дип сорады аннары.

— Ә экспертиза нәтиҗәсе бармы соң әле? Иң мөһиме хәзер шул. Аннан инде Усманов белән аяк терәп сөйләшергә була. Факт. Иртәгә үк мин Казанга кеше җибәрәм. Материалларыгызны әзерләп куегыз.

— Мин дә шул фикердә торам,— диде аның сүзен раслап Сәгъдиев.— Аннан беләсезме? Кичә бит клубта кино булган. «Стамбул казначее». Мин әйтәм, шул кинодан кайтучылар эше түгелме дим. Безгә моның белән дә кызыксынырга кирәк...

Тикшерүчеләрнең эшләре озакка сузылды. Алар идарәдән чыкканда, авыл тирән йокыга чумган иде инде. Тик Кама буеннан ачы җил исә, дулкыннарның чайкалуы әллә кайларга ишетелеп тора иде...

## Мылтык печәнлектән табылды

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Тикшерү эше бер генә көн дә тукталып тормады. Инде авылда тикшерелмәгән шикле кеше калмады кебек иде.

Сәгъдиев колхоз радиочелтәре аша «Таң» колхозчыларына мөрәҗәгать белән дә чыгып карады.

— Кайбер кешеләрдә,— диде ул,— учетка, регистрациягә кермәгән ау һәм вак калибрлы мылтыклар булуы беленде. Без мондый мылтыкларны милициягә китереп регистрациягә кертүегезне, я булмаса, бөтенләй тапшыруыгызны үтенәбез.

Регистрациягә кермәгән мылтык ияләре закон нигезендә штрафка тартылачак. Моны һәркем яхшы белергә тиеш...

Шушы чыгыштан соң, өч кеше милициягә килеп:

— Бу тимер кисәкләрен алыгызчы,— дип, иске-москы мылтыкларын китереп тапшырдылар.

Бу мөрәҗәгать бөтен район халкына да җиткерелде. Дисталәгән мылтык җыелды. «Корылмаган мылтык та елга бер мәртәбә үзеннән-үзе ата»,— дип халык телендә юкка гына әйтелми бит. Җинаять эшләренә анализ ясау нәкъ шуны күрсәтә. Иң зур җинаять — кеше үтерү җинаятенең дүрттән бер өлеше шушы мылтыкка бәйләнешле була. Менә ни өчен ау мылтыгы да аучылар җәмгыятендә член булган кешеләргә генә сатыла. Һәр мылтык милициядә регистрациядә тора. Мылтыкны рөхсәтсез саклау үзе генә дә хәзер җинаять булып санала.

Сәгъдиев бүген, прокуратурага иртән үк килеп, эшкә керešте. Күп тә үтмәде, секретарь Әлфия:

— Сезгә Казаннан пакет,— диде һәм аңа бер конверт тапшырды. Тикшерүче аны тиз генә ертып, эчендәге кәгазьләрнең соңгы битләрендәге нәтиҗәне укып чыкты.

— Менә сиңа шикле Усманов! — дип кычкырып җибәрде ул, үзе дә сизмәстән, һәм прокурор бүлмәсенә ашыкты.

— Вәли Саматович, менә карагыз әле. Безнең беренче версия ялгыш булып чыкты бит!

Тикшерүче белгеч нәтиҗәсен прокурорга сузды.

— Безгә әле җиде тапкыр үлчәп кисү генә дә әз. Ун мәртәбә үлчәп бер тапкыр киссәк тә таманга килә...

— Мин үзем дә шулай уйлаган идем. Сездән санкция дә сорамадым бит,— диде тикшерүче, акланып.

— Димәк,— диде прокурор,— Кәрамовлар йортыннан алынган ядрәләрнең химик составы Усмановтан алынган кургаш кисәкләренең химик составына туры килми. Аннан соң пыж өчен кулланган дәфтәр битләре дә аның кызыныкы булып чыкмаган.

— Ә инде дәфтәр битләрендә, эксперт күрсәткәнчә,— дип Сәгъдиев сүзнең җебен үзенә алды.— «Гүзилә Усманова» түгел, «Наилә Хәсәнова» дип язылган икән.

— Димәк,— диде тагын прокурор,— җинаятькә укучы Наилә Хәсәнованың катнашы булмаса да, аның белән бергә торучы кешенең, әлбәттә, катнашы булырга тиеш. Кем ул? Сез аны таба аласызмы?

— Тагын «Таң» колхозына барырга туры килә...

Үз бүлмәсенә чыгу белән, Сәгъдиев телефонга ябышты:

— Миңа Шәриповны. Милициядән,— диде ул трубкага.— Сафәрме? Яңалык бар, малай! Казаннан заключение килде. Җыенып кил. «Таң»га чыгабыз.

Күп тә үтмәде, прокуратура алдына ишекләрендәге кызыл тасмага «Милиция» дип язылган «газик» килеп туктады.

Бүлмә ишеген ачу белән, Шәрипов:

— Кая, нәрсә язганнар? — дип, тикшерүче каршына килеп басты. Ашыга-ашыга экспертиза нәтиҗәсен укып чыкты. Аннан күңеле төшеп:

— Әйе, дускай, бу юлы синеңчә килеп чыкты шул...

Җыену озак булмады.

— Сез,— диде Сәгъдиев, лейтенантка мөрәҗәгать итеп,— бу Хәсәнова Наиләнең туганнарын беләсезме?

— Беләм. Наилә үзе идарәдә. Хисапчы. Абыйсы балыкчы. Энкәче бер бәндә. Сәмит исемле. Кәрамов бригадасында.

— Ә-ә-ә! Хәтерлим әлайса хәзер. Кәрамов та аның турында сөйләп утырган иде. Заман түе көнне ул Хәнәфигә бәйләнгән булган.

— Дөрес. Шул вакыт инде Хәсәновны унбиш тәүлеккә утыртып куйдылар...

Район кешеләре тагын идарәгә килеп төштеләр. Беренче булып Наилә белән очраштылар. Буйга җиткән, кара кашлы матур кыз иде ул.

— Әйе, моннан биш ел элек урта мәктәпне бетердем,— дип тартынып кына сөйләп китте Наилә.— Аннан Чистайда бухгалтерлар курсында укыдым. Кайда эшләгәнемне үзегез дә беләсез инде.

Н. ЯМАЛИЕВ ◆ ТӘРӘЗӘГӘ КЕМ АТКАН ◆

— Ярый,— диде Сәгъдиев, протоколның анкета өлешен тутыргач.— Абыегызның мылтыгы бармы?

— Бар иде. Хәзер генә күргәнем юк.

— Сәмит ядрәләрне нәрсәдән ясый?

— Кургаштан.

— Ә пыж өчен нинди кәгазь куллана?

— Иске китапларны.

— Ә сезнең иске дәфтәрләрне кулланганы булдымы?

— Хәтеремдә бар. Бервакыт ул миннән: «Кая, иске дәфтәрләреңне бир әле»,— дип сорап алган иде. Чормадан алып төшеп бирдем. Кай вакыт дисезме? Җәй көне.

— 25 октябрь көнне сез кайда булдыгыз?

Наилә уйга калды.

— Әнә теге «Стамбул казначее» киносы булган кичне?

Ул көнне аның җиңгәсе өйдә булмаган. Наилә балалар белән өйдә калган. Кичен дус кызы белән кинога барырга булганнар. Абыйсы сәгать сигезләрдә генә кайткан. Эчкән булган. Наилә, аны өстеннән биклəп, кинога киткән.

— Бүтәнчә өйдән чыгып буламы соң?

— Лапас ягыннан була. Анда да ишек бар безнең.

— Соңгы сорау: сезнең дәфтәр битләреннән ясалган пыж кисәге ничек Кәрамовлар тәрәзәсе төбенә килеп төшкән?

Наилә инде җинаять турында яхшы белә иде.

— Белмим шул. Бәлкем абый әйтер? — дип, сүзен бетерде ул.

Тикшерүчеләр Хәсәновлар йортына юнәлделәр.

Ят кешеләр килеп кергәч, Сәмитнең хатыны Җәмилә тәмам гаҗәпкә калды.

— Әллә, ходаем, безнең Сәмит берәр нәрсә эшләп ташлаганмы? — дип өзгәләнә башлады.

— Сез Сәмитнең мылтык кора торган әйберләрен генә бирегез,— диде аңа Сәгъдиев.

Җәмилә өйалдыннан әйләнеп керде дә:

— Кая куйгандыр, таба алмадым бит. Үзегез эзләп карагыз инде.

Хуҗалыкта карамаган урын калмады. Биш корылган, дүрт буш патрон, кургаш кисәкләре генә табылды. Тагын бер иске кайчы килеп чыкты.

Печәнлекне актарырга керештеләр.

— Менә кайда ул «җүләр!» — дип кычкырып җибәрде лейтенант, сәнәгенә тәртелгән мылтыкны актарып алгач.— Гаепсез кеше болай мылтыгын яшереп куймас иде. Мөгаен, җинаятьнең очы шушындадыр.

Алар тиз генә эш урыныннан Сәмитнең үзен чакырттылар. Утыз-утыз биш яшьләрдәге бу кеше, бүлмәгә керү белән, бүреген урындыкка ташлады. Кара чәчләре тырпаеп калдылар.

— Сезнең мылтык кайда әле? — дип, тикшерүче сынаулы карашын Хәсәновка төбәде.

— Саттым мин аны.

— Кемгә?

— Бер кешегә шунда. Базарда. Чистайга барган идем...

— Бир әле, лейтенант, теге без печәнлектән эзләп тапкан мылтыкны,— диде Сәгъдиев. Мылтыкны кулына алып, Сәмиткә күрсәтте:

— Кем мылтыгы бу?

Сәмит тәмам телсез калды. Маңгаена борчак-борчак тир бәреп чыкты.

— Я, кем мылтыгы бу?

Сәмит тун төймәләрен ычкындырып җибәрде.

— Гафу итегез,— диде ул, авыр сулап.— Радиодан сөйләгәнне ишеткәч, мылтыкны бирәсем килмәде. Шуңа күрә яшереп куйдым.

— Ник?

— Мин аучылар җәмгыятендә тормыйм. Мылтыкка таныклыгым да юк.

Патроннарга ядрәләрне ул да кургаш кисәгеннән үзе ясый икән. Пыж урынына сеңелесенең иске дәфтәрләреннән файдалануы да расланды. «Тимер дәлилләр», диләр мондыйларны юристлар.

— Дөресен генә әйтегез әле, нигә сез Кәрамовлар тәрәзәсенә аттыгыз? — диде Шәрипова, һич көтмәгәндә.

Сәмит, ялан аяк кызу табага баскан кеше кебек, бөтергәләнеп куйды.

— Нәрсә, сез мине акылдан шашкан дип уйлыйсызмы?

— Нигә,— диде Сәгъдиев,— әллә сез тәрәзәгә акылсыз кеше аткан дисезме?

— Димим дә.

— Шулай булгач! Кем соң тәрәзәгә атучы?

— Каян белим мин аны?

— Ярый алайса. Ул вакытта сез ясаган пыж кисәген ничек соң Кәрамовлар тәрәзәсенә атканнар?

— Ышанмыйм мин бу сүзгә. Бу хата булырга тиеш.

— Ышанмыйсызмы? Менә белгеч нәтиҗәсен укып карагыз.

Сәмит тикшерүче биргән кәгазьне ашыкмый гына кат-кат укып чыкты. Аннан калтырана-калтырана:

— Аңламыйм мин! Кем атар икән минем патроннан?

— Без дә аңламыйбыз шул! Бәлкем, сезгә инде дөресен генә сөйләргә дә вакыт җиткәндер.

Бүлмәдә тагын авыр тынлык урнашты.

— Тәрәзәгә мин атмадым,— диде Сәмит, кырт кисеп.

— Сезнең Хәнәфидә үчегез дә булган икән?

— Үч дип андый ук зур үч түгел инде. Шул исерек баш белән... Сез теге сабан туенда булган хәлне әйтәсезме?

— Әйе, әйе... Сездән алынган әйберләрне дә без Казанга экспертизага җибәрәбез. Шулай да сезгә гөптән уйларга киңәш бирәбез,— диде аңа Сәгъдиев.

Сәмит, кыйнап ташлаган кешедәй, идарәдән көч-хәл белән генә чыгып китте.

— Менә хәзер инде, Сәфәр, без дөрес юлда торабыз...



## Яңа версия

Икенче көнне иртән үк район прокуратурасына Сәмит килеп төште. Нинди йомыш аны бирегә алып килгән? Нәрсә әйтергә тели ул? Әллә гаебен үзе сөйләп бирергә җыенамы?

Пыялага «Секретарь» дип язып куйган бүлмә ишеген кыюсыз гына ачып керде дә ул:

— Миңа тикшерүче Сәгъдиев кирәк иде,— дип сорады.

— Әнә өченче бүлмәгә керегез. Рафаил Кабирович анда,— диде кара чәчләрен баш түбәсенә күтәреп бәйләгән кыз.

— Гафу итегез,— диде ул, тикшерүче бүлмәсенә кергәч үк, кабаланып.— Хәтергә кайбер нәрсәләр төште...

Аннары иренен ялап алды.

— Әллә су биримме?

— Рәхмәт, кирәкми.

— Мин бит сезгә законнарны аңлаттым. Җинаятен сөйләп биргән кешегә суд, һәркөндә, йомшаграк караячак.

— Аңлашыла.

— Я, шуннан?

— Дөрес, озак баш ваттым. Шулай да исемә төште бит! Беләсезме? Узган җәйне патроннарны Илшатларда корган идек. Мин аларга сеңелкәшнең дәфтәрләрен дә кыстырып барган идем...

— Кем ул Илшат?

— Исламов. Кәрамовларның күршесе.

— Ә ядрәләр кемнеке иде?

— Һәркем үзенекен корды. Без аны кургаштан кисәбез.

— Кем раслый?

— Хатыны Венера, сеңелем Наилә.

— Исламовның мылтыгы бармы соң?

— Югын юк. Бабасыннан ала ул. Кем соң әле исем-фамилиясе? Менә бит сиңа, тел очында гына тора. Ә-ә-ә! Хәйбуллин, Бикмулла карт.

— Тфү,— дип ачынып куйды Сәгъдиев.— Мин бит сезне башкача әйтер дип уйлаган идем... Ярый, Хәсәнов, тикшерербез.

Җилкәсеннән авыр йөк төшкәндәй, Сәмит җиңеләеп бүлмәдән чыгып китте.

Сәгъдиев шунда ук милициягә барып, майор Андреевка керде. Милиция начальнигы иртәнге почтаны карап утыра иде.

— Тагын бер яңалык бар! — диде ул, исәнләшкәннән соң, һәм Хәсәновның әйткәннәрен сөйләп бирде.

Майор өстәленең уң ягына беркетелгән кечкенә кара кнопкага өч мәртәбә басты. Ишектә лейтенант Шәрипов күренде.

— Сәлам, дускай,— дип, ул кулын биреп күреште.— Бүген иртәләгәнсең!

— Мөһим нәрсә бар. Тагын бер версия килеп чыга бит...

— Сәфәр, я, карагыз әле, Бикмулла Хәйбуллинның мылтыгы учетта торамы?.. Әйе, «Таң» колхозыннан.

Берничә минутка өлкән оператив уполномоченный бүлмәдән югалып торды.

— Учетта. Берданкасы бар икән,— диде ул, кергәч.

— Алайса, Хәсәновның сүзе дөрес булып чыга. Безгә тагын «Таң»га кайтырга туры килер. Сез Исламовларда тенту уздырырсыз, ә мин кешеләрдән сораштырырмын.

Ике араны нибары бер сәгать чамасы үттеләр. Сәгъдиев идарәгә кереп китте, ә лейтенант Исламовларга юл алды. Хатыны өйдә туры килсә, машина белән аны бирегә алып килергә булды.

— Эш озакка сузылды сезнең,— дип каршы алды тикшерүчене Әмирхан ага.— Ул бәндә табылырмы икән соң? Вакыт та шактый үтте бит инде.

— Нишлисең,— дип җавап бирде Сәгъдиев, уңайсызланып.— Җинаятьче бит үзенең визит карточкасын калдырмаган!..

Әйе, күп кешеләр, тикшерү эшенең нинди катлаулы, авыр, тынгысыз эш булуын, тикшерүчеләрдән күпме көч, энергия, белем таләп иткәнен аңлап җиткермиләр шул. Аларга җинаятьче тиз генә табылсын!

Сәгъдиевнең күз алдына үткән гомере килеп басты. Фашист илбасарларына каршы канлы сугышның башлануын бик томанлы гына хәтерли ул. Кешеләрнең коты очып: «Сугыш! Сугыш!» — дип кычкырышуларын, елашуларын һич кенә дә онытасы юк. Алты яшьләр тирәсе генә иде әле ул вакытта аңа. Әтисе өч баланы, әнисен калдырып, сугышка чыгып китте. Шул китүеннән кайтмады. Брянск урманнарында үлеп калды. Рафаил ничек кирәк алай җиде классны бетерде. Нишләргә тагын? Укуны дәвам иттерергә аның көче дә, теләге дә юк. Заводка барып эшкә керде. Башта өйрәнчек, аннан токарь булып эшләде. Шулай эшли-эшли кичке урта мәктәпне тәмамлады.

— Син, Рафаил, инженер булырсың,— дип әйткән иде карт мастер, аның тырышлыгына сокланып.

Ләкин мастер ялгышты. Ул университетның юридик факультетына читтән торып укырга керде. Ә заводтагы эшен дәвам итте.

Менә хәзер ул район прокуратурасында тикшерүче. Елдан-ел Сәгъдиевнең тәҗрибәсе осталыгы үсә бара. Бирегә килгәч, алты ел дәвамында нинди генә җинаять эшләре тикшермәде ул! Социалистик милеккә кул сузучыларны, каракларны, совет халкының иминлегенә, горурлыгына, хәтта гомеренә кул күтәрүчеләрне караңгы почмаклардан яктылыкка, кояш нурлары астына аз чыгардымы ул!

Баштарак, эшкә килгәнче, ул үзе дә тикшерү эшенең кыенлыгын аңлап җиткермәгән иде. Хәзер аңлады инде! Тик тормыш иптәше Фәүзия генә кайвакытларда: «И, Рафаил, ничек түземлегең җитә бу эшкә! Ашың аш түгел, ялың ял түгел...» — дип куйгалый...

Тыштагы машина сигналы аны уйларыннан бүлде. Тәрәзәдән урамга карады. «Газик»тан Шәрипов белән бер хатын-кыз чыгып, ишеккә юнәлделәр.

— Сез Венера Исламовамы? — Ул бу хатын-кызны аягүрә басып каршы алды.

— Ни булды тагын? Әллә безнең Илшатның да сезгә катнашы бармы? — дип сорады Исламова, үзенең кем булуын әйткәч.

— Тикшерәбез әле. Нәрсә килеп чыгар?

— Кызганычка каршы, ул кичне үзем Чистайда идем. Белмим, сезгә нәрсә әйтә алырмын икән?

— Берничә сорауга җавап бирсәгез, шул җиткән. Сез Сәмитне яхшы беләсезме?

— Ничек әйтим? Илшатның ахирәт дусты инде. Бергә салгалыйлар, ауга да бергә йөриләр.

Сүз патроннар коруга күчкәч, Венера:

— Хәтерлим,— дип куйды.— Бу җәй көне иде. Сәмитнең сеңелесенең дәфтәрләре эшкә ярады, дип келеп утырганын да хәтерлим әле. Әйе, әйе патроннарны бездә кордылар.

— Ялгышмыйсызмы?

— Юк, дөресен сөйлим, иптәш тикшерүче.

Сәмит әйткәнчә, Илшатның үз мылтыгы юк икән. Кирәк булганда, каенатасы Бикмулладан алып тора икән.

— Дөресен генә әйткәндә,— диде Венера, авыр сулап,— безнең Илшатка мылтык чире тигән, ахры. Бераз салып алса, гел мылтыкка тотына. Мин үзем дә курка башладым инде...

— Хәзер мылтыгы кайда соң аның?

— Чистайга киткәндә, мылтыгы мич арасында калды. Кайткач инде күрмәдем. Әтигә илткән, ахры.

— Сез аның мылтык кирәк-яракларын безгә бирә аласызмы?

— Кирәк икән, рәхим итегез.

— Алайса, Сәфәр, барыгыз. Кургаш кисә торган әйберләрен дә алыгыз. Кирәк икән, тентү ясагыз. Менә сезгә тентү карары. Ә мин хәзер Исламовны дәштерәм.

Илшат егерме алты-егерме сигез яшьләре тирәсендәге чандыр гына бер кеше иде. Күзләре аның тикшерүчегә ничектер нурсыз, ягымсыз булып күренделәр.

— Минем сезгә нигә кирәгем булды икән? — дип сорады ул, ишектән керешли үк.

— Сез ашыкмагыз,— диде Сәгъдиев.— Мин үзем сезне сорау алырга чакырдым.

— Ярый алайса, сорап карагыз.

— Сезне ау белән шөгыльләнә, диләр. Дөресме?

— Әз-мәз генә. Ләкин минем мылтык юк.

— Ничек, алайса, ауга йөрисез? Коры кул беләнмени?

— Кешедән алып торгалыйм. Кемнән дисезме? Кайвакыт Бикмулла бабайдан.

— Хәзер сездә мылтык бармы?

— Булмаганны бар дия алмыйм. Юк. Мин аны бабайга илтеп бирдем инде.

— Кайчан?

— Числосын хәтерләмим.

— Шулай да тәрәзәгә атканчымы, әллә аткачмы?

— Юк, атканчы. Бер атна элегрәк. Бусын точно беләм.

— Ничек?

— Шулай хәтеремдә калган.

— Менә Венера алай дими бит!

— Ялгыша ул.

— Сезгә тагын бер сорау? Пыж өчен нинди кәгазь кулланасыз?

— Төрле китап, гәҗитә.

— Ә дәфтәр битләрен?

— Хәтерләмим. Юк бугай.

— Сәмит белән бергә патроннар кордыгызмы?

— Кордык.

— Ул сеңелесенең дәфтәрләрен алып килгән идеме?

— Юк.

— Ә менә Сәмит тә, Венера да бу турыда бер сүзне сөйлиләр. Ә сез аларның сүзен кире кагасыз? Сезне кара-каршы китереп сорарга туры килер.

Тентү вакытында Исламовлардан 7 данә 12 калибрлы, 3 данә 16 калибрлы корылмаган патроннар, кургаш кисәкләре алынды. Шәрипов тагын йөзе кырылып беткән бер өтергә дә тапкан иде.

Тикшерүче Бикмулла карт белән дә очрашты. Заманында ул яхшы аучы булган. Әмма хәзер тазалыгы шактый какшаган, аучы сукмаклары аны күптән кызыксындырмый икән инде.

— Мылтыкны сезгә Илшат кайчан китереп бирде, бабай? — дип сорады аннан Сәгъдиев.— Менә шушы мылтыкны?

— Үзе,— диде карт, мылтыгын танып.— Илшат аны тәрәзәгә атканның икенче көнендә китерде. Моны яхшы хәтерлим.

— Ничек итеп?

— Икенче көнне безгә күрше авылдан Марат килеп төште. Энекәш малае ул. «Бабай, мылтыгыңны миңа бирәсеңме?» — дип утырды. «Язуың бармы?» — дип сорагач, «Юк»,— диде. Мин аңа: «Башта язу ал. Аннан мылтык синеке булыр»,— дидем. Менә сез тагын Мараттан да сораштырып карагыз...

# Хакыйкать барыбер җиңә

Кичкырын Исламовлар ишеген шакыдылар.

Илшат әле генә эштән кайткан иде. Бу тавышка ул өйалдына чыкты.

— Повестка китердем,— диде авыл Советы башкаручысы, ишек ачарга чыккан Илшатка.

Илшат повестканы кат-кат укып чыкты. Бу уч төбе хәтле генә кәгазь кисәге аның кәефен бозды. Ашы аш булмады. Йокысы качты, төне буе яткан урынында тәгәрәп чыкты...

Ә иртән ул тикшерүче бүлмәсендә утыра иде инде.

— Элек сезнең суд җаваплылыгына тартылганыгыз бармы? — дип, Сәгъдиев аңа беренче соравын бирде.

Илшат тирән уйга калды.

Тикшерүче соравын кабатлады:

— Нигә җавап бирмисез? Элек төрмәдә утырганыгыз бармы?

— Юк,— диде Илшат, кырт кисеп. Аннары үз-үзен белешмәстән кызып китте: — Мин сезгә әйтәм, юк, юк, дим... Нигә сез минем белән уйныйсыз? Бернинди гаебем юк минем! Сәмит белән хатын аркасында йөртәсез мине. Нишләп миндә тенту уткәрдегез? Болай гына калдырмыйм мин сезне! Прокурорга жалоба бирәм.

— Сез кызмагыз әле, Исламов. Сораган сорауларга гына җавап бирегез. Әллә сез Киров өлкәсендә төрмәдә утырганыгызны оныттыгызмы?.. Хәер, прокурорга жалоба бирә аласыз...

Илшат кинәт башын күтәрде, усал күзләрен тикшерүчегә төбәде. Көченнән килсә, ул Сәгъдиевне ботарлап ташлар иде.

— Бу сезгә ярдәм итмәс,— диде ул, тавышын тагы да күтәрә төшеп.— Хулиганлык кылганмын икән, мин аның өчен өч ел утырган инде. Точка. Тагын сезгә миннән ни кирәк?

— Дөресен сөйләвегез кирәк. Сез бит элек судта булганым юк, дигән идегез. Шуны да киңәш итәм: нервларыгызны саклагыз, үзегезне тынычрак тотыгыз.

— Нервлар әйбәт минем. Аларда сезнең эшегез юк.

— Ул вакытта менә таныш булыгыз: мин сезгә хәзер гаебегезне игълан итәм. Бу карарда барысы да язылган.

Тикшерүче кычкырып карарны укып чыкты.

— Гаебегез нәрсәдә икәнлеге аңлашыламы?.. Менә бирегә имзагызны куегыз. Аннан соң мин сезгә хокукларыгызны аңлатырмын...

— Юк, юк! Мин тәрәзәгә атучы кеше түгел! Сәмит үз бәласен миңа ташламасын! Ышаныгыз миңа: сез ялгышасыз!..

Сәгъдиев тыныч кына сорау алуын дәвам иттерде.

— Әйтик, шулай булсын: Сәмит тә, Бикмулла абзый да, Венера да ялгышалар, ди.

— Дөрес, ялгышалар шул!

— Ә менә ул вакытта сез башка дәлилләрне, бигрәк тә телсез дәлилләрне кая куясыз?

— Нинди дәлилләр ул тагын?

— Минә экспертиза нәтиҗәсе! Тыңлагыз. Мин укыйм. «Кәрәмовлар йортының стенасыннан алынган ядрәләрнең химик составы белән Исламовлар хуҗалыгыннан алынган кургаш кисәкләренең химик составы бер-берсенә охшаган».

— Чепуха бу, иптәш... гражданин тикшерүче! — дип көлеп куйды Исламов.— Чөнки, барлык кургашларның да составы, минемчә, бер төрле булырга тиеш. Кургаш кургаш инде ул.

— Алай түгел икән шул! Минә тагын тыңлагыз. «Кәрәмовлар стенасыннан алынган ядрәләр Исламов йортыннан алынган өтергә белән киселгән».

Илшатның теле аңкавына ябышкан шикелле булды. Бер басып, бер утырып карады. Ул тәмам мәлҗерәп төште. Хәзер ул сыгып ташлаган лимонга охшаган иде.

— Тартырга ярыймы? — диде ул, кесәсеннән бер пачка папирос чыгарып. Аннары калтыранган куллары белән папиросын кабызды. Бер суырды да кинәт кычкырып елап җибәрде. Аның бөтен гәүдәсе хәрәкәткә килде.

— Әй, бу исерек баш! — дип куйды ул, үкси-үкси.

Исламов бераз тынычлангач, тикшерүче сөйләшүне дәвам итте.

— Ни өчен тәрәзәгә аттыгыз?

— Болай гына...

— Бернинди сәбәпсезме?

— Шулай булып чыга инде...

Әйе, исерек баш шулай инде ул, берни белән дә хисаплашмый. Сәбәбе бармыюкмы дип тормый, башына нинди уй килеп төшсә, шуны эшләп ташлый. Үзеннән-үзе җинаять юлына баса.

— Кабатлап сорыйм: ни өчен сез Кәрәмовлар тәрәзәсенә аттыгыз?

— Болай гына...

— Ай-һай, болай гына микән!

Хәнәфи белән Илшат арасында җир белән күк арасы аерма бар. Беренчесе — тырыш, һәр яктан тормышы килгән колхозчы, ә икенчесе — җилкуар, ялкау, исереклеккә башын салган бер кеше. Хәнәфи шифер белән ябылган түбәле зур йортта рәхәт яши, ә Илшат бабасыннан ук калган салам түбәле, яртысы җиргә сеңгән йортны да алмаштыра алмый. Бөтен тапканы шешәгә китеп бара. Күрәсең, мондый «тигезсезлек» аны кыерсыткан. Көнләшү хисләре аның йөрәген тырнаган. Исерек баштан бу хисләр, әлбәттә, тагы да көчәйгән. Урамга мылтык күтәреп чыккан да ул күп уйлап тормаган...

— Мин бит аларны үтерергә дип атмаган! Нигә миңа мондый каты статья бирдегез?

— Бик урынлы статья,— дип сөйләп китте Сәгъдиев.— Беренчедән, өйгә атканда, анда кешеләр барын, аларның тормышына зарар килү мөмкинлеген сез уйларга тиеш идегез. Икенчедән, мылтык ул таш түгел. Таш атып бары бер кешене генә үтерергә мөмкин, ә мылтык ул күп кешеләргә куркыныч тудыра. Дөрес, сезнең җинаять, бәхеткә каршы, беркемгә дә зарар китермәде. Шулай да сезнең өй эченә мылтыктан атуыгыз кеше үтерүгә юнәлдерелгән хәрәкәт булып исәпләнә. Менә шулардан чыгып, мин РСФСР җинаять кодексының 15—102 статьяларының «г» пункты нигезендә сезне җавапка тартырга тәкъдим итәм.

Илшат борын астыннан нәрсәдер мыгырдап куйды.

Эш дәверендә Сәгъдиевкә мораль яктан зәгыйфь булган кешеләр белән шактый еш очрашырга туры килә. Күпләренә бер нәрсә хас: белемнәре ягыннан алар сай, культуралары түбән, даими рәвештә эчүчелек белән шөгыльләнәләр. Исламов та нәкъ менә шундый: аны газета-журнал да, китап та, музыка-сәнгать тә кызыксындырмаган, бар белгәне — «зәм-зәм суы» булган. Шуңа күрә аның дөньяга карашы да бик тар. Киләчәге турында да ул берни кайгыртмый...

Сәгъдиев телефон трубкасын алды да:

— Миңа милиция дежурныен бирегез әле,— диде.— Рафиковмы?.. Миңа ике милиционер җибәрегезче.

Бераздан ике коралланган сакчы Илшатны тикшерүче бүлмәсеннән алып чыгып китте...

# *ХИКӘЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ*

*Хикәя — әдәбиятның иң актив, иң өлгер жанрларыннан берсе. Хикәя белән язучы бүгенге тормышта үзен дулкынландырган, кызыксындырган, борчыган мәсьәләләргә тиз җавап бирә, кечкенә күләмле шушы жанрга гына сыя торган тормыш хәлләрен, сәнгать фактына әйләндереп, укучы алдына куя.*

*Әмма, кызганычка каршы, соңгы елларда язучыларыбыз хикәя жанрына игътибарны киметтеләр, бүгенге көн тормышына багышланган әйбәт хикәяләр аз. Моның беренче сәбәбе хикәя язучы авторларның иҗат активлыгы кимүдә булса, зур гаеп әдәби тәнкыйть өстенә дә төшә. Безнең булган кадәр хикәяләребезгә дә матбугатта әдәби тәнкыйть тарафыннан тиешле бәя бирелми, хикәя язучы авторларның иҗаты тикшерелми, бүгенге көн хикәясе нинди булырга, нинди мәсьәләләр күтәрергә тиеш — шул хакта әдәби әңгәмә алып барылмый. Хәлбуки, әдәбиятта чагыласы тормыш материалы, әдәби осталык турында сөйләшү хикәя жанрын үстерү өчен түгел, бәлки бөтен әдәбият өчен дә кирәк.*

*Яшьләр — әдәбиятыбызның киләчәге. Редакцияләргә әдәби иҗат белән шөгыльләнүче яшьләрдән кулъязмалар гел килеп тора. Ләкин ул әсәрләрнең күбесе сыйфат ягыннан бик йомшак була. Яшь авторларның байтагы әдәбиятка тормыштан түгел, бәлки әдәбиятның үзеннән, укылган китаплардан чыгып киләләр, матур әдәбиятта күп тапкыр чагылган образларны, фикерләрне генә кабатлыйлар. Бу хәл дә зур борчу тудыра. Димәк, бездә әлә Язучылар союзы тарафыннан да, нәшрият һәм редакцияләр тарафыннан да яшьләрнең әдәби әзерлеген үстерү юлында җитәрлек эш алып барылмый, әдәби консультация эше йомшак куелган.*

*Шушы елның 15 маенда «Казан утлары» журналы редакциясе һәм Татарстан язучылар союзы каршындагы проза секциясе инициативасы белән уздырылган җыелышта сүз әнә шул хакта — бүгенге хикәя жанрының торышы турында барды.*

*Фикер алышуга Ф. Хөсни, А. Расих, М. Әмир, Л. Ихсанова («Казан утлары» журналының җаваплы секретаре), Я. Халитов (журналның проза бүлеге мөдире), Ф. Миннуллин (әдәби тәнкыйть бүлеге мөдире), А. Хәсәнова («Азат хатын» журналының җаваплы редакторы), А. Яхин («Чаян» журналының җаваплы редакторы) һәм башкалар катнашты.*

*Журналның бу санында язучыларыбыз Фатих Хөсни һәм Мирсәй Әмирнең әлеге җыелыштагы чыгышларын укучыларга тәкъдим итәбез.*

## Фатих Хөсни

# ХИКӘЯ УКЫЙСЫМ КИЛӘ!

**Һич тә дипломатия сатмыйча, ачыктан-ачык сөйләшәсем килә: кызыклы хәл соңгы вакытта татар әдәбиятында. Кызыклы һәм пошаманлы. Язучылар саны арта, союз членнары артканнан-арта, ә хикәя кимегәннән-кими. Газета, журнал редакцияләре хикәя сорап барабан кагалар. Журналларыбызның аерым саннары бөтенләй диярлек хикәясез чыга. «Казан утлары» журналы — бүгенге татар совет әдәбиятының көзгесе — мәсәлән, быелгы алты санында бары тик өч кенә хикәя урнаштыруы белән «мактана». Җитмәсә тагы, шундый аянычлы хәл безнең татар әдәбиятында, элек-электән хикәяләргә һәм хикәячеләргә бай булган татар әдәбиятында урын алып килә. Хикмәт нәрсәдә соң? Кайдан килеп чыккан торгынлык соң бу?**

**Бер көнне шулай, «Казан утлары» журналы редакциясенең оештыруы буенча, язучылар, тәнкыйтьчеләр, редакторлар җыелышып, шушы турыда сөйләштек. Әлбәттә, бу сөйләшү вакытында да вак үпкәләр, «ат»ның тәртәне, «тәртә»нең атны гаепләве кебек әһәмиятсез әйткәләшүләр булмыйча калмады. Ләкин чыгыш ясаучы иптәшләрнең күпчелеге, килеп туган хәл өчен көенеп, хикәя кытлыгының сәбәпләрен ачарга, аннан**

чыгу юлларын табарга тырышып сөйләделәр. Хикәя жанрына тәнкыйтьнең игътибарсызлыгы, редакцияләрнең, тәҗрибәле өлкән язучыларның яшь хикәячеләр белән тиешенчә эшләмәүләре, журналларның үзләрендә бу жанрның специфик үзенчәлекләре турында ләм-мим сүзнең булмавы, нәшрият каршында кайчандыр яхшы гына эшләп килгән әдәби консультация бюросының кинәт кенә туктап калуы, ниһаять, хикәя жанрына гонорар түләү практикасында зарарлы «тигезләп» кисү кайчысының әле һаман алынып ташланмавы — хикәя жанрының сүлпәнәя башлавының кайбер сәбәпләре әнә шуларда булганлыгы әйтелде. Болары, һичшиксез, шулай. Аларны белеп тору, әлбәттә, ярый. Эшебездә тоткарлык ясаучы бу сәбәпләрне бетерү юлында, бәлки, практик чаралар да күрә башларбыздыр.

Ләкин, ни генә булмасын, сүз белән генә сусын басылмый, шайтан алгыры! Яхшы хикәя укыйсы килә.

Югарыда китерелгән тоткарлагыч сәбәпләрдән тыш, мин үзем тагын ике сәбәпне — икесе дә безнең язучыларның үзләренә кайтып кала торган сәбәпләрне күрсәтер идем. Беренчедән, без, язучылар, үзебез хикәядән тәм тапмый башладык түгелме икән? Көчебез җитсә-җитмәсә, тормыш материалы күтәрсә-күтәрмәсә, аның белән исәпләшмәстән, без барыбыз да, һ. Такташның озын сөйләүче озын мөгаллиме кебек, озын язарга өйрәнеп киттек. Олыраклардан күреп, яшьләр дә шул юлдан китеп баралар. Кайчагында ачу китергеч хәлләр алдында каласың: иптәш әле кулына каләм генә алган, характерлар коя белмәүне әйткән дә юк, юньләп адәм ышандырырлык вакыйгасюжет кора белми, теленең ата-анасы юк, ә ул — капчыгының киң тот — дүрт-биш йөз битле роман күтәреп килгән. Без аңарга, тукта әле, егеткәем, болай зурга үрелгәнче, син әлек кулыңны һәм күңелеңне тыйнаклыкка өйрәт, каләмеңне кечерәк жанрларда чарла, дип әйтәсе урында, зурдан кубып, әлеге чиле-пешле роман турында сөйләшә башлыйбыз, кай очракларда андый чиле-пешле романнарны хәтта басып та чыгарабыз. Шуннан соң ул, җитлекми туган «даһи», нишләп синең хикәя дигән тар гына мәйданчыгында биеп азаплансын!

Аннары тагын икенче бер җитди сәбәп: без хикәя жанрының үзенчәлекле табигате турында бөтенләй диярлек сөйләшмибез, кайгыртмыйбыз. Ә бит нинди дә булса бер һөнәргә үзеңне багышлыйм дисәң, иң элек ул эшнең асылын, аның нечкәлекләрен, «капризларын», нинди материалның аңарга ятып торганлыгын, нинди материалның «каршылык күрсәтәчәген», кыскасы, зур сүздән курыкмыйча әйтсәк, шул эшнең теориясен белергә кирәк. Гаять зур осталыкны һәм нәфасәт тойгысының сизгер булуын, төгәллекне һәм артыклыкны тирәнтен сизә белүне сорый торган хикәя жанры гына әллә бу кагыйдәдән читтә калырмы? Һич!

Әнә шул профессиональ зарурияттан чыгып, бер уңайдан, мин монда, үзем белгәнемчә, хикәя дигән жанрның кайбер «тумыш» табигатенә кагыла торган нәрсәләр турында да сүз ачмакчы булам.

Роман яки повестьтан үзгә буларак, хикәя үз эченә бер яки берничә кеше катнашында «башкарыла» торган тик б е р г е н ә вакыйганы, аның да, агым суның тугайда бер бөтерелеп, чоңгыл ясап, «уйнап» торган ташкынлы төше кебек, дәртләр һәм омтылышлар үзара нык бәрелешә торган конкрет бер «тугаен» гына ала. Вакыйга шулай башлана, үсә, иң үткен бәрелеш ноктасына күтәрелә, аннары әкренләп түгәрәкләнә, бетә һәм тормыш агымы тагын үз юлы белән китә. Бу яктан хикәянең драматик әсәр белән нык уртаклыгы бар. Монда инде, борылып, ян юлларга, тыкрыкларга кереп урап йөрүләр «рөхсәт ителми». Кайбер Көнбатыш теоретиклары хикәянең нигезендә бик нык кысылган, тыгызланып, гади күзгә күренмәслек дәрәҗәгә китерелгән анекдот ята, дип тә раслыйлар, имеш. Моның ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килеп-килмәве турында бәхәс ачмастан, тик шуны гына әйтәсем килә: хикәягә салынган вакыйга, укыган вакытта гына түгел, телдән сөйләп биргән вакытта да тыңлаучы өчен кызыклы һәм гыйбрәтле булырга тиеш. Хәтта тагын да кискенрәк итеп әйтергә мөмкин. Хикәя язганда автор һәрвакыт истә тотсын: тукта, шушы мин язганны укып чыккан берәү андагы вакыйганы үз теле белән икенче берәүгә сөйләп бирә алырмы? Шундык конкрет материал бармы? Сөйләсә, әлеге икенче яки өченче берәү аны кызыксынып тыңлармы? Шушы әчке сорауларга — күңел сорауларына игътибар итеп язылган хикәя, ышанып әйтергә була, шактый зур дәрәҗәдә камиллеккә ирешкән әсәр булырга мөмкин. Бу — мәсьәләнең бер ягы.

Еш кына без тиешенчә игътибар итми торган тагын бер як: хикәя утә гадәти вакыйгага корыла алмый. Хикәя нигезенә салынган вакыйга гадәтилектән чак-чак кына күтәрелебрәк, чыгыбрак торырга тиеш. Романтик пландагы хикәяләрдә бу «чыгынкылык» хәтта аеруча көчле була. Алыгыз Виктор Гюго, Проспер Мериме хикәяләрен. Аларның баш әйләндергеч куе вакыйгаларында нинди дә булса бер хиреслеккә утә нык, утә дәртләнеп бирелгән кешеләр катнашалар һәм укучы ул геройларның «стихиясенә» бер эләксә, тиз генә ычкына алмый. Әлбәттә, андый хикәяләрнең укучыга йогынты тәэсирләре дә гадәттәгедән көчлерәк була. А. П. Чеховның яки Фатих Әмирханның хикәяләрен алып карыйк. Әйтик, «Чиновникның үлеме» хикәясендә бөтен бәла «Корневильские колокола» спектаклен карап утырганда бәләкәй дәрәҗәле мескен чиновник Червяковның искәртмәстән зур дәрәҗәле статский генерал Бризжаловның җилкәсенә-пеләшенә туры китеребрәк ялгыш төчкереп җибәрүеннән башлана. Шуннан китә эчке шөбһәләнү, шуннан китә курку, шуннан китә гафу үтенүләр һәм, ниһаять, юк кына шушы сәбәп бичара чиновникны үлеменә китерә. Гадәти хәлме бу? Түгел. Бу әлеге шул без әйткән «гадәтилектән чыгыбрак» тора торган хәл. Ләкин дәрәҗәлеләр алдында калтырап тору «культ»ка әйләнгән Чехов заманы — иске Россия өчен бу характерлы. Әлбәттә, бик нык күпертелгән, тыгызландырылган, ләкин ышандыра. Һәм әнә шул гадәтилектән «чыгыбрак» торганы өчен ул кызык та, хикәя дә.

Яки Фатих Әмирханның «Габделбасыйр гыйшкы» дигән хикәясен алыйк. Мәдрәсәдән башка дөнья күрмәгән, иске мәдрәсә схоластикасыннан бүтән нәрсә ишетмәгән беркатлы, бераз томанарак шәкерт Габделбасыйр күрше ишек алдындагы бай кызына, үзен күрмәгән, сүзен ишетмәгән килеш, гыйшык уты белән кабына. Башлана хат язулар, башлана йокысыз төннәр, башлана кыз урынына үзенең җиләнен төреп, шуны дәртләнеп кочып ятулар... Хәлбуки, аның кичтән койма ярыгына кыстырып калдырган хатларын иртәгесен дворникның, бу нинди чүп, дип себереп торган көне...

Яки Сәмигулла абзыйның чәй-шикәр мәсьәләләре белән утә хиресләнеп шөгыльләнүе, юлга дип төрелгән төргәкләрне әле бәйләтеп, әле чиштереп, бер дә иренмичә, чәй-шикәрләрне алыштырып баш катыруы нәтиҗәсендә пароходтан калуы...

Гадәти хәлләрме болар? Түгел. Шул ук вакытта, баштан уйлап чыгарган хәлләр дә түгел. Буш хыялга бирелергә яратучы мокыт татар шәкертләре, яки бөтен фантазиясе чәй-шикәр тирәсеннән узмаган вакчыл татар сәүдәгәрләре өчен характерлы хәләхвәлләрне күзәтеп, шуларны бер «төен» тирәсенә туплап, тыгызлап, образ дәрәҗәсенә күтәреп һәм, шул ук вакытта, укыр өчен кызыклы, гыйбрәтле итеп, хикәя дәрәҗәсенә дә күтәреп бирелгән сәнгать тормышы бу. Моны, әлбәттә, чын художник кына эшли ала.

Ах алла, сөйләп торган булабыз тагы! «Хикәя» дигән сүз үзе генә дә бик күпне аңлата түгелме соң? Хикәя икән, димәк, хикәя инде ул, гадәти бер вакыйганы гадәти генә тел белән гадәти генә итеп сөйләп бирү түгел. Кызганычка каршы, бездә еш кына хикәянең хикәя икәнлеген оныту бар. Шуннан аңарга ул күтәрә алмаслык авыр йөк күтәртергә омтылу, яки, моның киресе, шуннан аны шома язылган шаяру әсбабына әйләндереп калдыру. Ахыр чиктә, безнең кайбер хикәя дип тәкъдим ителә торган язмаларыбызның укыр өчен кызыксыз, җанга азык бирү ягыннан көчсез булып чыгулары да шуннан.

Сүз уңаеннан, шаяру турында. Шаяру һәм җитди кешелек язмышы турында. Дөнья шаярусыз булмаган кебек, әдәбият та шаянлык, шуклык бизәкләреннән башка була алмый. Зур язучылар моны аңлыйлар һәм шаянлык-шуклык турында язганда да бу хисләрне җитди кешелек язмышы аша үреп үткәрәләр. Хикәяләр остасы, зур стилист Иван Бунинның «Легкое дыхание» дигән хикәясе искә төшә. Анда сурәтләнгән яшь һәм бик чибәр гимназистка Оля Мещерская шаянлык һәм шуклык ягыннан, бирешсә, тик Такташның Алсуына гына биреша торгандыр. Бөтен нәрсә килешеп тора үзенә, чапса — матур итеп чаба, егылса — матур итеп егыла, сабагын яхшы белә, малайлар аның артыннан дистәләп йөгерергә әзерләр. Ул кашы-күзе, ул чәче, ул прическасы... Сүз уңаеннан әйтеп үтик, шул прическадан башланып китә дә сүз. Көннәрдән бер көнне класс җитәкчесе бу шаян кызга шул прическасы өчен бәйләнә башлый:

— Син онытма, акыллым, андый прическа йөртергә сиңа иртәрәк әле, син дама түгел, син туташ кеше,— дип куя мәсьәләне.

— Ә сез кайдан беләсез минем тулаш кеше икәнлегемне? — ди Оля, аңарга хас турылык һәм беркатлылык белән.

Чынлап та, буласы эш инде булган. Бу чибәр һәм җилбәзәк кызның җиңел уйлавыннан файдаланып, Мещерскаялар гаиләсенең дусты, әлеге класс җитәкчесе дигән әдәпле ханымның бик тә дәрәҗәле агасы, олы яшьләрдәге Алексей Михайлович Малютин, нечкәртелгән хәйләләр белән ул нарасыйны тозакка төшереп, кызны әкрен генә «башлап» китәргә инде өлгергән, имеш. Хикәя, ниһаять, плебей чырайлы ямьсез бер казак офицерының, көнчелек аркасында, Оляны станция платформасында көпә-көндез атып китүе белән бетә. Шаяру — шаяру да, кара әле, бу мәкерле дөньяда артык чибәр һәм үтә җилбәзәк булу да яхшыга алып бармый икән. Хикәянең гыйбрәтле һәм фаҗигале сабагы әнә шунда.

Әмирхан Еникинең «Шаяру» исемле бер хикәясе бар. Пароходта җәйге каникулга таралучы студент яшьләр һәм шул ук пароходның өске катында вакытын һәм маен кая куярга белмәгән, чынлыкта, эшсезлектән, эч пошудан маҗара эзләбрәк чыккан нәфис киемле, чибәр мещанка — Диләрә ханым бара. Алар арасында кызыклы гына танышып китүләр, сыйлашулар, уен-көлкеләр, җәдәш аерышу. Һәм алар арасында бик тә тыйнак, бик тә ихлас күңелле, авылда калган сөйгән кызын бик тә сагынып өлгергән һәм аңарга бүләккә дип бик матур яулык алып кайтып баручы Харис бар. Егет үзенең мәхәббәтенә үтә турылыклы булса кирәк, сүзгә-өнгә бик катнашмый, үзенең эчке дөньясы һәм сөйгән кызына дип алып кайтып бара торган бүләге белән генә калырга тырыша. Ә теге маҗара эзләүче хәйләкәр төлке Диләрәнең күзе нәкъ әнә шул Хариска төшә. Ул аны ничек тә ауламакчы, үзен аулый алмый икән, һич югы, бу җүләр гашыйкның сөйгән кызына дип алып кайтып бара торган бүләк яулыгын кулга төшермәкче. Җәдәштә оту нәтиҗәсендә, Диләрә-юха үзенең бу теләгенә ирешә дә. Харис мескен бүләккә дигән яулыктан колак кагарга мәҗбүр.

Шаяруын шаяру да, шул шаярулар аралаш без монда ихлас күңелле кеше белән туклыктан тәмам бозылган, ике аяклы ерткычка әверелеп бара торган эгоистка арасындагы бәрелешне күрәбез. Һәм бу соңгысына карата чын күңелдән ачынабыз. Нәтиҗә шул: шаяру аркылы да кешегә акыл бирергә мөмкин икән!

Ниһаять, бер тургай турында ике хикәя. Узган ел Ибраһим Газиның «Тургай картаямы икән?» дигән хикәясе чыкты. Быел, әле күптән түгел генә, Эдуард Касыймовның «Саумы, тургай!» дигән хикәясен укыдык. Актуальлек ягыннан Э. Касыймовның хикәясе алгы пландарак кебек. Анда сүз быелгы яз, аның капризлары турында, кошлар һәм кошларга мәхәббәт турында бара. Анда этиле-малайлы ике кеше салкында ачыкмасыннар дип, тырышып-тырышып кыргый кошларга җим ташып йөриләр. Яхшылык эшлиләр, әлбәттә. Сүз дә юк. Ләкин хикәядә иң әһәмиятлесе — хикәядә хикәя юк. Чөнки чын мәгънәсендә ачылган, үзара мөнәсәбәткә кергән җанлы кешеләр юк. Ә менә Ибраһим Газиның «Тургай картаямы икән?»ендә бүгенге көнгә үзе кичергән кичәге көнс аша карый торган, ләкин туры килгәндә бүгенге көн турында да әйтер сүзе булган бик тә сөйкемле, бик тә җанлы Шәйхәттар карт бар. Аның яшь чагында читтән генә булса да яратып йөргән, ләкин Шәйхәттар солдатта чакта ашыгып кияүгә чыккан һәм менә хәзер дә, Шәйхәттар абзагыз «авылда ике генә карт калдык» дип, тын гына юанып йөргәндә, ашыгып үлеп киткән Гөлҗиһан карчык бар. Алар арасындагы ачыкланмаган, гомер буена ачыкланмаган, кем белә, шул ачыкланмаган хәлендә дә, балки, икесен дә җылытып торган кешелекле мөнәсәбәт бар. Һәм шунлыктан хикәя дә бар. Моннан тагын шул нәтиҗә килеп чыга: башка бернинди бизәк тә түгел, хикәяне, барыннан да элек, кешеләр язмышы гына тотып тора әле, кызыклы итә ала.

Тагын нәрсә? Монда тагын хикәянең үзенчәлекле теле — мускулы, нервлары, удар көче, чәчрәп торган очкыны булырга тиешле теле турында да сөйләргә мөмкин булыр иде. Бусының икенче бер зур тема икәнлеген искә алып, хәзергә ул турыда сүз кузгатмаска булдык. Ахыр чиктә, мин дә кеше һәм мин дә язучы лабаса! Нигә барысы турында да мин генә такылдап торырга тиеш, ди? Башка иптәшләр дә уйлансыннар. Аннары тагы бүтәннәргә акыл бирү белән генә эш бетми, чыкса-чыкмаса, минем үземнең дә язасым, хикәя язасым бар бит әле.

Ә шулай да күңелемдәге тагын бер кат кабатламыйча булдыра алмыйм: яхшы хикәяләрне бик-бик укыйсы килә, егетләр!

◇ ◆ ◇

## Мирсәй Әмир

# ИГЪТИБАР ҖИТМИ!

Соңгы елларда безнең вакытлы матбугатта да, китап нәшриятында да хикәяләр чыннан да сирәгрәк басыла. Редакцияләр хикәя азлыктан зарланалар. Чәчмә жанрда язучыларыбыз мөмкин кадәр зуррак күләмле әсәр язарга омтылалар: повесть, роман өстендә эшләүне артыграк күрәләр. Ләкин бу, минемчә, хикәянең жанр буларак искерүе, ягъни аның заман стиленә җавап бирә алмый башлавы турында сөйли торган хәл түгел әле. Чөнки безнең бүгенге чынбарлыкта хикәянең актуальлеген киметерлек берниндидә социаль һәм иҗтимагый сәбәпләр юк. Киресенчә, һәр елы гына түгел, һәр көне диярлек тарихи яңалыклар алып килә торган безнең заманда хикәя — әдәбият арсеналындагы иң җитез, иң уңайлы коралларның берсе. Аны язу өчен дә, басып чыгару өчен дә, уку өчен дә күп вакыт кирәкми. Радио-телевидение аша тапшырырга яки турыдан-туры сәхнәгә чыгып укырга да бик кулай ул. Әчын каләм остасы булган язучы бер-ике битлек кенә хикәядә дә кайбер романнар аша әйтә алмаган зур фикерләрне әйтә, дөньяны шаулатырлык проблемалар күтәрә ала. Моның классик үрнәкләрен без А. Чехов, О. Генри һәм башка күп кенә мәшһүр язучыларның иҗатларында күрәбез.

Совет язучылары, шул җөмләдән үзебезнең татар язучылары арасында да сокланырлык хикәяләр биргән авторлар азмыни? Татар әдәбиятында хикәя гомумән элек-электән бик хөрмәтле урын алып килә. Фатих Әмирхан, Газиз Гобәйдуллин, Шәриф Камал хикәяләре — әдәбият тарихыбызның иң гүзәл сәхифәләрен тәшкил итмиләрмени? Бүгенге әдәбиятыбызны Фатих Хөсни, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники хикәяләреннән башка күз алдыгызга китереп карагыз! Гариф Галиев, мәрхүм Мин Шабай, Рафаил Төхфәтуллин, Газиз Мөхәммәтшин, Габдрахман Минский, Аяз Гыйләҗев хикәяләренә күз йомып карагыз! Һәм гомумән төп жанры ул булмаган башка бик күп язучылар һәм әдәбиятка яңа килүче яшьләр иҗат иткән хикәяләрне искә алыйк. Хикәяләрдән башка әдәбият дөньясын күз алдына китерәсе дә килми. Алардан башка әдәбият бакчабыз бөтенләй шәрәләнеп, ялангачланып калыр иде. Кыскасы, хикәя жанрының бүгенге көндә яшәргә һәм үсәргә хакы булуы һәркем өчен ачык хакыйкать. Мәсьәләнең бу ягы турында бәхәс кузгатырга урын да юк.

Соңгы елларда хикәяләр (сүз, әлбәттә, чын мәгънәсендә бу атамага лаек булган әйбәт хикәя турында бара) азрак языла башлаган икән, моның сәбәбе, минемчә, әдәбиятчыларыбызның, шулай ук редакцияләребезнең бу жанрга карата игътибарны йомшартуларында. Аеруча әдәби тәнкыйть тарафыннан хикәягә игътибар җитми. Газета-журналларыбызда, китап нәшриятларыбызда хикәяләр азмы-күпме чыга тора. Яхшылары була аларның, начарлары була. Ләкин шуларның ни яхшысына, ни начарына карата матбугатта тәнкыйть сүзе әйтелми. Үзенең идея әһәмияте, сәнгать көче белән кайбер повесть яки романнарга торырлык хикәяләр була, дидек. Ә соң бездә аерым бер хикәягә әдәби анализ ясаган тәнкыйть мәкаләсе яки һич югында рецензия чыкканы бармы? Юктыр, булса, күренер иде. Узган елда бездә Ибраһим Газиның «Түргәй картаямы икән?» дигән хикәясе күп кенә мәкаләләрдә телгә алынды. Чынлыкта, телгә алынуга гына түгел, бик зур мактауга, хәтта әдәби анализга лаеклы хикәя. Ләкин Ибраһимга 60 тулу уңае белән уздырылган юбилей чорына туры килмәсә, ул

хикәя турында да шундый җылы сүзләр әйтелгән булыр иде микән? Элегрәк шул ук Ибраһим Газиның «Яшь ленинчы» газетасында «Ак сирень» дигән хикәясе чыккан иде. Анысы да бик матур хикәя иде. Ләкин аны беркайда да телгә алучы булмады. Фатих Хөсни турында хикәя остасы дигән сүзне бик күп ишетәбез. Хаклы әйтелә. Ләкин аның кайсы хикәясенә, үзенә башка тәгаллләнгән сәнгать әсәре итеп, бәя бирелгәне бар?

Хикәяләр белән беррәттән повесть һәм романнар да язучы автор иҗаты турында сүз бара икән, башлыча аның зур күләмле әсәрләре турында тулырак фикер әйтелә дә, хикәяләре турында гомуми характерда гына берничә юл язу белән чикләнелә. Ф. Хөсни турында да шулай була, Р. Төхфәтуллин турында да. Башкаларын әйткән дә юк.

Әдәбиятка яңа килүче яшьләр тарафыннан язылган хикәяләргә дә тәнкыйть игътибары җитми. Күптән түгел мин «Казан утлары» журналында Азат Ганиевнең «Янәшә» исемле хикәясен укыдым. Ул миндә яхшы тәэсир калдырды. Бу яшь авторда хикәяче өчен иң кыйммәтле сыйфат булган кыскалык бар, нечкә күзәтүчәнлек һәм идеяне ачуга тәгал хезмәт итә торган тормыш детальләрен дөрес сайлый белү осталыгы бар. Аңа әле тел байлыгы җитми. Шулай да, образлар теле белән ул укучы күңеленә кирәкле настроениене бирә ала. Бу кыска гына хикәядән без бүгенге чынбарлык өчен хас яшь кеше образларын күрәбез. Алар барыннан да элек азат рухлы, интеллектуаль яктан бай дөньялы, һаман алга — белемгә омтылучы, яшьләргә хас булганча гаять үткен хисле, ялкынлы характерлы кешеләр. Аларда яшәү көче бөркелеп тора. Шунысы характерлы, хикәянең төп героинясы Зилә мәхәббәте уңышсызлыкка очрау хәсрәтеннән үзенүзе үтерергә теләп, агу эчә. Ләкин тормыш, янәшәсендәге иптәшләре аңа үләргә бирмиләр. Зилә суга ташланып үлмәкче. Ләкин монда да тормыш җиңә. Янәшәсендә аның рухи халәтен аңлаган икенче кеше бар. Бер-берсенең йөрәген, уй-тойгыларын яхшы аңлаган кешеләр янәшә булганда, аларга берни дә куркыныч түгел. Уңышсызлыкка очраган мәхәббәт фаҗигасе дә җиңелә. Художник образы безнең әдәбият өчен яңа, дияр идем. Автор тарафыннан эчке дөньясын тоеп язылган, ышандыра торган образ. Ул үзенең янәшәсендәге Зиләне дөньяга янача карарга өйрәтә. Сүз белән түгел, эше, хәрәкәтләре белән. Кыз үзенә күптән таныш булган урманны, рәссам караган ноктадан карап, бөтенләй бүтәнчә күрә башлый...

Кыскасы, мондагы сараң образларга яшерелгән фикерләрне, идея эчтәлеген шәрехли башласаң, бик күп язарга мөмкин булыр иде. Билгеле, яшь автор үзе боларның барын да уйлап та бетермәгәндер. Ләкин ул художник сизгерлеге белән тормышның характерлы детальләрен дөрес тота алган. Алар җитмәгән урында, кирәк детальләрне үз фантазиясе белән тутырырга да курыкмаган. Сәнгать рөхсәт итә торган дәрәҗәдә шартлылыктан файдаланган. Нәтиҗәдә әнә шундый үзенчәлекле, сәнгатьне тойган кешенең игътибарын җәлеп итәрлек хикәя килеп чыккан.

Билгеле, аны шедевр дип булмый. Яшь автор язган, әле җитлекмәгән урыннары да булган бу хикәягә бәлки озаклап тукталмаган да булыр идем. Кайбер иптәшләрнең аны бөтенләй игътибарсыз үткәрүләре белән килешәсем килми. Хәтта кайберәүләр аны башка җүнлерәк хикәя юклыктан аптырап кына басылган әйбер, дип карыйлар икән. Алай гына да түгел, соңыннан беленде: бу хикәяне, идея әһәмияте юк дип, яшь язучының җыентыгыннан бөтенләй сызып та ташлаганнар икән. Бу хәл мине тагын да сагайта төшә. Хикәянең сыйфат дәрәҗәсен билгели торган критерийларыбыз тәгал микән? «Идея эчтәлеге», «сәнгать дөреслеге», «автор позициясе» кебек төшенчәләрне артык примитивлаштырып аңламыйбызмы икән? Бер яктан хикәягә кытлык дип тавыш күтәргәндә, икенче яктан «Янәшә» кебек хикәяләрне корзинга озату — бу әдәби иҗатка карата хуҗаларча эш итә белмәү түгелме?

Сәнгать әсәрләренә бәя биргәндә яхшыны яманнан аера белү бик җиңел түгел. Монда әдәби тәнкыйть ярдәме кирәк. Димәк, хикәя жанры бүген бездә беркадәр кыен хәл кичерә икән, моның җитди сәбәпләреннән берсе әдәби тәнкыйтебезнең аңа җитәрлек игътибар итмәвенә кайтып кала. Бу сәбәп, үз чиратында, редакцияләргә дә, хикәя язучыларның үзләренә дә кагыла. Хикәя турында, тәнкыйтьчеләрне төп трибунага бастырып, алар янына язучыларның үзләрен һәм укучылар активын да чакырып, матбугат битләрендә бик җитди сөйләшәсе бар безгә.

Юк, хикәя корый торган жанр түгел ул!

**Ибраһим Салахов**

# ФӘХРЕТДИН БИНЕ МИФТАХЕТДИН

Моны яздым кулыма каләм алып,
Ни өчен яздым икән, күңелем талып?
Ишеткән җан безләргә дога кылсын,
Гозер сүзен мин әйттем хатка салып.
Моны язган Фәхретдин атым була,
Кәгазьгә язып куйган хатым була.
Дога теләп, моны кем язды дисәң, —
Казан җирлек, нугайдан затым була.

1866 ел.

Моннан шактый еллар элек, Казан университеты китапханәсендә, бер борынгы китапны кулыма алгач, гаҗәпсенү катыш шатлыклы бер дулкынлану кичердем мин. Китапның исемен укыйм: «Шаһмаран». Авторы — Фәхретдин бине Мифтахетдин. Күзләрем алдыйдыр дип, ышанмыйча тагын бер кат укыйм. «Шаһмаран». Фәхретдин бине Мифтахетдин... Әйе, дөрес, шулай язылган. Кабалана-кабалана китап битләрен актарам. Дулкынланудан, ахры, битләрен тоташ укырга сабырлык җитми, әле бер битен ачам, әле икенчесен... Таныш исемнәр сикергәләп куя, таныш тәгъбирләр очрый. Бу — мин белгән, бала чакта дистәләрчә кат ишеткән атаклы Шаһмаран бит! Алай гына да түгел, мин ул Шаһмаранның — Еланнар патшасының торган җирен дә беләм бит әле!..

Ялгыз бала булып үстем мин. Өйдә дә, күрше-күләндә дә минем белән яшьтәш балалар булмаганга, күңел уйнарга ашкынган вакытларда, Сафа җизниләргә йөгерә идем. Менә аларда инде дөнья рәхәте ичмасам! Бала-чага монда черки күче күк. Җаның ни тели — шуны уйныйсың, туйганчы шаярасың, уйнап туйгач, әкиятләр башлана. Бер-беребезне уздырып тезеп китәбез менә дигәннәрен, берәгәйлеләрен! Таз да калмый, алтын әтәч тә, аждаһа да калмый... Әкиятләр туйдыргач, өелешеп тагын уенга ябыша идек. Ул күз бәйләш дисеңме, арка сугыш дисеңме. Уенга аптырамый идек, уйлап таба белә идек! Авыз да ерыла иде, борын да каный иде. Җор идек без, батыр идек. Ә шулай да бер нәрсәдән ярыйсы ук шүрли дә идек. Ул курыткан нәрсә — мунча. Җизниләр бакчасында утыра иде ул мунча. Тәбәнәк кенә, бәләкәй генә булса да, әйбәтләп нарат бүрәнәләрдән буралган иде. Түбәсе дә тактадан. Мунчага керә торган ишек күршеләр ягына, ә өч күзле тәрәзә җизниләр ягына — шомырт агачларына карап тора. Без — малайлар — никадәр генә батыр, гайрәтле булсак та, үзебезнең кайдалыкны онытырлык дәрәҗәдә кызышып уйнасак та, һичберебез, һичбервакытта ул мунчага якынлашмыйбыз, аны ерактан әйләнеп үтәбез. Чөнки анда еланнар патшасы Шаһмаран тора. Аны инде үз күзләре белән күргән кешеләр дә бар. Ул — ап-ак, ди, ике башлы, ди, нәкъ кеше кебек сөйләшә, ди. Курыкмас җиреңнән куркырсың!

...Еллар үтте. Бала чак урмандагы кайтаваз кебек яңгырап алды да, каядыр еракка-еракка китеп югалды. Күрмәдек тә, сизмәдек тә без аның узуын. Бала чактан бирле күп сулар акты инде, күп гомер кичелде... Ә теге без курыккан мунчада бернинди елан патшасы да яшәмәгән икән ләбаса. Ул мунча, заманында, Фәхретдин хәлфәнең өе булган... Бу кечкенә генә мунча-өйгә аның 4—5 балалы гаиләсе сыйган, һәм ул үзе шунда ук әсәрләр дә язган. Әле әйткәнебез, атаклы «Шаһморан» да менә шунда иҗат ителгән икән!

Минем өстәлемдә биш кульязма китап ята. Икесе — Корьән зурлыгында, ә калган өчесе һәфтияк күләмендә, әмма аңа караганда күпкә калыннар. Заманында алар авторның үз кулы белән пөхтәләп төпләнгән булганнар. Бер гасыр буе буыннан буынга, кулдан кулга күчеп, бу китаплар инде шактый таушалган, читләре тузып чачаклана төшкән... Каралып беткән катыргы тышлыкны ачуга гаҗәпләнеп каласың — энҗе кебек тезелгән хәрефләр. Курәсең, кавырсын каләм үтә нечкә итеп очланган булган. Карасы да безнең караларга охшамаган, зәгъфранга тартым кызгылт-сары, елт-елт итеп нурланып тора.

Кульязма китапның иң өстә ятканын кулыма алам. «Шаһморан» 258 биттән тора: 3 нче биттән башлана. 260 нчы бит белән кисела. Бу кульязма, кайчандыр басылып чыккан, әлеге көндә Казан университетының гыйльми китапханәсендә саклана торган «Шаһморан» исемле китапның автор тарафыннан язылган төп оригинал нөсхәсе булырга тиеш. Чагыштырып карар өчен матбугатта чыккан басма китап кулымда булмау сәбәпле, кульязманың никә бите югалганын һәм басма китап белән автор нөсхәсе арасында күпме үзгәреш барын кистереп әйтү кыен. Кульязма «Шаһморан» — 10 меңнән артык шигъри юлдан торган күләмле кыйсса. Әкияти сюжетка корылган булса да, вакыйгаларны тасвирлаганда реалистик күренешләрнең оста сурәтләнүе, теленең саф татарча булуы игътибарга лаек. Хәзерге заман укучысының Фәхретдин бине Мифтахетдиннең «Шаһморан»ын бөтенләй диярлек белмәвен истә тотып, бу әсәрдәге вакыйгалар барышы турында берничә җөмлә белән генә булса да әйтеп китүне урынлы саныйм.

...Рамәл гыйлемен һәм дөнья хикмәтләрен белә торган Даниялның хатыны бер ир бала тудыра. Аңа Җамсаб дип исем кушалар.

Гыйльме хикмәт эчендә галим булыр,
Аны тәгъриф кылырлар инсан, җеннәр,—

дип, Даниял улына зур өмет баглый. Даниял үлеп китә һәм Җамсаб әнисе тәрбиясендә үсә. Галим булыр бу дип күз төбәгән Җамсаб ата-анасының ышанычын акламый: укуга да күңел салмый, һөнәргә дә өйрәнми. Ахырда анасы базардан ике ишәк сатып алып кайта да улына болай ди: «Утын ташып сат, юкса ачтан үләрбез». Шулай итеп Җамсаб утынчы була. Урманга барып утын кисә, базарга алып барып сата. Шуннан килгән акчага көн күрә башлыйлар болар. Бер көнне Җамсаб кулындагы таягы белән, эшсезлектән шаярып кына, җир чокый башлый һәм бер мәрмәр ташны чокып ача. Ачса — кое, ә кое тулы бал! Хәзер Җамсаб һәм аның юлдашлары утын ташып йөрмиләр инде, бал белән сәүдә итә башлыйлар. Соңгы мичкә балны чыгаргач, юлдашлары Җамсабны буш кое төбендә калдыралар да, кое авызын зур таш белән томалап, үзләре шәһәргә кайтып китәләр. Менә шуннан соң Җамсабның җир астындагы мәҗаралары башлана. Ул еланнар патшалыгына барып чыга. Еланнар патшасы Ак елан — Шаһморанны очрата. Шаһморан Җамсабны үзендә калдыра, аны байлыкка күмә. Әмма Җамсабны байлык, рәхәтлек тиз туйдыра, ул анасын, туган илен сагына, хәсрәтеннән авыруга сабыша. Ахырда Шаһморан, Җамсабның гозер-ялваруларына каршы тора алмыйча, аны азат итә һәм туган шәһәренә илтеп куярга әмер бирә. Җамсаб кайта. Кайткач та, елан патшасы Шаһморанга бәйле тагын бик күп хәлләр була. Кыйссаның соңында Җамсаб Мисыр шаһының баш вәзире итеп билгеләнә...

Миндәге кульязмада вакыйгалар әнә шулай тәмамлана. Мондый хикмәтле хәлләрне сөйләүче автор үзе кем булган соң? Чыгышы кайдан?

«1891 сәнәдә июнь 13 яумендә җомга көн бу рисаләне 3 сәгатьтә тәмам кылдым. Катиб: Фәхретдин бине Мифтахетдин, Газани вә Болгари, вә Лаиши, Кәриәһи Юлга».

Гарәп телендә язылган бер китабының соңында автор үзе турында шушы белешмәне бирә. Моннан башка миңа түбәндәгеләр мәгълүм.

Мифтахетдин улы Фәхретдин 1839 елда Казан губернасы Лаеш өязе Югары Юлга авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Үз авылындагы мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, әтисе аны Казанга, үзенең туган тиешлесе Сафиуллага җибәрә. Фәхретдин атаклы мәгърифәтче һәм тарихчы Шиһап Мәрҗани мәдрәсәсендә укый һәм зур остазның үзеннән дәресләр ала. Шәкерт Фәхретдин үзенең гыйлемгә хиреслеге, сүзгә осталыгы, мөназараларда өстенлек алуы белән таныла.

1861 елда Фәхретдин, авылдашы Гарифның димләве буенча, Күкчәтау ягына юлга чыга. Пермь шәһәренә кадәр пароходта киләләр дә калган юлны җәяүләп китәләр.

Ул вакытта Себер тимер юлының салынып яткан чагы була. Акчалары беткәч, көнлекләп юл салуда эшли-эшли, бу ике юлчы, авылларыннан чыкканга дүрт ай дигәндә, Кызылъяр (Петропавловск) шәһәренә килеп җитәләр. Бу турыда үзенең бер истәлегендә Фәхретдин болай дип яза: «Беренче тапкыр казакъ дигән халыкны күрдем һәм телләренә төшенмичә зур хафага калдым. Дустым Гариф шәһәргә килеп төшкән көнне үк бер казакъ баена ялланып, Акмолла дигән якка китте, чөнки ул аларның телләрен беләдер иде. Мин фәкыйрь ялгыз калдым».

Кызылъяр тирәсендә казакълар аңа «мулдәкә»лек тәкъдим итмәгәч, Фәхретдин Күкчәтауга таба китә. Ахырда ул Бурабай тирәсендәге Акылбай дигән бер байның авылына туктап, балалар укытырга яллана.

1866 нчы елны Фәхретдин, гаиләсен алып килү нияте белән, Югары Юлгага кайта. Аның бәхетсезлегенә каршы, нәкъ шул елны меңнән биш наборы башлана. Фәхретдинне, аягында яра булуга карамастан, солдатка алалар. Ул, сигез ел солдат хезмәтен үтәгәннән соң, гаиләсе белән бөтенләйгә Күкчәтауга күчеп килә һәм балалар укыту белән шөгыльләнә башлый. Ул балалар укыта, укый, әсәрләр иҗат итә. Аның язганнары халыкка бик ошый, «Шаһморан»ны һәм аңа иш әсәрләрне авыл кешеләре чиратлашып, кулдан-кулга йөртеп укыйлар. Без югарыда телгә алган мунча аңа өй хезмәтен үти. Балалары үскәч, Фәхретдин урам чатына ике бүлмәле, такта чатырлы яңа өй дә салып чыга, әмма «елан патша өен» дә ташламый. Атнага бер тапкыр кече атна көнне монда мунча керәләр, ә калган көннәрдә Фәхретдин хәлфә ялгызы гына калып төннәр буе «Елан патшасы» белән «сөйләшә...»

Мунча тар булса да, күрәсең, Фәхретдиннең фантазиясе бай, фикере киң булган — ул бик күп язган, татарча һәм казакъча гына түгел, гарәпчә дә, фарсыча да зур-зур әсәрләр иҗат иткән. Кызганычка каршы, аның язганнарының шактые гражданнар сугышы елларында, төрле тентүләр вакытында тар-мар килеп беткән. Инде бүгенге көнгә кадәр сакланган һәм миңа мәгълүм булган әсәрләре түбәндәгеләр:

1. «Шаһморан» — шигъри кыйсса.
2. «Сәетбаттал газый» — шигырь һәм нәсер белән язылган героик поэма. Сакланган өлеше 500 битләр чамасы.
3. «Хаятел хайванат» — хайваннар дөньясын тасвирлаган әсәр.
4. «Казан тарихы» — елъязма.
5. «Дөнья тарихы» — гарәп телендә.
6. «Дөньядагы гыйбрәтле һәм кызыклы вакыйгалар». Бу хезмәттә төрле илларда булып узган вакыйгалар турында сөйләнә.
7. «Җиһаншаһ вә Шәмсебану» — поэма.
8. «Баштан кичкәннәрем». Автобиографик поэма.

«Баштан кичкәннәрем» поэмасының бик күп битләре югалган. Улы — Сафа җизнинең әйтүенә караганда, Фәхретдин бу поэмада үзенең Юлга авылыннан Күкчәтауга баруын, Акылбай авылында балалар укытуын, казакъ халкының тормышын, солдат хезмәтенә алынуын, госпитальдә ятуын, Пензада солдат хезмәтен үтәвен һәм яңадан Күкчәтау далаларына әйләнеп кайтуын тасвирлаган булган. Поэманың сакланган өлеше болай башлана:

Сигез йөз алтмыш беренче ел ирде,
Июнь егерме дүртенче көн ирде.

Дүшәмбе көн сәфәр кылдым мин җиремдин,
Бичара аерылып киттем шунда илемдин.
Фирак булдым Сахибҗамал җарымдин,
Уналты көн генә торып, аерылдым андин...

Кызганычка каршы, бу поэманың бары 46 бите генә (3 нче биттән 50 нче биткә хәтле) сакланган. Бу өлештә авторның солдатка алынуы һәм Казан госпиталендә үткәргән көннәре генә ачыла. Бирелә мин поэмадан кайбер өзекләр китерергә уйладым. Болай эшләү, беренчедән, моннан йөз ел чамасы элек язылган поэманы тел, стиль ягыннан тикшереп карау өчен кызыклы булса, икенчедән, авторның биографиясе ачыклануы, 1861 елгы реформадан соң татар крестьяннарының ни хәлдә булулары, никрутлык, солдатка алыну һәм госпиталь тормышлары чагылуы да игътибарга лаеклы.

Ничә көн, ничә төн йөреп киттек имди,
Алабуга дигәнгә җиттек имди.
Алабуга дигән зур бер каладыр,
Кимәбез шунда килеп тукталадыр.
Кимә туктап ике көн анда яттык,
Кимәсигә төядек мең-мең капны.
Ки анда кап төяргә без дә йөрдек.
Яшьтән күрмәгәнне шунда күрдек.
Ике көндин соң йөрди кимә,
И, Фәхретдин, сүзенне инде сөйлә.

. . . . . . . . . . . . .

Ничә көннәр йөреп кимә ул
Күренди бер кала аты Сарапул.

. . . . . . . . . . . . .

Янә күренде бер кала, аты Пермь.
Тугыз көн инде без суда йөрдек,
Кала күргәч, чыгабыз дип куандык.

Моннан соңгы битләр югалган. Сафа җизнинен әйтүенчә, Фәхретдин менә шул Пермьдә яткан үн «суык аяк» белән бергәләп Кызылъяр — Күкчәтау ягына җәяүләп юл тота. Югарыда әйтелгәнчә, Акылбай авылында биш еллап балалар укытканнан соң, 1866 елда яңадан туган авылына кайта һәм...

...Өйгә керсәм, ул вакыт казан төшкән,
Самавыр кайнап чыгып, чәй дә пешкән.
Җайлы дастырхан салулы тор,
Түгәрәкләп туганнар бары утыр.
Гарип атам бер якта уйга калып,
Һичкем менән сөйләшми утыр.
— Ни сәбәп сөйләшмисең, атам? — дидем, —
Җаең һич килми, ни булды саган, дидем,
Утырасың ваем менән үз алдыңа,
Мәнесен ачсаң иде маган, дидем.
Әткәм җавап биреп: балам, диде,
Бер хәбәрне ишетте атаң, диде,
Иртәге көн приемга барырга
Хәбәр булган саган, диде.

Моннан соңгы юлларда некрут Фәхретдиннең Казанга каралырга баруы тасвирлана. «Җәмагать белән утырып, без юнәлдек, бер ходайга тәвәккәл кылып алып»,— ди ул.

Кәгазьдин «Фәхретдин» дип атымны укып,
Чакырдылар тагын мин гарибне.
Ишектә торган бер ясавул
Ачу белән күлмәгемне тартып алды.
Җап-җалангач мөшкелгә калды хәлем,
Тәнем калтырап, торадыр тетрәп җаным.

Шунда доктор урныннан тора килде,
Баштанаяк гәүдәмне карап торды.
Баштанаяк тикшереп агъзаларым,
Аягымның ярасын карап күрде.
Аягымның ярасын доктор күрде,
Күргәннән соң, уйланып карап торды.
Тотып карап, утырган түрәләргә:
«Тәзәләтен жара», диеп хәбәр бирде.
Өлкән майор карап әвәл закон жаен,
Язгали каләм алды өндәмәен.
Андин соң майорларның барчасы
Язуга керештеләр өстәл саен.
Күзләремнән атылып минем яшем чыгып,
Аягыма көчкә басып, исем китеп,
Бу түрәләр бары яза башлагачтин,
«Принял» дип әйтәме дип, тордым көтеп.

**Аягындагы җәрәхәте бик җитди булганга күрә, Фәхретдинне вакытлыча госпитальгә озатып торалар.**

Атам киткәннән соң кайгуланып,
Сборный казармада хәйран калып
Торганда, военный кәнсиләргә
Тагын иөрде бер солдат безне алып.
Тиз йөреп таш курганга килдек тагы,
Ул таш курган борынгы Казандагы.
Мөселманнан хан патша булган икән,
Әйтеп үткән әвәлге замандагы.
Кургандагы өйләрнең барчасы таш,
Кандай жирне күрмәде бу гарип баш!
Барчалары казенный махкәмәдер,
Сыйфат кылып һичберсен әйтер имәз.
Кургандагы сарайның һәрберсе таш,
Биеклеге барының да 4—5 яташ.
Урамына көн төшми дисәң янә булыр,
Шунда килдек күзләрдән агызып яшь.
Бу курган калган икән борын ханнан,
Ул хан үзе булган мөселманнан.
Тарих мең дә биш йөз утыз елда
Орышып урыс патша алган аннан.
Военный кәнсәләрдә язып безне,
Беркеттеләр дәфтәргә икебезне.
Дүртенче пехот батальонга
Җибәрергә яздылар тагын безне.
Язып алып кәгазьгә безне шунда,
Бер солдатны чакырды, «кил», дип, монда!
Батальон Казанның бер касында,
Газан дигән үзәннең ягасында.
Бишбалта дигән кәрия бардыр анда,
Казан белән дәрнянең арасында.

Биредә авторның үз аңлатмасы бар.
«...Бишбалта дигән бер кәриядер кем, Казандин 5 чакрым бер түбән ердә. Казан илә аның ики арасы улуг сазлыктыр. Ул сазлыкта урыс хәзинә малы белән таштин күпер бина кылыштыр. Биеклеге ердән егерме кәз булыр. Шул күпердин йөреп инде утәрләр. Кәриянең әһеле урыслардыр. Анда бер мәхәллә һәм мөселманнар бардыр. Мәсҗид имам җамиг.

Дүртенче батальон диган шул илнең эчендәдер. Анда аның өчен хәзинәдән олуг сарайлар бина кылынгандыр, казарма диярләр. Яшь солдатларны өйрәтә торган ердер».

Әлкыйсса, китерделәр безни шунда,
Юлдашым Сәйфетдин икәү безне.
Катар-катар тегелгән етмеш чатыр,
Һәркайсында 17 солдат ятыр.
Чатырларның сыртында солдатларны
Алып чыгып, мылтык менән уйнатып тор.
Чатырларның каршындагы кәнсәләргә
Алып килеп безне бирде солдат.
Чыгып килде чатырдан бер ясавул:
Киярсез шинель диган кием, диде.
Онытырсыз сагынуны, илең, диде.
Унөч кадак кулыгызга мылтык биреп,
Өйрәткәле кушармын сезне, диде.
Караңыз сез җыелып уйнаганга,
Шунда торган урыска, мөселманга.
Хезмәт кылмай падишага чара юк,
Военный солдат булып алынганга.
Утырмагыз сез инде кайгуланып,
Уйланып, күңелегезгә кайгу алып.
Ике көн үткәннән соң сез чыгарсыз,
Уйнауга, кулыгызга мылтык алып.
Куеңыз, иләңезне сагынмагыз,
Аңкаулыкка инде салынмагыз.
Ушы әйткән сүземдә булмасаңыз,
Һич миңа шәфкать кыл, дип ялынмагыз.
. . . . . . . . . . . . .
И Фәхретдин! Кил инде юлың бире,
Таш мәрҗәндәй сүзең тезә бирче!
Бәндәсенә ходаның рәхмәте күп,
Һичвакытта өметеңне өзә бирмә.
Сөйләп бирдем, күрдем диеп, канча кыйсса,
Тыңлаганга озындыр ушбу кыйсса.
Моннан соңра күргәнне бераз әйтеп,
Бу кыйссаны кылаен инде кыска.
. . . . . . . . . . . . . . .
Төшкәнемә биш җомга диган чакта
Күрештем атам белән амандашып.
Бик яман йөдәп калган атам үзе,
Зәгъфрандай саргаеп сулган йөзе.
Вә әткәм җылай биреп: «Балам, диде,
Туганнарың барчасы да аман, диде.
Синең өчен зар кылып җылый-җылый
Битакәт, биһуш ятыр анаң, диде.
Әнкәеңнең бик яман хәле, диде,
Әйтер хәл юк сыйфат кылып аны, диде.
Синең кайгу белән форьяд итеп
Гәүдәсендә чыкмаган тик җаны, диде.
Биһуш булып егылыр кардәшләрең,
Синдәй улыбыз күзебезгә күренмәсә.
Вәемнан бер сәгать күңеле тынып
Анаң синең торган юк һичбер заман.
Сәгать саен тилмереп торадыр ул,
Күзен салып син киткән юлга табан».
. . . . . . . . . . . . .

Ярты сәгать шунда үтәр-үтмәс
Чыгардылар атамны ишек ачып.

---

Мин калдым госпитальдә күп көн ятып
Фиршелләрнең кулыннан тәгам татып.

Фәхретдингә госпитальдә шактый озак ятарга туры килә. Ниһаять, аның аягы тәмам төзәлә һәм аны яңадан комиссия аша үткәрәләр.

Кышлар үтеп, кар китеп, язлар җитте.
Июньнең ун көннәре булган чакта
Төзәлеп җәрәхәтем тәмам бетте,

. . . . . . . . . . . . . .

..Кигездиләр ак күлмәк белән ак чалбарны.
Гыйбрәт кылып язамын моның барын.
Солдат булып йөргән көннәрендә
Тыңлагыз Фәхретдиннең күргәннәрен.
Унөч кадак мылтык бирде кулымызга,
Кара каеш бугызды билемезгә.
Җәмәгать, күрсәгез хәйран калыр идегез
Ул вакытта саргаеп, сулган йөзебезгә.
Алга салып ясавуллар чакырады,
Алартып ул күзләрен акырады.
Телен белмәс сүз белән тавышланып,
Ишәктәй авызын ачып бакырады.
Шуның белән өч айдан вакыт үтте.
Күрдек без бу җирдә күп михнәтне.
Көннәрендә — учения, төн булганда —
Каравылга куйдылар мин гарипне.

---

..Унберенче мизанның йолдызында
Поход чыгып киткәле хәбәр булды.
Китәмез гуй инде дип бу шәһәрдән,
Ишеткән соң хәзерләндек бу хәбәрне.
Пенза дигән шәһәргә юнәлткәли
Язу килде военный кәнсәләрдән.
Пенза дигән бер шәһәр булды алда,
Хәбәр булдый киткәли безгә анда,
Дүрт йөз алтмыш чакрым буладыр ул,
Ул Казанның кыйбла тарафында.
Утыз кеше билгеләндек үзләремез,
Яшькә тулып ул вакыт күзләремез.
Чын михнәт килде гуй башымызга,
Зәгъфран кеби саргайды йөзләремез.

. . . . . . . . . . . . .

Әйтеп булмайды сүзләр инде.
Утыз кеше военный кәнсәләргә
Каралуга килдек гуй безләр инде.
Аркабызга пот ярым капчык асып,
Кәнсәләргә без килдек якынлашып,
Гараиб хатыным янымда килә ятыр,
Җылый-җылый күзләреннән яшен сачып.
Байгош хатын янымда форьяд итеп,
Килә ятыр башыннан акыл китеп.
Җылый-җылый, башта әйтеп үткән
Таш курганның кашына килдек җитеп,
Киләде Сәхибҗамал кылып форьяд,

Мин киләмен эчемдән кылып моң-зар.
Моңымны һич мәгълүм кылмасам да,
Ул вакыт булгандыр аннан зыян.
Башым иеп карап киләмен җиргә,
Йоткын булып төшкәннән соң кафиргә.
Сабыр кылмый, җылый бирсәм әгәр,
Дивана диярләр иде мин фәкыйрьгә.

---

Фәхретдин бине Мифтахетдиннең «Баштан кичкәннәрем» поэмасының миндә сакланган өлеше шушы җирдә өзелә. Пенза шәһәрендә озак еллар патшага хезмәт итүе, соңыннан янадан Кукчәтауга әйләнеп кайтуы турында язылган өлешләре югалган.

Әйткәнемчә, Фәхретдин бине Мифтахетдиннең әсәрләре байтак. Аларның һәммәсен бу кечкенә очерк-язмада анализлап чыгу мөмкин түгел. Махсус әзерлеге булган белгечләр кенә аларга төпле бәя бирә алырдыр.

Фәхретдин бине Мифтахетдиннең тормыш юлы, иҗаты турында сүз йөрткәндә, аның балалары һәм аларның язмышларына да тукталып китү артык булмас дип уйлыйм. Чөнки алар үз заманында Кукчәтау өязендәге татар һәм казакъ халыклары арасында культура-агарту эшендә һәм революцион хәрәкәттә актив катнашкан кешеләр.

Фәхретдиннең Гайнелхәят, Хөснелбәнат, Бәдрелхәят, Зәйнәп исемле дүрт кызы һәм Сафа, Һади исемле ике улы була.

Гайнелхәят яшьләй вафат була. Хөснелбәнатне атасы Наурызбай дигән мәгърифәтче казакъ мулласына кияүгә бирә. Наурызбай үз вакыты өчен укымышлы һәм хөр фикерле кеше булган. Ул, үз йортында мәдрәсә ачып, казакъ татар балаларын укырга-язарга өйрәткән, Казаннан китаплар, газеталар алдырып, аларны халыкка таратып торган, үзе дә иҗат эше белән шөгыльләнгән — күп кенә үләңнәр язган.



*Сафа Мифтахетдинов әтисенең кулъязма китапларын укый.*

1900 елларда патша хөкүмәте интенсив рәвештә казакъ җирләрен кысрыклап, җирле халыкны руслаштыру политикасы алып бара башлый. Мондагы халыкны көчләп чукындыру өчен Петербургтан махсус миссионер поплар китертелә. Менә шушы хаксызлыкларга каршы, җирле халык интересларын яклап, Наурызбай һәм аның фикердәшләре көрәшкә күтәреләләр. Халык Наурызбайның эшен хуплап, шәхесен олылап, аны Наван хәзрәт дип атый башлый. Тик кара көчләр дә тик ятмый. 1903 елда Наурызбайны кулга алалар һәм Енисей өязе Казачий станицасына сөрәләр. 1904 елның язында хатыны Хөснелбәнат та, биш баласын ияртеп, ире янына — Енисей ягына юл тота... 1905 елгы революция дулкыннарыннан соң, Наурызбай сөргеннән азат ителеп, Кукчәтауга кайта һәм яңа дәрт белән укыту-мәгариф эшенә керешә. Хөснелбәнат исә бу эштә аның беренче ярдәмчесе була — ул кыз балаларга сабак өйрәтә.

Бәдрелхәят белән Зәйнәп тә, аталары Фәхретдиннең тырышлыгы аркасында, гыйлем-фән китаплары укып, дөньяви белем алуга ирешәләр. Бу кызлар да апалары Хөснелбәнат кебек, тормышка чыгу белән үз йортларында кызлар мәдрәсәсе ачалар.

Совет власте урнашкач, Кукчэтауда ачылган татар мэктэплэрендэге беренче мөгаллимэлэр энэ шул Бэдрелхаят һэм Зэйнэп апаларда укыган кызлар булалар инде.

Фэхретдиннең улы Һади Мифтахетдинов Кукчэтау өязендэ Совет хөкүмэте урнаштыру өчен көрэшүчелэрнең иң активларыннан берсе була. Ул, Кукчэтаудагы татар-казакъ яшьлэреннэн беренче буларак, большевиклар партиясе сафына керэ, өяздэ татарлар өчен мэктэплэр, клублар, уку йортлары ачуда, аларда эшлэү өчен укытучы һэм башка культура хезмэткэрлэре хэзерлэүдэ бик зур хезмэтлэр күрсэтэ.

1918 елда Кукчэтауны Колчак гаскэрлэре басып ала. Байларның доносы буенча Колчак җэзалау отряды «большевик Һади»ны эзли башлый. Ул чак качып котыла. Колчакчылар Һадины тапмагач, аның агасы Сафаны заложник итеп төрмэгэ ябалар. Бары Кызыл Армия частьларының тиз арада Кукчэтауны алуы гына Сафаны үлемнэн коткара.

Кукчэтау өязе колчакчылардан арыну белэн Һади тагын җиң сызганып культура-агарту эшенэ тотына. Аның инициативасы белэн клуб, китапханэ салына. Аларда төрле түгэрэклэр эшли башлый, диспутлар үткэрелэ, эдэби кичэлэр уздырыла. Атна саен диярлек сэхнэдэ берэр пьеса куела. Һади үзе дэ төп рольлэрне башкара. Кирэк булса, пьеса да яза. Мэсэлэн, аның гражданнар сугышы елларын чагылдырган «Кызыл йолдыз» исемле өч пэрдэлек драмасы күп еллар буена авыл сэхнэлэреннэн төшмэде.

Культура-агарту эшендэ аңа хатыны Нэфисэ апа да зур ярдэм итэ. Ул, партия өяз комитеты каршындагы хатын-кызлар бүлеге мөдире буларак, татар, казакъ хатын-кызларын мэктэплэргэ, курсларга урнаштыруда турыдан-туры үзе җитэкчелек итэ.

1929 елны Һади Мифтахетдинов Кукчэтауда беренче булып «Кызыл йолдыз» исемле колхоз оештыра һэм озак еллар буе аның председателе булып эшли... «Кызыл йолдыз» — хэзерге вакытта район үзэгендэге совхозның бүлекчэсе.

Зэйнэп апага хэзер 88 яшь, э Сафа җизнигэ 86 яшь. Икесе дэ бирешмилэр, сау-тазалар эле, мэҗлеслэрдэ, халыкның соравы буенча, «Шаһмаран»нан, «Сэетбаттал»дан өзеклэр укып бирэлэр...

Атасының кульъязмаларын укуда, өйрэнүдэ Сафа җизни миңа бик күп ярдэм итте: танылмаган сүзлэрне ачыклап, төшендереп торды һэм Фэхретдиннең биографиясенэ кагылышлы моментларны ачыклашты. Сүз арасында шундый бер детальне эйтеп үтэсе килэ. Фэхретдиннең кульъязмасы никадэр ачык, матур язылган булмасын, еллар үтү белэн күп җире уңа төшкэн яки тапланган. Мин икешэр кат күзлек киеп таный алмыйм. Э Сафа җизни аларны күзлексез укый.

Фэхретдин бине Мифтахетдин 1913 елда 74 яшендэ Кукчэтауда вафат була һэм Кукчэтау татар зиратына җирлэнэ. Аның кабере бүгенге көнгэ кадэр саклана. Мэрхүмнең кабере ташына, гарэп хэрефлэре белэн уеп, түбэндэге сүзлэр язылган: «Фэхретдин бине Мифтахетдин 1839 сэнэдэ дөньяга килеп 1913 сэнэдэ дарелфэнадан дарелбэкага рэхлэт эйлэди...»

Фэхретдин бине Мифтахетдин үзеннэн соң зур эдэби мирас калдырган. Кызганычка каршы, бу хэзинэнең күбесе югалган. Инде минем кулда сакланган кадэресе дэ зур гыйльми тикшерүгэ мохтаҗ. Бу эш якын елларда эшлэнергэ тиеш.

«Ишеткэн җан безлэргэ дога кылсын,
Гозер сүзен мин эйттем хатка салып», —

дип, килэчэк буынга өмет һэм ышаныч белэн эйтеп калдырылган «гозер»не үтэү — Фэхретдин бине Мифтахетдин исемен һэм аның тоткан урынын эдэбият тарихында билгелэү — безнең бурычыбыз.

## Нияз Хәкимуллин

# ҖИР СУЛЫШЫ



**Без дүртәү. Георгий Золотарев, Галиәхмәт Җамалетдинов, Александр Локтев һәм мин. Алар өчесе Зеленодольск егетләре. Ә мин Казанда яшим. Мин алар белән моннан дүрт ел элек Алтай тауларында кыргыз туристлары белән сәяхәт итеп йөргәндә таныштым. Шулай бер көнне тау битен каплап үскән тайга аланында без дүрт кешелек турист палатасын күрдек һәм, сәяхәтчеләр гадәте буенча, палатка хуҗаларының хәлен белеп китәргә булдык.**

**— Кайсы яктан сез, егетләр! — дип соравыбызга каршы, хуҗалар бертавыштан:**

**— Казаннан! — дип җавап бирделәр.**

**— Чынлапмы! — дидем мин, якташларымны очратуга куанып. — Мин үзем дә Казаннан бит! Кайда торасыз, кайда эшлисез!**

**— Ничек дип әйтергә инде сезгә! — диде Галиәхмәт, ничектер уңайсызланыбрак калып.— Дөресен генә әйткәндә, без Казанның үзеннән үк түгел. Зеленодольскидан без. Әле безнең шәһәр бик алай атаклы түгел, ә Казанны белмәгән кеше юк. Шуңа күрә кем генә сораса да, Казаннан дип җавап бирәбез.**

**Палатка буендагы учак янында шулай сөйләшеп танышып алгач, Георгий белән Александр:**

**— Бәлки сәяхәтләргә дә бергә йөрербез, якташ, — диделәр.**

**Әнә шул көннән башлап без дуслашып киттек, сәяхәтләргә дә гел бергә йөри башладык. Түбәләре болытлардан ашып торган Тянь-Шань тауларына мендек, Алтай, Саян тауларында йөрдек, куәтле Енисейны эшкә җиккән Красноярск ГЭСын карап кайттык һәм Байкал күлендә йөздек. Ә узган ел утлы сулышын бөркеп торучы вулканнар илен — Курил утрауларын күреп кайтырга булдык.**

**Халык арасында нигәдер унөченче санны бик үк яратып бетермәү гадәтка кергән. Безнең сәяхәткә чыгып китү көнебез дә унөченче числога туры килде. Хәтта утырган вагоныбыз да унөченче вагон иде. Әгәр унөченче сан чыннан да бәхетсез сан икән —**

бездән дә уңышсыз юлга чыккан кеше булмаска тиеш иде. Әмма асылда һич алай булмады. Составның иң ахырына тагылган булса да, без утырган унөченче вагондагы пассажирлар гаҗәеп яхшы кешеләр булып чыкты. Килеп керүебезгә, ачык чырай, якты йөз күрсәтеп, сез кемнәр, кая барасыз, нигә әйбер капчыкларыгыз бик зур, бу кадәр күп капрон җепләр белән ни эшләмәкче буласыз, июль аенда нигә мондый җылы киемнәр алдыгыз, дип сораштыра башладылар. Геологлармы, әллә кинооператорлармы, кино төшерергә барасызмы әллә, дип кызыксынучылар да булды.

— Юкка башыгызны ватмагыз, без нибары ил гизәргә чыккан туристлар гына,— дидек без аларга.

Шулай бара торгач, Свердловскины да үтеп киттек. Аннары Новосибирск, Красноярск, Ачинск, Тайшет, Иркутск... Элек сөрген урыны булуы белән яман аты чыккан Себерне танырлык та түгел хәзер. Кая карама анда зур-зур төзелешләр, такта яру заводлары, төрле предприятиеләр, шахталар күренеп кала. .

Иркутскины үткәч, тайга урманнары белән капланган сопкалар башланды. Поезд әле тирән упкын кырыеннан үтә, әле бормалы тарлавыклар буенча бара да туннельләргә кереп китә. Аннары сопкалар артта кала һәм без Байкал күле буеннан бара башлыйбыз. Бу мәһабәт күлне бик күп мәртәбә күргәнем бар минем. Әмма ул һәрвакыт кабатланмас матурлыгы белән күңелне үзенә тарта.

Поезд чаба да чаба. Улан-Удэ, Чита, Биробиджан шәһәрләрен артта калдырып, Амур елгасын үтеп, ниһаять, Хабаровскига килеп җитәбез.

Аннан соң самолетка утырып китәргә тиешбез.

— Хәерле юл, егетләр! Барыр җирләрегез ерак, алдыгызны-артыгызны карап йөри күрегез! — дип, безне бөтен вагон озатып кала. Без аэропортка киләбез һәм Хабаровск — Петропавловск-Камчатский маршруты буенча очачак ТУ-104 самолетын көтәбез. Поездда ,сигез мең километр җир үткән идек. Самолетта тагын ике мең километр чамасы очасыбыз бар әле...

Самолет җирдән күтәрелеп киткәч, пассажирларның берсе:

— Сау бул, материк! — дип көрсенеп куйды.

Ул хаклы иде. Амур үзәнлеген үткәннән соң без, Зур җирдән аерылып, Охот диңгезе өстеннән оча башладык. Диңгез өсте бик тыныч. Яшькелт-зәңгәр суда чагылып кояш нуры күзләрне камаштыра. Кояштан саклагыч күзлек кимәсәң, карый да алмыйсың.

Тагын коры җир күренә башлады. Без бу кай төш икән дип торганда пассажирларга минераль сулар, тәмле конфетлар өләшеп йөрүче стюардесса:

— Сахалин өстеннән очабыз, иптәшләр! — диде.

Без тоташтан тайга урманнары белән капланган ул бетмәс-төкәнмәс хәзинәләр утравын рәхәтләнеп карарга да өлгерә алмый калдык, самолетыбыз, утрауны үтеп, тагын Охот диңгезе өстеннән оча башлады. Ун километр биеклектән очсак та, диңгезнең очы да кырые да күренми. Бары тик төрле якка таба йөзеп баручы кораблар һәм алар артыннан сузылып калган дулкын эзләре генә күзгә чалынып-чалынып китә.

Ике сәгатьтән артык очкач, тагын коры җир — Камчатка күренә башлады. Мондагы кыргый табигатьне яхшырак күреп калыгыз дигәндәй, очучы самолетны түбәнгәрәк төшерә. Ак кар каплаган тау сыртлары тагын да ачыграк күренә башлый. Ә үзәнлекләрне күреп булмый, алар ак томан эчендә. Томан эссе сулы чишмәләрдән, гейзерлардан чыккан пардан хасил булган. Әнә вулканнар да күренә башлады. Их, нинди матур икән алар! География дәреслекләрендәге рәсемнәр генә түгел болар. Авызларыннан ут бөркеп торучы вулканнар. Менә нинди икәнсең син Камчатка — утлы таулар иле!

Камчаткада йөздән артык вулкан бар. Аларның күбесе инде сүнгән, әмма утызының утлы йөрәге әле дә тибеп тора. Алар Көньяк Курил утрауларында да бар. «Курил» утраулары! Һәрвакыт төтен бөркеп «тартып» торганга күрә шулай дип атаган аларны рус диңгезчеләре. Курилда хәрәкәттәге вулканнар тагын да күбрәк — утыз тугыз. Аларның кайберләре диңгез төбеннән үк бәреп тора.

Курил атауларының иң төньягындагы Алаид вулканы үзенә бертөрле булып аерылып тора. Аяз көнне Курил утрауларының теләсә кайсы җиреннән күренә ул. Чөнки



аның биеклеге ике километр ярым. Бу гаҗәеп үзенчәлекле вулкан турында легенда да бар. Аланд элек Камчатка ярым утравының көньягында булган һәм үзен бик горур тоткан, башка вулканнар белән һич тә исәпләшергә теләмәгән, имеш. Шунлыктан башка вулканнар аннан баш тартканнар. Аланд бу хәлгә бик нык үпкәләгән һәм, утраудан китеп, салкын, кырыс дулкыннар арасына океанга кереп урнашкан, ди. Ләкин Аланд йөрәген дә үзе белән алып киткән һәм тагын да зуррак, кодрәтлерәк вулканга әйләнгән.


Аландны беркайчан да яхшылап күреп булмый: чал башын һәрвакыт куе томан каплап тора, ярлары су эчендә. Ә аның элекке урынында үтә күренмәле саф сулы искиткеч күл барлыкка килгән һәм аны Курил күле дип атый башлаганнар.

Иртәнге сәгать тугызда без аэропорт вокзалында идек инде. Безнең белән бер самолетта килгән геолог егет «Спидола»сын бөтен көченә кычкыртып сөйләтә башлады. Мәскәү дикторы соңгы хәбәрләрне тапшыра иде. Менә ул сүзен тәмамлады һәм Кремль курантлары суккан тавыш ишетелә башлады. Бер, ике өч... ун, унбер, унике! Мәскәүдә сәгать төнге унике, ә монда инде иртәнге тугыз, яңа эш көне башланган. Димәк, без кояшны Казан һәм Мәскәү халкына караганда тугыз сәгатькә алданрак күрәбез булып чыга. Уйлап карасаң, гаҗәпләнмәслек тә түгел: никди киң бит безнең туган ил!

Әйе, без хәзер туган илебезнең көнчыгыш чигендә, иң алдан кояш чыга торган җирдә.

Өлкә үзәге Петропавловск-Камчатский — Тын океандагы иң зур портларның берсе. Шәһәр зур Авыча бухтасы тирәли урнашкан. Авыча бухтасы коры җиргә уйдыкланып кереп торган һәм океанга тар гына бер тармак белән тоташкан култык ул. Шунлыктан бухтага океан давыллары килеп җитә алмый. Ул дөньядагы иң матур һәм иң уңайлы гаваньнардан санала.

Без бухта буена киләбез. Бухта суы салмак кына дулкынланып тора. Яр буенда адым саен дулкын чыгарып ташлаган матур-матур ташлар, кабырчыклар һәм төрле төстәге краб кыскычлары очрый. Ак канатлы акчарлакларга охшап, ял итәргә чыккан яшьләр яхталарда йөзеп йөри. Көн җылы, кояшлы һәм җилсез. Ләкин нигәдер берәү дә су коенмый. Әллә бик салкын микән дип, кулларыбызны суга тидереп караган идек — өшетеп ала язды. Петропавловск-Камчатский шәһәре Казаннан көньяк киңлектәрәк урнашкан һәм хәзер июль аеның уртасы, ягъни иң эссе вакыт булуга да карамастан, су коену турында уйларга да ярамый. [Соңыннан белдек: Камчатка ярлары буенкан Ойясио дигән салкын океан агымы үтә, шуңа су җәй көне дә бик суык була икән.]



Без шулай үзара сөйләшеп торганда, бухта суы акрынлап җәелә-арта башлады. Ярларга ишелеп чыкты, яр буендагы ташларны күмеп китте. Су күтәрелә башлаган вакыт иде бу.

Инде әйткәнемчә, шәһәр бухта яры буенча ярым түгәрәк ясап урнашкан. Урамнары сопкалар буендагы террасалар буйлап үтә. Петропавловск-Камчатский — зур шәһәр. Ул яр буйлап егерме биш километрга сузылган. Көньякта тын океанга барып терәлгән, төньягын исә ак карга төренгән биек таулар каплап тора. Ә шул тирәдән ерак булмаган Корякский, Авыча, Вилючинский вулканнары шәһәргә кабатланмас матурлык өсти. Аларның чал башлары шәһәрнең теләсә кайсы урыныннан күренеп тора. Тыныч көннәрдә ул вулканнарның шәүләләрен бухта суында да күрергә мөмкин.

Кичке караңгылык җәелә башлагач, шәһәрдә һәм портта берьюлы меңнәрчә утлар кабына. Кичен Петропавловск-Камчатский аеруча матур була икән. Бухтадагы кораблардан башлап, утлар гел югарыга, сопка буйларына таба күтәрелә һәм бу күренеш күңелдә шундый тойгы уята, әйтерсең, шәһәр күктәге йолдызларга ук барып тоташа.

Камчаткада яшәүчеләрнең барысының да диярлек күкрәгендә значок. Гади значок кына түгел. Юбилей значогы. Әле күптән түгел генә Петропавловск-Камчатскийга 225 ел тулган, значок шул юбилей уңае белән чыгарылган икән.

Азия белән Америка үзара коры җир белән тоташканмы, әллә юкмы! Менә шул мәсьәләне ачыклау нияте белән, «Изге Петр» һәм «Изге Павел» исемле җилкәнле ике корабка утырып, руслар ерак көнчыгышка экспедициягә китәләр. Витус Беринг һәм Алексей Чириков җитәкчелегендәге бу экспедиция кораблары, Камчатканы көньягыннан урап үтеп, 1740 елның сентябрендә Авыча бухтасына килеп керә. Экспедиция членнары кышны шушы бухтада үткәрәләр. Берничә йорт, казарма һәм амбарлардан торган кечкенә генә поселок, шул елдан алып, «Петр» һәм «Павел» дигән әлеге кораблар исемен бергә кушып, Петропавловск дип атала башлый. Петропавловск-Камчатскийга әйләнә.

Экспедиция булып киткәннән соң Петропавловск поселогы шактый нык үсә башлый. Россиянең көнчыгыш чигендәге терәк пункты буларак, аның үсүенә патша хөкүмәте дә әһәмият бирә. Ләкин, шулай булса да, ул чорларда шәһәр әллә ни алга китә алмый, нигездә солдатлар яши торган агач казармалардан гына гыйбарәт була. Бары тик Совет власте елларында гына Петропавловск агач шәһәрдән зур-зур завод-фабрикалары, күп санлы уку йортлары, искиткеч матур парклары, стадионы булган һәм дөнья күләмендә әһәмиятле урын тоткан портлы шәһәргә әверелә.

СССР картасына караган чакта Камчатка ничектер ерак төньякта урнашкан шикелле күренә. Әмма асылда бу һич тә алай түгел. Камчатканың көньяк чиге Киев шәһәре урнашкан киңлектә, ә төньяк чиге Ленинград шәһәре урнашкан киңлектә ята. Шулай булгач, моны төньяк дип әйтеп булмый лабаса!

Камчатканың территориясе дә шактый зур. Атап әйткәндә, аның җире Швеция белән Норвегияне хәтле яки Япониядән өч мәртәбә зуррак. Камчатканы илебезнең «балык цехы» дип атыйлар. Һәм бу дөрес тә. Яр буенда кая карама анда зур-зур балык заводлары һәм балык комбинатлары. Алар ел саен миллионнарча центнер югары сыйфатлы балык эшкәртеп чыгаралар.

Камчатка «балык цехы» гына түгел, ул «йомшак алтын» цехы да. Командор утрауларында яши торган диңгез мәчеләренең кыйммәтле тиреләрен кем генә белми

икән! Торф запасы буенча Камчатка илебездә алдынгы урында тора. Анда ташкүмер, никель, алтын да бар. Ә соңгы елларда нефть тә таптылар. Камчаткада эссе су чыганаклары бик күп. Ул чыганакларны да эшкә җигә башладылар инде. Паужетта, илебездә беренче мәртәбә, җир астыннан алынган җылылык белән эшли торган электр станциясе төзелде һәм ток бирә башлады. Җыеп кына әйткәндә, Камчаткада һәртөрле байлык бик күп. Әмма аның иң зур байлыгы — эш сөюче чирек миллион халкы. Халык хуҗалыгын һәм культурасын үстерү өлкәсендә ирешкән уңышлыклары өчен Камчатка өлкәсенең хөкүмәтебезнең югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнүе әнә шул хакта сөйли.



* * *

Шәһәр белән танышканнан соң, төп максатыбызга ирешергә — җир сулышын тыңлый барырга булдык. Башта, океан корабына утырып, Камчатка ярымутравының көнчыгыш яры буена урнашкан Жупаново поселогына бардык. Анда бик зур балык заводы бар икән. Жупановодан соң Тын океан буеннан җәяүләп китәргә туры килде. Җил әллә ни көчле булмаса да, океан өсте тыныч түгел иде. Бер-берсен куышкандай, чал башлы зур-зур дулкыннар йөгерешә. Вакыт-вакыт алар ничектер кинәт очланып өскә күтәрелеп куялар, үзара бәрелешеп, тирә-якка күбекләрен чәчеп җибәрәләр. Аннары ачыгырып ярга килеп бәреләләр дә хәлсезләнеп артка чигенәләр. Аларга яңа дулкыннар китереп бәрә. Җил һаман көчәя бара. Җил көчәйгән саен, дулкыннар да арта, зурая. Хәзер инде карарга да куркыныч, шомлы була башлый. Тын океан менә шушылай котырына да белә икән ул!

Без көн буе океан яры буйлап бардык. Кичкә таба исә сукмагыбыз кырт кына сулга таба борылды да Семлячински дип аталган эссе су чыганаклары янына алып килде. Кичерәк кенә тарлавык. Мондый тарлавыклар Кавказда да, Алтайда да, Тянь-Шаньда һәм Камчатканың үзендә дә бик күп. Шул ук вакытта Семлячински чыганагының тарлавыгы башка тарлавыклардан бик нык аерыла да. Чөнки монда ел буена багана булып пар күтәрелеп тора. Әйтерсең, кемдер туктаусыз тәмәке тартып утыра! Семлячински тарлавыгының башка тармаклардан аермасы тагын шунда, аның тирәсе һәрвакыт ямь-яшел. Җәйдәкны күмәрлек мондагы шикелле озын һәм куе үләннәрне бүтән беркайда да таба алмыйсың. Семлячински тирәсендә башка тарлавыклар да бар. Әмма аларның берсендә дә мондый үлән үсми, барысы да тап-такыр. Хикмәт шунда, тарлавыктан ага торган эссе су үзенең тирә-ягындагы җирне кышын да, җәен дә җылытып тора, шуңа күрә бу тирәдәге үсемлекләр һәм җәнлекләр дөньясы Камчатка суыкларының бар икәнен дә белми. Хәтта кыш көне дә, бөтен дөньяны кар каплап алган вакытта да, бу тарлавыкта ямь-яшел үлән үсеп утыра икән.



Тарлавык суында ел буена коеналар. Анда җир астыннан көчле агым булып бәреп тора торган уналты чишмә бар. Ул чишмәләрдәге суның температурасы төрлесенеке төрлечә, ә иң эссесе илле градустан артыграк. Тагын шунысы кызык: әлеге эссе сулы чыганаклардан илле-алтмыш метр читкә киттең исә салкын сулы чишмәгә юлыгасың.

Эссе чыганаклардагы суның шифалы үзенчәлекләре бар. Радикулит, ревматизм, тимрәү кебек авырулар белән чирләүчеләр дәвалана икән монда. Тарлавыкта алар өчен махсус ванналар эшләнгән. Күрәсең, бу суның шифасы чыннан да зурдыр, авырулар бик тиз савыгалар икән.



Семлянски чыганакларындагы су утә күренмәле чиста һәм бик тәмле. Аны рәхәтләнеп эчәргә була. Эчүдән тыш, ул эссе суны, трубалар аша үткәреп, йортларны, парникларны һәм теплицаларны җылыту өчен дә файдаланалар. Шулай итеп, бу шифалы су Камчаткада кыш көне дә кыяр, помидор кебек яшелчәләр үстерергә мөмкинлек тудыра.

Табигать матурлыгы хакында сүз чыкса, гадәттә Швейцария табигатен мисалга китерәләр. Минем Швейцариядә булганым юк, шунлыктан ул хакта бәхәсләшә алмыйм. Әмма, минемчә, Камчатка табигате үзенең матурлыгы ягыннан Швейцария табигатеннән һич тә ким түгелдер шикелле. Мондагы табигатьнең матурлыгы шунда, ул бер үк вакытта кырыс һәм бик төрле. Әйтик, шәһәр урамнарында кызу июль көне, ә күп кенә тарлавыкларда кар әле яңа гына эри башлаган, агачлар яфракка бөреләнеп кенә килә. Әйтерсең, монда әле яз башы гына. Табигать кышкы йокысыннан уянып кына килә. Ташка ябышып үскән карлә каеннарга карыйсың да, Камчатка табигатенең кырыслыгына хәйран каласың. Ачы суыклар, томаннар һәм көчле җилләр шулай җиргә ятып үсәргә мәҗбүр иткән ул каеннарны. Июль ае булуга да карамастан, Камчатканың карлы тарлавыкларында җылы киемсез йөри алмыйсың. Кышкы кием белән дә туңдыра әле. Аннары кинәт эссе суга юлыгасың. Юк, җир астыннан бәреп тора торган гади чишмә генә түгел, бәлки эссе сулы зур күл бу. Табигать барысын хәстәрләп куйган монда. Эссе душта коенып чыгасың килә икән, рәхим итеп, шарлавык астына кер дә утыр. Шарлавыкның куәтле агымы кыяның нигезен нәкъ урындык кебек итеп шомартып, чокырлап куйган.



Шул чокырга кереп утыр да рәхәтләнеп коен. Бары тик яхшылап тотынырга гына онытма. Югыйсә көчле агым хәзер үзеңне күлгә бөтереп алып төшеп китә... Башта шарлавык суы бик эссе булып тоела. Әмма, бер-ике минут утыргач, күнегәсең, һәм бөтен тәнгә искиткеч рәхәтлек тарала. Шулай ун минутлап эссе шарлавык астында тәнеңә табигый массаж алгач, чыгасың да күлгә сикерәсең. Анда коенып чыккач, арыганлыкны юып алгандай була, бөтенләй башка кешегә әйләнәсең...

Без юлыбызны дәвам итәбез. Без җир сулышын тыңларга телибез бит. Ләкин әле аңа ерак, йөз километрлап җәяү барырга кирәк.

Байтак баргач, Тын океанга коя торган Шаулы елга тамагында туктап, бераз ял итеп алырга булдык. Уйнап кына кармак салып караган идек, икешәр, өчәр килолы кета һәм горбуша балыклары эләгә башлады. Җебең генә чыдасын да, кармакларың гына түзсен. Әмма безгә балык күпме кирәк соң!! Бу балыклар безнең як балыкларыннан бик нык аерыла. Итләре кып-кызыл аларның һәм бик тәмле.

Ә яр буендагы кыяларда — кошлар базары. Алар бик күп, ботка урынына кайнашалар, кычкырышалар. Без Шаулы елга буенда. Бик тиз һәм каты шаулап ага ул. Шуңа Шаулы дип атаганнардыр, күрәсең. Ләкин никадәр шаулап, котырынып акса да, адәм баласы барыбер авызлыклаган аны: тотынып аргы ягына чыгар өчен елга аркылы юан җеп сузганнар. Җепкә көймә дә бәйләп куелган. Без, шул көймәгә утырып, җепкә тотына-тотына елганың аргы ягына чыгабыз.

— Карагыз әле! — ди Георгий, кинәт шып туктап. — Әнә, күрәсезме, боланнар чишмәдән су эчә!

Аннары, кинокамерасын тотып, су эчеп торучы бер көтү кыргый боланнарга якынрак бара да аларны төшерә башлый. Әмма боланнарның аңа һич тә исләре китми. Әйдә, төшер туйганчы дигәндәй, ана болан су эчеп туйганнан ары да озак кына баласын ялап-иркәләп тора.

Ул боланнар бездән шуңа курыкмый, чөнки алар гомерләрендә бер тапкыр да мылтык тавышы ишетмәгәннәр. Мылтык атарга рөхсәт ителми, чөнки монда дәүләт заповеднигы. Соры аю да, ак төлке дә, кеш тә бар монда. Ә кыр үрдәге, аккош һәм кыр казы кебек кош-кортларның исәбе-хисабы юк!

Тагын бер тиз агышлы елгага килеп җитәбез. Монысында көймә дә, җеп тә юк. Ә җепсез кичү турында уйларга да ярамый, хәзер агызып алып китәчәк.


Әмма без аптырап калмыйбыз. Бик нык капрон җебебез бар безнең. Шуңа тотынып, хәвефсез-хәтәрсез генә бу соңгы елганы да кичәбез. Аннары текә тау башлана. Аңа күтәрелү шактый читен. Әледән-әле кәрлә агачлар, үсемлекләр очрый. Аннары кар башлана. Көчле җил болай да кыен юлыбызны тагын да авырайта...

Ниһаять, тау сырты күренде. Кулыбыздагы маршрут картасына карагандa, ул перевалны үткәч, Гейзерлар үзәнлеге башланырга тиеш. Шунда без җир сулышын тыңларга тиешбез. Юлның соңгы метрларын үтүе аеруча читен. Арыганлык та сизелә башлады. Шулай да без һаман алга атлыйбыз һәм, перевалны үтеп, искиткеч зур казан кырыена килеп җитәбез. Ул казанның киңлеге дүрт километр чамасы, ә тирәнлеге ярты километрга якын. Аның өске кырыйлары ак кар белән капланган, түбәнгә таба төшкән саен кар кими, аннары бөтенләй бетә һәм ямь-яшел үләнлек башлана. Казанның төбендә нәрсә барын күреп булмый, чөнки аны пар болытлары каплап тора.

«Камчатка энҗесе», атаклы Гейзерлар үзәнлеге менә шушы инде. Бөтен җир шарында атаклы Гейзерлар нибары дүртәү генә. Аларның берсе Төньяк Америкадагы Йеллустон паркында, икенчесе Яңа Зеландиядә, өченчесе Исландиядә һәм дүртенчесе менә шушында — Камчаткада. Ләкин фонтаннарының матурлыгы һәм биеккә сиптерүе буенча аларның берсе дә Камчатка гейзерларына тиңләшә алмый.

Гейзерлар — эссе су чыганакларының бик сирәк очрый торган төре. Тагын шунысы кызык, алар фонтаннарын туктаусыз сиптереп тормыйлар, бәлки билгеле бер вакыт үткәч кенә кинәт көчле су һәм пар аттырып җибәрәләр. Башка эссе сулы чыганаклардан алар әнә шул яклары белән аерылып торалар да инде. Гейзерның фонтаны аткан вакытта кечкенә вулкан атылуны хәтерләтә. Гейзер татарча «эссе» дигән сүз. Гейзерлар бары тик хәрәкәттәге вулканнар булган һәм тау ярылу процессы дәвам иткән районнарда гына очрый. Безнең илдә гейзерлар бары тик Камчаткада гына.

Бу Гейзерлар үзәнлеген әле күптән түгел генә таптылар. Яннарына бару бик кыен



булганлыктан, озак еллар буена кеше күзеннән яшерен яткан алар. Хәтта җирле аучылар да белмәгән аларны. Гейзерлар үзәнлеге бары тик 1941 елда гына мәгълүм була. Беренче тапкыр аучылар да, туристлар да түгел, бәлки Кроноц заповеднигының фәнни хезмәткәре ача бу үзәнлекне. Шуннан бирле ел саен бик күп туристлар һәм галимнәр килә монда. Галимнәрне гейзерларның ни өчен алай вакыт-вакыт су фонтаны аттырып тору сәбәбе кызыксындырса, туристларны гейзер фонтаннарының искиткеч матурлыгы үзенә җәлеп итә. Гейзерлар үзәнлеге фонтанлы эссе чишмәләр үзәнлеге генә түгел, бәлки эссе күлләр һәм шифалы сазлыклар иле дә. Бу үзәнлектә ике ярым-өч километр арада егермеләп зур-зур гейзер бар. Аларның һәркайсына исем дә бирелгән: Беренче, Кечкенә, Зур, Биек, Энҗе, Өчле, Күрше һ. б. Менә шул гейзерлар арасында уннарча шифалы сазлыклар, җылы сулы күлләр һәм йөзләрчә вак чишмәләр бар. Алар барысы да сулый: газ, пар һәм эссе су бөркеп торалар.

— Бу үзәнлектә төрле зурлыктагы ике меңгә якын чыганак бар,— ди безне озатып йөрүче экскурсовод Зоя Кузминична.

Өстенә яшел штурмовка, аякларына озын балтырлы резин итек кигән ул кыз һәр гейзерның исемен һәм тарихын бик яхшы белә. Ул монда чын-чынлап тулы хокуклы хуҗа, монда аннан башка беркая да бара алмыйсың. Әйтик, син бер дә исең китмичә генә барган вакытта аяк астыңнан гына гейзер фонтаны бәреп чыгуы ихтимал, ялгыш читкә бассаң, югары температуралы сазлык казанына батып калуың да бик мөмкин. Әйтәм бит, Зоядан башка берни эшләп булмый монда.



— Бу гейзер шуңа «Беренче» дип аталган,— дип сөйли безгә Зоя,— чөнки иң элек шушыны тапканнар. Моннан чирек гасыр элек бу гейзер һәр алты минут саен бик биеккә эссе су фонтаны атып торган. Ә 1961 елда ул кинәт тынып калды һәм аны бөтенләйгә туктады, ахры, дип уйлаганнар иде. Әмма алай булмаган икән. Ял итәргә генә тукталган икән ул. Әле моннан бер атна элек кенә Беренче яңадан «уянды» һәм, күрәсез, әнә ничек матур итеп фонтанлый башлады. Хәзер элеккедән дә ешрак һәм биеккәрәк сиптерә ул!

Без үзәнлек буйлап югарыга таба менәбез. Барган саен җир сулышы ачыграк сизелә. Мондый хозур күренешне әйтеп-сөйләп бетерерлек кенәме соң! Әле анда, әле монда гейзер фонтаннары туктаусыз сиптереп тора. Яки берьюлы төрле биеклектәге берничә фонтан барлыкка килә. Әнә бездән уңдагы Кечкенә исемле гейзерның фонтаны сүнүе булды, сул яктагы зур гей-

зер хәрәкәткә килде. Анысы сүнәргә өлгермәде, арырак тагын ике зур-зур су фонтаны бәреп чыкты. Барысы да әкияттәге кебек монда. Без Зоя артыннан иләп кенә атлый бирәбез, ә ян якларыбызда сазлык казаннары кайнап ята. Балчык, кызыл төстәге гап-гади саз балчыгы, нәкъ манный боткасы кебек кайный бит! Диаметры дүртбиш метр булган ул казаннардагы шул балчыкны богыр-богыр кайнатыр өчен күпме көч кирәк икән! Ул казаннардагы балчык шундый нык кайный, менә-менә ташып китәр төсле тоела. Бар, шул казаннарның берсе янына барып колыңны сузып кара! Казаннардан шактыйерактагы җиргә колыңны куйсаң да, колны пешерерлек эссе бәреп тора. Ә иелеп тыңласаң, аяк астындагы җирнең шаулап кайнап торуы ишетелә. Менә хәзер синнән берничә метрда гына аста яткан газ һәм су парлары кинәт нәкъ син басып торган урында гына җирне бәреп чыгарлар да сине күккә, биеккә тотып атарлар төсле тоела. Резин итекләребезнең табаннары шактый калын булса да, җир кызуы аяк табаннарын пешерә. Әгәр алай-болай шунда утырып торыр булсаң, авызыңдагы су кайнап чыгарга мөмкин! Җирнең үзәге кызган сыекча хәлендә булуына ышансам да, моңарчы мин аны ничектер күз алдына тәгаен ачык итеп китерә алмый идем. Ә менә монда, Гейзерлар үзәнлегендә, чыннан да, җир-анабызның йөрәге әле бик кайнар икәнлеген үз күзебез белән күрдек!

— Балык булса, таба да, кастрюль дә кирәк түгел икән монда, — диде Галиәхмәт, шаяртып. — Куырып ашыйм дисәң, аяк астындагы җиргә, ә балык шулпасы кирәк булса, әнә күлгә генә саласың да пешерәсең!

— Балык нәрсә ул! — диде Зоя, аның сүзен куәтләп. — Балык кына түгел, аю ите дә бик тиз пешә монда. Әнә теге күлгә карагыз әле. Аның суы бертуктаусыз кайнап тора. Кышын да, җәен дә эсселеге һаман бер — туксан сигез градус. Моннан ике ел элек, апрель аенда, бер бик көчле бураннан соң шушы күл өстендә кар күпере хасил булган. Күрәсең, кышкы йокысыннан яхшылап айнып җитмәгән булгандыр инде, шул кар күперен бер аю килеп кергән һәм күлгә җимерелеп төшкән дә шундук пешеп үлгән...

Без, мондагы күренешләргә хәйран калып, акрынлап сәяхәтебезне дәвам итәбез. Менә без хәзер тагын бер төркем гейзер янына килеп җиттек. Гейзерларның берсе аеруча күзгә бәрелеп тора. Анысы башкалардан биегрәк тә, зуррак та, ничектер печән чүмәләсен хәтерләтә. Һәм кинәт шул чүмәләнең төрле җиреннән су сөзелеп чыга башлады. Әмма бу хәл озакка бармады, гейзер шундук тынып калды. Бу — гейзерның хәбәр бирүе. Тиздән су фонтанын аттыра башлаячак ул.


Фото һәм киноаппаратларыбызны әзерләп, нәрсә булыр икән дип көтә башлыйбыз. Без гейзерга шулкадәр якын, хәтта аның суы, шаулап һәм кайнап, ничек итеп өскә күтәрелүенә кадәр сизелеп-ишетелеп тора. Башта чүмәлә түбәсеннән парга төренгән эссе пычрак сызгырып бәреп чыга, аннары берьюлы өч су фонтаны ата башлый. Фонтаннарның биеклеге һәркайсыныкы кимендә егермешәр метр. Аннары тирә-якны сөт шикелле ап-ак пар болыты каплап ала.


Биш, алты, җиде минут үтә, ә гейзер фонтаны һаман сиптерүен дәвам итә әле. Егерме елдан артык, бер генә минутка да соңга калмыйча, шулай ике сәгать ярымнан ике сәгать ярымга фонтанлап тора инде ул. Берьюлы өч фонтаннан сиптергәнгә күрә «Өчле» дип атаганнар аны. Әйе, мондый эссе сулы табигый фонтаннары булса, теләсә кайсы шәһәр дә туристларның Мәккәсенә әйләнер иде.

Әнә бездән сулда, тау битендә тагын бер гейзер. Бик матур конус формасындагы бу гейзерның өсте тоз кристаллары белән капланган. Шул кристаллар, кояшта ялтырап, ничектер шикәрне хәтерләтәләр. Шуңа «Шикәрле» гейзер дип йөртәләр икән аны. Бик актив бу гейзер: өч минуттан өч минутка шактый зур фонтанын сиптереп тора.

Туристлар сукмагыннан еракта булмаса да, Шикәрлегә якын барырга ярамый, чөнки аның янында гына фумора[1] кыры бар. Ул кыр ярым сыек алсу-кызгылт үзле балчык белән капланган. Әнә шул җиргә кызыксынып басып карап, аякларын пешерүчеләр дә була икән. Гейзерлар үзәнлегенә килгән юлда бер группа туристлар очраттык без. Аларның берсе иптәшләренә тотынып, аксаклап кына кайтып бара иде.

[1] Җир астыннан чыккан эссе газларны беренче мәртәбә Италиядә Везувей вулканы аткан урыннарда тикшерәләр. Андагы пыскып, ягъни төтен чыгып торган җирләрне итальянча фумора (тарту, төтәү дигән сүз) кырлары дип атаганнар.— Автор.





Аягын шушы фумора баткаклыгында пешергән булган. Үз сүзле, артык белдекле булып кылану беркайчан да яхшыга алып бармый шул!

Уйлап карасаң, таң калырлык бу гейзерлар. Әйтик, менә янәшә торучы ике гейзер. Шуларның берсе суын егерме метр биеклеккә сиптерә, ә икенчесенең көче нибары өч-дүрт метрга гына җитә. Кайбер гейзерлар дүртәр сәгать ял итәләр дә нибары бер минут, минут ярым гына «эшләп» алалар, ә кайберләре, киресенчә, күп «эшли», ялны бик аз итә. Кайберләре салмак кына аттыра башлый һәм шулай ук акрын гына туктый да. Ә кайберләре кинәт бәреп чыга һәм кинәт туктап та кала. Үзләре кайчан тели, шул чакта атучы гейзерлар да бар монда. Әнә шул гадәтләре өчен аларны «Тотрыксыз» дип атаганнар. Тотрыксызлар белән янәшә үк билгеле бер вакыт үткәннән соң гына сиптерүче гейзерлар да бар. Аларның режимы шундый төгәл, кирәк икән — сәгатеңне дөресләргә мөмкин! Кыскасы, бер үк үзәнлектәге гейзерларның һәркайсының үз гадәте, үз холкы бар. Алар һич тә бер-берсенә ошамаган. Моның сере һәм сәбәпләре нәрсәдә соң! Бу мәсьәләдә галимнәр арасында әлегә фикер берлеге юк. Һәр галим үзенчә фикер йөртә, һәркайсы үзенчә фараз итә.

Без хәзер үзәнлекнең иң матур җирендә — Икеле, Тотрыксыз, Энҗе, Бөек һәм Горизонталь исемле гейзерлар янында торабыз. Шуларның иң зурысы һәм иң матуры — Бөек гейзеры. Фонтанын аттырып тормаганда бөтенләй күренми дә ул, чөнки аның башкаларныкы кебек кабарып торган конусы юк. Ләкин фонтанын аттыра башласа, аннан да матуры булмый инде. Аның янында торганда табигать көчен тагын да ныграк сизәсең. Фонтанын атарга әзерләнә башлаганда Бөек янына якын барырга һич тә ярамый. Ким дигәндә йөз метр читтә торырга кирәк. Әмма шул йөз метрдан да бик яхшы күренә ул. Иң элек гейзер чокырындагы су шаулап кайнарга тотына, аннары, эсселеккә түзә алмыйча, метр ярым-ике метрга сикергәли башлый һәм, ниһаять, кырык метр биеклектәге эссе су баганасы булып һавага күтәрелә. Ә ул баганадан чыккан пар тагын да биегрәк — 150—200 метр биеклеккә җитә. Башка фонтаннар Бөек янында бөтенләй кечерәеп кала. Ике-өч минуттан, яңгыр кебек булып, вак кына тамчылар ява башлый, ә күктә искиткеч матур салават күпере хасил була.

Бөек өллә ни озак сиптерми, нибары ике минут чамасы гына «эшли». Әмма шул кыска гына вакыт эчендә дә егерме биш тонна эссе су чыгарып ыргытырга өлгерә ул!

Бөек эшен бетергәч, аның янына якын ук килергә мөмкин. Хәзер ул дүрт сәгать ярым ял итәчәк, яңадан фонтан аттырырга көч җыячак.

Менә без Беекнең чокыры янында. Аның тирәсендәге җир башка гейзерларныкы кебек түгел, бәлки фонтан сиптергәндә җир астыннан чыккан тозлардан хасил булган үзенә бертөрле тоз-ташлардан гыйбарәт. Ул тоз-ташларның кызыл, ак һәм сары төстәгеләре дә бар һәм алар нечкәтер роза чәчәкләрен хәтерләтәләр. Таш чәчәкләр! Гейзер «авызы» тирәсендә бик күп алар. Беекнең грифоны, ягъни авызы шактый зур: буйга өч, иңе бер ярым, тирәнлеге өч метр чамасы. Менә шул «авыздан» күкерт исе кушылган пар күтәрелеп тора. Гейзер яңадан су фонтаны аттыру өчен көч җыя хәзер. Еракта, кайдадыр җир астында, гүләгән тавышлар ишетелә. Ул тавыш һаман якыная, өскә күтәрелә бара һәм аяк астындагы җирне селкетә башлый. Аннары җир тетрәргә тотына. Җир сулышы менә шушы инде. Хәзер монда торырга ярамый, тизрәк китәргә кирәк. Чөнки Беек тагын кырык метрлы эссе су фонтаны атачак!

* * *

Камчаткадан бик канәгать булып кайттык без һәм быел тагын шунда барырга җыенып торабыз. Ләкин бу юлы без Камчатканың башка җиренә — утлы сулышларын бөркеп торучы вулканнарны карарга барачакбыз.

**Шәүкәт Галиев**

# БАЛАЛАР ДӨНЬЯСЫ

*Көен дәфтәреннән*

## Анынча

Урам чатындагы милиционер машиналарга юл күрсәтеп тора. Бала:
— Светофор абый, — ди.

## Алдан күрүче

Кызчык әбисенең күзлегенә кызыга. Әтисеннән сорый:
— Мин әби булгач, миңа күзлек алып бирерсеңме?

●

Кар төягән машиналар бара.
— Әти, карны кая илтәләр?
— Шәһәр читенә, кызым.
— Анда кар юкмыни?

## Кышкы салкында

Аяк атлаган саен кар шыгыр-шыгыр килеп кала. Бала йөгереп бара да:
— Итек кәбестә ашый! — ди.

## Тәрбияле малай

Кунаклар барында өстәл янына килми. Бер мәлне өстәл астыннан кәгазь кисәге суза. Әтисе алып укый:
«Әти! Колбаса бир әле, 3 кисәк. Үземә, апага, күрше кызына».

## Кызыксыну

Киреләнә башлагач ана баласын өркетмәкче:
— Кара аны, колагыңны борам бит!
— Кайсысын?

## Машинада

— Утыр, улым, урын бар бит.
— Утырмыйм. Җәяү генә басып барасым килә!

## Төшенгән

Балага дөяләр турында диафильм күрсәтәләр. Иртәгесен ул:
— Тагын дөяфильм карыйсым килә! — ди.

## Күрмәкче

Балалар уйный. Кондукторсыз трамвайда кайткан кыз:
— Мин — трамвайсыз кондуктор, әйдәгез! — дип ияртеп китә.

## Тәртипле бозау

Ишек алдында чирәм чемченеп кызыл бозау йөри. Бер малай дүрт аякланып каршысына килә дә: «му-му-у» дип мөгри — бозаулар телендә сөйләшкән итә. Бозау башын күтәреп, чәйнәвеннән туктап гаҗәпләнеп тора. Әмма җавап бирми. Ашаганда сөйләштермә!

●

— Рәшит, исемең ничек?
— Әйтмим!

## Наян

— Сеңелем, сиңа ничә яшь?
— Сигез туларга ун минут, абый!

## Җәлли

Шәһәрдән кайткан кыз:
— Мин бу сөтне ашамыйм, сыерны авырттырып савып аласыз... Миңа кибет сөте бирегез! — ди.

## Унынчысы...

Ана балаларын шелтәли:
— Рәт чыкмас инде сездән. Булмас, булмас!
— Алай димә, әни, сиңа Алтын медаль алып бирдем бит әле!
Моны герой ананың унынчы баласы әйтә...

ж ӂ ж



*Минем «Иске ел кая китә» һәм «Мәктәп юлы» исемле ике китабым чыкты. Алар нәниләр өчен язылганнар. Быел «Чын герой» дигән өченче җыентыгым чыгачак. Шигырьләрем өлкә газеталарында, «Ялкын», «Азат хатын», «Совет мәктәбе» журналларында басылып килә.*

*1930 елда Арча районының Чөмәелга авылында туганмын. Арча педагогия училищесын тәмамлагач, 1948 елда укыта башладым. Читтән торып, педагогия институтын тәмамладым. 1950 елдан Саба районының Эзмә мәктәбендә.*

*Мин иҗатымны нәниләргә багышлыйм. Алар дөньясын яхшы белергә тырышам, аларның тапкырлыгын, зирәклеген иҗат фантазиясе аша үткәреп, аларның үзләренә үк бүләк итәсем килә.*

## Заһирә Гомәрова

# ТӘРӘЗӘ ТӨБЕНДӘ

— Тәрәзә төбенә
Утырма,— ди әби,—
Кем шунда утыра,
Ул үсми бер дә,— ди.

Ә бит гөл утыра,
Ә бит гөл гел үсә.

— Гөл ул,— ди,— әбием,—
Һәр көнне су эчә.

— Мин дә,— дим,— эчәрмен,
Гөл кебек үсәрмен.

# КҮЧЕРДЕМ ДӘ КҮЧЕРДЕМ

Язганнарын күршемнең
Сүзен сүзгә күчердем.

Ышанмасаң, кил, күр бер,
Урынында һәр өтер.

Укытучы аралый;
Безгә тигез карамый.

Әйбәт карый күршемә,
Куя аңа «биш» кенә.

Ачу иткән шикелле,
Миңа тезә «икене».

Күргәнме күчергәнне,
Класстан күчермәде.

Күчермәс идем дә мин,
Күчермәс дип белмәдем.

# ЙОКЫ ЧҮЛМӘГЕ

Кызарып кояш та чыкты — белмәде,
Карлыгачлар күтәрелде — күрмәде.
Чылтырап аккан чишмә көтте — килмәде,
Бану — йокы чүлмәге.

Иртән чыклы үләннәрдә йөрмәде,
Шомартып чәчләрен тарап үрмәде,
Бит-күзләрен юарга өлгермәде,
Бану — йокы чүлмәге.

Бантикларын да өтеләп тормады,
Йомарланган килеш әнә күлмәге.
Вакытында мәктәбенә килмәде,
Бану — йокы чүлмәге.

**А. Халиков,**
тарих фәннәре докторы, профессор.
**Р. Фәхретдинов,**
тарих фәннәре кандидаты.

# *ТАТАР ХАЛКЫ ТУРЫНДА ЗУР ФӘННИ ХЕЗМӘТ*

Халкыбыз озын һәм катлаулы тарихи юл үткән. Татар халкы шактый четерекле социаль-экономик шартлар дәвамында, һәртөрле илбасарларга каршы көрәш барышында үзенең матди һәм мәгънәви культурасын тудырган. Халыкны халык иткән төп милли үзенчәлекләрнең әлегәчә саклануы һәм аларның яңа формаларда баеп баруы — халкыбыз акылы иҗат иткән материаль һәм рухи байлыкның үтә тотрыклылыгы турында сөйли.

Үткәне белән горурланырлык халык тарихын һәм аның культура мирасын яңа буыннарга һәм, гомумән, бүгенге дөньяның башка кешеләренә күрсәтү — изге һәм зарури бер эштер. Татар халкы әнә шундый олы миссияне үти алырлык зур бер тарихи-этнографик хезмәткә мохтаҗ иде. Андый хезмәтнең юклыгыннан культура тарихының төрле өлкәләрендә эшләүче галимнәр һәм иҗат кешеләре дә интегә иделәр.

Хәзер бу мохтаҗлык артта калды — биш миллионлы татар халкының материаль-рухи культурасына багышланган һәм күптән көтелгән фәнни хезмәт дөнья күрде. «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» дип аталган бу китап СССР Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре тарафыннан язылып, Мәскәүнең «Наука» нәшриятында басылып чыкты[1]. Коллективның җитәкчесе — Идел буе халыклары этнографиясенең зур белгече, тарих фәннәре докторы, мәрхүм профессор Н. И. Воробьев.

Татарларның төрле группалары тарихына, көнкүрешенә һәм культурасына кагылышлы бай мәгълүматларны җыйнап бирү ягыннан бу хезмәтне чын мәгънәсендә татар этнографиясенең энциклопедиясе дип атарга була. Китапның аерым бүлекләрен санап үтү генә дә күтәрелгән проблемаларның гаять кызыклы һәм күп кырлы булу хакында сөйли. Монда татар халкының формалашу тарихы да, историография һәм халык саны да өйрәнелә, көнкүреш һәм материаль культурасына да тулы характеристика бирелә. Беренче тапкыр буларак, халкыбызның иҗтимагый һәм гаилә-туганлык мөнәсәбәтләре, рухи культурасы һәм фольклор тарихы буенча киң һәм кызыклы мәгълүматлар җыйнап бирелә.

---

[1] Татары Среднего Поволжья и Приуралья (ответственные редакторы Н. И. Воробьев, Г. М. Хисамутдинов). Изд. «Наука», Москва. 1967 (рус телендә). 537 битле. Тиражы 6300. Бәясе 2 сум 50 тиен.

Советлар Союзы халыклары арасында сан ягыннан бишенче урында торган татар халкы үзенең составы буенча күп төрле. Ул ике төп группага — Казан татарларына һәм мишәрләргә бүленә. Боларның һәрберсе тагын кечерәк өлешләрдән тора. Мәсәлән, Казан татарлары арасында типтәрләр, кряшеннәр, касим, нократ, пермь, оренбург татарлары бар, ә мишәрләр — сергач, темников, сембер, чистай һ. б. группаларга бүленәләр[1]. Шушы һәрбер группаның килеп чыгышы гомумән татар халкының озын һәм катлаулы тарихы белән аерылгысыз бәйләнгән.

Әйтергә кирәк, революциягә кадәрге дәвердә дә, совет чорында да татар этнографиясе буенча байтак кына хезмәтләр язылды. Әмма аларның күбесе материаль көнкүрешне генә тасвирлауга багышланганнар иде. Халкыбызның иҗтимагый һәм гаилә мөнәсәбәтләре, аның ифрат та бай рухи культурасы этнографик әдәбиятта моңарчы үзенә урын таба алмый килде. Шулай ук татарларның күп санлы этник группалары да тиешенчә яктыртылмады. Янәдән килеп, шуларның барын бергә берләштергән, татар халкының традицион этнографиясе буенча моңарчы җыелган бик күп фактик мәгълүматларны туплаган бер монографик хезмәт юк иде. Без рецензияли торган бу китапны Урта Идел һәм Урал буе татарларының төп группаларына хас материаль, социаль һәм рухи көнкүреш мәсьәләләрен ачыклауда беренче уңай адым дип карарга кирәк. Культурабызның формалашу тарихын ачыклауда һәм бу культураның төрле социаль-экономик шартлардан бәйле булуын күрсәтүдә бу хезмәт күркәм бер башлангыч саналырга лаек. Әлеге проблемаларны чишкәндә авторлар дөрес юл сайлаганнар: материаль һәм рухи культураны өйрәнүнең нигезе итеп татарларның алдынгы группасы — казан татарлары алынган. Башка группаларның үзенчәлекле яклары чагыштыру ярдәмендә яктыртылган.

Китап нигездә татар халкының традицион этнографиясен, ягъни халкыбызның Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр формалашкан этнографиясен яктыртуга багышланган. Хәлбуки, халыкның көнкүреше һәм культурасы хәзерге заманда нык үзгәрде, аның аерым өлешләре хәтта бөтенләй онытылып, эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культураның яңа элементлары белән алыштырылды. Әмма халкыбызның хәзерге этнографиясен һәм культурасын аның элекке этнографиясеннән башка күз алдына китерү бөтенләй мөмкин түгел. Менә шуңа күрә дә авторлар, «татар халкы көнкүрешенең һәм культурасының Совет власте елларындагы үзгәрешен тикшерү үзе бер мөстәкыйль җаваплы проблема һәм махсус монография өчен тема булып тора» дип уйлаганнар һәм беренче чиратта традицион этнографияне җентекләп тикшерүне максат итеп куйганнар. Безгә калса, бу юл да дөрес сайланган, һәм киләчәктә халкыбызның бүгенге тормышына багышланган икенче бер зур монография дә чыгар әле дип ышанасы килә. Шунысын күрсәтеп үтү дә зарури — хезмәт шактый кызыклы күргәзмә материал белән тулыландырылган. Китапта XVIII һәм XIX йөздәге аерым сәяхәтчеләрнең татар тормышыннан алып эшләгән гравюралары һәм XX йөз башы фоторәсемнәре беренче мәртәбә җыйнап бирелә.

Китап проф. Н. И. Воробьев тарафыннан язылган «Гомуми мәгълүматлар» исемле бүлек белән ачыла. Бу бүлек үзе өч кисәктән тора: «Татар халкының формалашу тарихы», «Кыскача историографик күзәтү», «Халыкның таралышы һәм саны». Халыкның килеп чыгышына багышланган бүлек нигездә Идел һәм Урал буе татарларының тарихын дөрес ачыклый. Безнең эраның IV гасырында көньяк-көнчыгыштан һәм көньяктан безнең бу якларга килеп чыккан күчмә һәм ярым күчмә кабиләләр борынгы бабаларыбыз булып санала, диелә китапта. Алар Идел буена килгәч, Уралдан алып Ока елгасына тикле булган зур территорияне билиләр һәм әкренләп җирле халыкны ассимиляциялиләр. IX йөздә бу территориянең үзәк җирләрендә Болгар исеме белән мәгълүм булган беренче феодаль дәүләт төзелә (9 нчы бит). Чыннан да, соңгы еллар-

---

[1] Биш миллионның бары тик 200 меңе генә башка татарлар — себер, литва, әстрахань, кырым татарларына туры килә. СССРның күп почмакларына таралып утырган башка татарлар чыгышлары белән барыбер Идел һәм Урал буе татарлары дип аталалар. Алар төрле тарихи шартлар нәтиҗәсендә шулай таралышып утырганнар. 2160 мең татар авыл җирендә, ә калганы, ягъни күпчелеге, шәһәрләрдә һәм эшче поселокларында яши. Илебездәге барлык татарларның 29 проценты гына Татарстанга туры килә. Бу статистика 1959 нчы елгы сан алу мәгълүматлары буенча китерелә. Яңарак материаллар буенча халкыбызның саны тагын да арта төшкән.

да тупланган яңа археологик һәм палеолингвистик мәгълүматлар, шулай ук кайбер этнографик күзәтүләр татарларның борынгы төрки бабалары бу якларга шактый иртә килгәнлеге турында сөйлиләр. Күрәсең, шушы борынгы төрки нигез соңга табарак берничә тапкыр Идел буена күченеп килгән төрки кабиләләр бәрабәренә тулыландырылгандыр. Ахыр чиктә алар бары бергә Идел һәм Урал буе татарлары этногенезының фундаментын тәзегәннәр. Билгеле, бу фундаментның иң тотрыклы өлешен Болгар дәүләтенең болгарлар исеме белән мәгълүм булган төп халкы тәшкил иткән.

Татар халкының этник үзенчәлекләренең формалашуында Көнчыгыш Европаның бер-берсе белән нык бәйләнешле ике феодаль дәүләте — Болгар һәм Казан ханлыклары чоры зур роль уйнаган. 700 ел буена сузылган болгар-татар дәүләте чоры бай этнографик культураның барлыкка килү һәм үсү дәвере булган. Монда шунысы бик әһәмиятле — бу зур дәвер халкыбызның крайдагы башка кабилә һәм халыкларныкына караганда күп өстен торган шәһәр культурасы булуы һәм нык алга киткән һөнәрчелекнең үсүе белән характерлы. Әле шул ягы да бар, безнең бабаларыбыз, күчмә төрки һәм җирле угро-фин кабиләләре белән тыгыз бәйләнештә булу белән беррәттән, шул заманның шактый алга киткән Европа — Азия илләре белән дә тыгыз мөнәсәбәттә булганнар. Әлеге бүлектә Болгар һәм Казан ханлыкларының Кавказ, Якын Көнчыгыш, Урта Азия, Рус дәүләте белән экономик һәм культура бәйләнешләренә ныграк басым ясалса, китап тагын да отышлырак чыккан булыр иде.

1552 нче елда элеккеге Болгар — Казан җирләре руслар тарафыннан колонизациялә башлый. Патша хөкүмәте мәрхәмәтсез рәвештә руслаштыру һәм көчләп чукындыру политикасы үткәрә. Мондый политика халыкта нык канәгатьсезлек тудыра һәм баш күтәрүләр китереп чыгара. Кысрыклаулардан һәм җәберләүләрдән туйган татарлар Идел һәм Урал буеның тынычрак урыннарына күчеп китәләр һәм башка төрки халыклар белән аралашалар, туганлашалар. Татарларның үз җирләреннән күченеп утырулары XVII йөзнең уртасында тагын да көчәеп китә. Кама аръягы һәм Сембер ныгытмалары дип аталган хәрби ныгытмалар төзү өчен, патша хөкүмәте көнбатыштан күпләп мишәрләрне, чувашларны һәм мордваларны күчереп утырта. XVIII йөздә янәдән Урал һәм башкорт җирләренә мишәрләр, бигрәк тә казан татарлары күчеп китәләр. Типтәрләр, Каргалы татарларының формалашуы шушы дәвер белән бәйләнгән. Тагын да соңрак, татарлар ерагракка — көньяк-көнчыгышка, Урта Азия җирләренә үтеп керә башлыйлар. Моңа инде капиталистик мөнәсәбәтләрнең нык тамыр җәюе, сәүдә сәбәп була. Бу мөнәсәбәтләр тагын да көчәя һәм крестьяннар арасында сыйнфый катлауланү арта барган саен, татарлар «бәхет эзләп» зур промышленность үзәкләренә күченеп китәләр. Донбасс шахталары, Баку нефть промыселлары, Урал заводлары, Себер алтын прискаларының эшчеләр сыйныфы татарлар исәбенә нык арта. Әгәр дә элегрәк, мәсәлән, Болгар һәм Казан дәүләтләре чорында ук әле крайдагы башка халыкларга караганда, татарлар арасында шәһәр халкының проценты күп югары булса, капитализм чорында бу аерма тагын да үсә. Әмма үзенең төп территориясеннән читтә, башка халыклар чолганышында яшәүләренә карамастан, мондый группалар үзләренең телләрен һәм культураларын саклап калалар.

XIX йөздә татар милләте тәмам формалаша. Шул уңай белән аның культурасында һәм көнкүрешендә булган үзгәрешләрне авторлар дөрес һәм ачык күрсәтә алганнар. Нәкъ менә шушы чорда инде, ягъни феодаль-мөселманлык һәм буржуаз-демократик ике агымның көрәш чорында, татар халкы этнографиясенең төп үзенчәлекләре чынчынлап формалашып өлгерә. XIX йөз ахырында һәм XX йөз башында татар культурасы үсешендә революцион-демократик агым нык көчәя һәм бу агым Октябрь революциясеннән соң яңа үсеш кичергән культураның нигезенә әверелә. Татар халкының барлыкка килүе һәм аның милләт булып оешуы шушы планда дөрес чишелгән. Татарларны шушы рәвешле этник группаларга бүлү, проф. Н. И. Воробьев исеме белән бәйле рәвештә, хәзерге көндә үзенең классик формасына керде. Ләкин әле бу — кайбер группаларның килеп чыгышына иkенче төрле караш юк диган сүз түгел. Мәсәлән, соңгы вакытта мишәр этногенезына карата кайбер яңарак фикерләр туды. Билгеле, әлеге рецензияләнә торган китапта да бу этногенезның борынгы дәвере әйтелеп кителә. Ләкин ул фикер археологик, антропологик һәм лингвистик мәгълүматлар белән ныгытылмаган. Ә соңгы ел материаллары мишәрләрнең дә борынгы Болгар чоры белән бәйле тарихы булуына ышандыралар.

Шушындый ук сүзләрне пермь татарлары турында да әйтеп булыр иде. Бу группа XVI—XVII йөздә Казан артыннан күченеп китә, диелә әлеге китапта. Безнеңчә, пермь татарлары Югары Кама буенда шактый иртә формалашканнар. Пермь татарларының борынгы төрки нигезен Болгар дәүләтен төзүче төрки кабиләләр дәвере белән бәйләү дөресрәк булыр төсле. Каманың югары агымында үткән йөздә һәм совет чорында археологлар тарафыннан табылган күп материаллар VII—VIII гасырларда ук инде бу җирләрдә төрки халыклар яшәгәндер диярга урын калдыра. Пермь һәм Киров өлкәләрендә табылган күп санлы көмеш савытлар («восточное серебро»), болгар ювелир әйберләре дә шуны раслый. Шунысын да әйтеп үтик, бу бүлектә кулланылган кайбер археологик мәгълүматлар бүгенгесе көнгә инде шактый искерделәр. Китапта археологик нигез итеп 1952 нче елга кадәр тупланган материал алынган. Мәсәлән, хәзерге Татарстан территориясендәге монголларга кадәрге чорга караган 38 болгар шәһәреннән бары тик өчесе генә Тау ягында урнашкан дип әйтелә (9 нчы бит). Бүгенгесе көнгә республикабызда табылган андый шәһәр калдыкларының саны 70 тән артты, ә Тау ягында алар 15. Монда шуны күрсәтеп үтү дә урынлы булыр. Китапның бу кимчелегенең объектив сәбәпләре дә бар, чөнки 1952 нче елдан бирле безнең Татарстанда археология буенча аерым хезмәтләр чыкканы юк.

«Кыскача историографик күзәтү» исемле бүлектә татар тарихын, бигрәк тә этнографиясен өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәр һәм аларның хезмәтләренә тукталынган. Татарлар турында язылган истәлекләрнең Болгар дәүләтенең беренче чорларыннан, ягъни Ибн-Фадланнар, Ибн-Рустәләр заманыннан алыкуы матур күренеш. Әмма Алтын Урда чорындагы аерым тарихи-географик язмалар телгә алынмаганнар. Соңгы дәвердә, бигрәк тә XIX йөздә татар тарихы һәм этнографиясе буенча фәнни хезмәтләр, рус һәм чит ил галимнәре белән беррәттән, татар галимнәре һәм мәгърифәтчеләренең исемнәре белән дә бәйле. Бу бүлекнең уңай якларыннан тагын шунысы бар — XIX йөз татар язучыларының, бишенче ел революциясе дулкыны белән күтәрелгән Тукайларыбыз, Әмирханнарыбыз, Галимҗаннарыбызның, Октябрь таңы тудырган башка аерым язучыларның әсәрләре халыкның этнографиясен сурәтләү ягыннан да кыйммәтле хәзинә булып саналалар, дип дөрес бәяләнгән. Ә менә совет чоры галимнәренең хезмәтләрен күрсәткәндә, татар тарихчыларыннан Х. Г. Гимади, М. Г. Сәфәргалиев, Ш. Ф. Мөхәммәдьяров исемнәре нигәдер онытылган. Этнографик әдәбиятны күзәтү белән бергә, бу бүлектә иң әһәмиятле этнографик чыганакларны да санап китү урынлы булыр иде. Экспедицияләр, этнографик мәгълүматлар җыйнауның системасы һәм методикасы турында берничә сүз әйтү чыганакларның фәннилек дәрәҗәсен тагын да арттырып җибәрер иде.

Китапның нигезен «Хуҗалык һәм материаль культура» дигән икенче кисәк тәшкил итә. Ул дүрт бүлектән тора: «Һөнәрчелек һәм кәсеп», «Авыллар һәм йорт төзелеше», «Киемнәр һәм бизәнү әйберләре», «Ашамлыклар». Н. И. Воробьев язган бу бүлекләр халыкның бай материаль дөньясы буенча кыйммәтле һәм кызыклы мәгълүматлар бирәләр. Бу мәгълүматлар галимнең 1953 нче елда чыккан «Казан татарлары» дигән китабындагы мәгълүматларга караганда күп бай. Сүз дә юктыр, борынгы болгар шәһәр культурасы традицияләрен үзендә нык саклаган казан татарларында утрак хуҗалыкның классик өч төре — иген игү, һөнәрчелек һәм сәүдә әүвәл-әүвәлдән төп кәсеп булып саналган. Авыл хуҗалыгын һәм һөнәрчелекне нечкәлекләренә кадәр дөрес чагылдырып бирү — китапның күркәм сыйфатларыннан берсе. Һәрбер терминны татарча бирергә омтылу бу сыйфатны тагын да бизи. Татарларда терлек асраучылык, бигрәк тә ат тәрбияләүгә булган мәхәббәт, сарык үрчетүдәге өстенлекләр, һөнәрчелек (туку, йон һәм күн эшкәртү, тире иләү, бау ишү, кап сугу, чана һәм тугым ясау, мичкә эшләү, сбруй ясау, бигрәк тә безнең халыкка гына хас булган атаклы каюлы читекләр һәм чигүле кәләпүш-калфаклар тегү һ. б. бик күп төрләр), ювелирлык осталыгы (өлге, нәкыш, чүкү юлы белән һәм алтын-көмеш җепне үреп бизәкләр эшләү) — болар бары да китапта шактый тулы яктыртылган.

Элегрәк чыккан кайбер этнографик хезмәтләрдә татарлар арасында балта осталары һәм мич чыгаручылар бик аз булган, аларга өйне һәм мичне күп очракта руслар салып бирә торган булганнар дигән ялгыш караш хөкем сөрә иде. Китапның уңышлы якларыннан тагын берсе шул — ул әлеге караштан бераз арынган. Татарларда өйләрнең һәм мичләрнең, гомумән йортның русларныкыннан аерылып торуы бик гыйбрәт-

ле. Шуны да өстәп китик, Казан арты авылларында безгә шундый нәрсәләр ишетергә туры килгәләде: әле революциягә кадәрге чорда ук татар авылларыннан аерым балта осталары бригадалары Мари һәм Вятка якларына чыгып, русларга йорт салып йөргәннәр. Мондый күренешләр әле дә очрый. Әмма бакчачылык һәм яшелчәчелек безнең халыкка хас түгел дигән искергән караш бу китапта да сакланган. Моның белән килешеп булмый. Күрше угро-фин халыкларының җимеш-яшелчә төрләрен татарча әйтүләре [мәсәлән, алма, чия, бакча, кавын, суган, кыяр] бу культураларның әлеге халыкларга татарлардан керүе турында сөйли[1].

Авыл һәм йорт төзелешен тасвирлауга багышланган бүлек тә бик кызыклы. Авылларның географик принципка нигезләнеп урнашуларыннан тыш, аларның эчке планлаштырылуында да аерым үзенчәлекләр бар. Йортны капка-койма белән әйләндереп алып, өйне ишек алдының эченәрәк салу, йорт тирәсенә һәм урамга биек агачлар утырту, еракtан кечкенә урманнарны хәтерләтүче зиратлар — болар һәммәсе Болгар дәвереннән килә торган традицияләр. Казан ханлыгы чорының фундаменталь архитектурасы, мәгълүм тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә, безнең көннәргә кадәр сакланмаса да, шәһәр архитектура стиле авыл архитектурасында үзенең чагылышын тапкан. Татар өйләренең крайдагы башка халыкларныкыннан аерымлыгы аларның биек һәм яктылыгында, җир идәннәрнең булмавында һәм өйләрнең поликрамиягә хас булуында күренә. Поликрамия — ул төрле төсләрне чиратлаштырып буяу, аның үзенең законочалыклары да бар. Безнең халык бигрәк тә ак, лимон сары, зәңгәр һәм яшел төсләр сайлауга хирес булган. Борынгы монументаль архитектура стиленең тагын бер сакланып калган өлеше — чорма тәрәзәсен бизи торган балкыш. Бу балкыш зуррак йортларда тагын да катлауланып, балкон формасында колонналар белән бизәкләнеп эшләнә. Аның «парчалы кыек» исемле атамасы булса да, әлеге китапта татарча исеме күрсәтелми калган. Китапта өйнең тышкы һәм эчке эшләнеше, гомумән йорт төзелеше шактый җентекләп сурәтләнгән. Бу бүлектә техник хата киткән. Балтач районы остасы Г. Фәхретдиновның йорты Мамадыш районы Тәкәнеш авылындагы йорт дип аталган [115 нче бит].

Әйтеп үткәнебезчә, китапка нигез итеп казан татарларының материаль һәм рухи культурасы алынган. Әмма мишәрләрнең һәм башка группаларның көнкүрешенә караган аерым күренешләрне чагыштырып күрсәтү — куелган мәсьәләне чишүнең отышлы ягы. Китапта бер татар этнографиясе генә түгел, ә әйләнәбездәге башка төрки һәм угро-фин халыкларының культурасы да өлешчә яктыртылган. Мондый чагыштыру методы бигрәк тә кием-салым һәм бизәнү әйберләренә багышланган бүлектә уңышлы кулланылган. Әмма мондый чагыштырма фон башка бүлекләрдә җитәрлек түгел. Кием-салым һәм аш-су турында язган бүлекләрне дә укучы кызыксынып укыр. Без кайбер тәкъдимнәр генә әйтеп үтәргә телибез. Бу бүлекләрдә фотографияләрнең азлыгы үзен сиздерә. Башка халыклар этнографиясеннән чагыштыру китерелсә дә, тарихи фон җитеп бетми. Мәсәлән, аяк киемнәре, бигрәк тә читекләр турында сөйләгәндә Болгар чорына күз салу комачауламас иде. Ә ул чордан калган язма истәлекләр дә безгә мәгълүм ич. Әйтик, 985 нче елда русларның болгарларга һөҗүме вакытында әсир ителгән болгарларның чабаталы түгел, ә күн итекле булганнарын нигә әйтеп китмәскә!! Аерым бизәнү әйберләрен тасвирлаганда да тарихка мөрәҗәгать итәргә кирәк иде. Казан татарларының әлегә кадәр сакланган беләзек, йөзек, хәситәләре болгарларда үзләренең археологик чагылышын таба ич. Материаль культурага багышланган бүлекләрнең тагын бер күңелгә охшаган ягы шул, татарларның тормыш-көнкүрешенә аеруча хас булган чисталык объектив күрсәтеп үтелгән.

Китапның «Иҗтимагый һәм гаилә-туганлык мөнәсәбәтләре» дип аталган өченче кисәге, дөресен әйткәндә, совет тарих фәнендә беренче буларак, татарлар арасындагы андый мөнәсәбәтне ачыклап бирә. Бай фактик материалга нигезләнеп, Г. М. Хисаметдинов революциягә кадәрге чорда татар халкында иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең фор-

---

[1] Ш. Ф. Мухамедьяров. К истории земледелия в Среднем Поволжье в XV—XVI веках. «Материалы по истории сельского хозяйства и крестьянства СССР». М. 1959. 121 нче бит.

малашу процессын исбатлый[1]. Авторның феодаль мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеге хакында, «чура» исеме белән билгеле булган бәйле кешеләр турындагы фикерләре кызыклы. Г. М. Хисаметдинов фикеренчә, «чура» ул чын мәгънәсендә кол түгел, ягъни ул коллыкның классик формасын чагылдырмый. Чура — ул үзенә җир бүлеп бирелгән кол яки хәрби әсир. «Чура»ның Идел буе халыклары авыз иҗатында чагылышы да кызык. Мәсәлән, шүрәле, арчури...

Татарларның күп кенә группаларына хас булган җыеннар, халкыбызның иҗтимагый мөнәсәбәтен өйрәнгәндә, һичшиксез, зур кызыксыну уяталар. Җыеннарның характерын һәм таралышын җентекләп өйрәнү авторга шактый гына әһәмиятле фикерләр әйтергә мөмкинлек биргән. Мәсәлән, җыеннарның Болгар дәвереннән генә түгел, хәтта тагын да элегрәк — ыруглык чорыннан ук килә торган күренеш булуы, аларның бигрәк тә төрки халыкларга хас икәнлеге ышандырырлык итеп күрсәтелгән. Тагын шунысы кызыклы, җыеннар алар игенчелек белән шөгыльләнүче утрак халыкка хас (мәсәлән, Казан артына). Җыеннар мәсьәләсе бик мөһим. Киләчәктә аларны тагын да тирәнрәк тикшерү, аерым авыллар һәм гаиләләрнең нәсел-нәсәбәсен күрсәтүче шәҗәрәләр белән әлеге җыеннарны чагыштырып, һәр икесенең исемнәре һәм территорияләре туры килү-килмәүне ачыклау бик тә мавыктыргыч мәгълүматлар бирер иде. Сүз уңаеннан әйткәндә, шәҗәрәләр турында китапта нигәдер ләм-мим берни юк.

«Гаилә-туганлык мөнәсәбәтләре» дигән бүлек шулай ук яхшы тәэсир уята; авторлары Ә. Г. Заһидуллин һәм Р. Г. Мөхәммәдова. Биредә туй йолалары җитәрлек дәрәҗәдә ачык һәм колоритлы күрсәтелгән. Революциягә кадәрге чорда татар хатынының кимсетелгән булуы һәм гаиләдәге тәрбия мәсьәләләренең торышы да тиешле урын алган. Әлеге бүлекнең ахырында гаҗәп бай таблица бирелгән. Таблицада туганлык терминнарының тулы җыелмасы тупланган. Р. Г. Мөхәммәдова төзегән бу номенклатура да әдәбиятта беренче тапкыр бирелә. Әлеге бүлектә җитәрлек дәрәҗәдә җентекләп тасвирланган туй йолалары аларның казан татарларындагы һәм мишәрләрдәге аермасын аңларга ярдәм итә. Авторлар объектив күрсәтеп үткәнчә, бу аерма төрле культура-экономика шартлар җирлегендә туган күренеш. Шулай да бу фикер тулысынча ачылып җитмәгән, чөнки аның өчен теге яки бу группага кагылышлы параллельләр җитәрлек түгел.

Халык бәйрәмнәренә багышлап язылган бүлек, тулаем алганда, сабан туйларын сурәтли. Әгәр дә XIX йөзнең кайбер тарихчылары сабан туен монголлардан калган бәйрәм дип санасалар, Р. Г. Кашафетдинов сабан туен утрак тормыш белән бәйле борынгы бәйрәм дип хисаплый. Татарларның төрле группаларына хас булган сабан туе бәйрәмен башка күрше халыклардагы бәйрәмнәр белән чагыштырып карау сабан туеның мәҗүсилек заманыннан ук килүче һәм авыл хуҗалыгы эшләре белән бәйле бер йола икәнлегенә шик калдырмый. Сабан туйларындагы төрле уеннар һәм ярышлар борынгы ике культураның бергә кушылу нәтиҗәсе, ди автор. Беренчедән, төньякка хас игенчелек һәм аучылык культурасы, ә икенчедән, дала, ягъни күчмә халыклар культурасы.

Рухи культурага багышланган кисәкне Г. М. Хисаметдинов һәм Һ. В. Юсупов язганнар. Татарлардагы традицион рухи культураның күп яклары, мәсәлән, астрономик карашлар, халык календаре, һава хәлләре һәм метереология буенча халык тәҗрибәсе, халык медицинасы бәйнә-бәйнә сөйләнеп, башка халыклардан параллельләр китереп, мавыктыргыч тасвирланган.

Дингә, мифларга ышанулар һәм аларның бүгенге көнгә чаклы сакланулары, мәсәлән, мәҗүсилек заманыннан ук калган кот, өрәк, борынгылар культы, хайваннарга, агачка, җиргә, утка һәм кояшка табынулар, һәртөрле табигатьтән тыш көчләргә ышанулар, күрәзәлек итүләр — болар бары да киң тарихи-чагыштыру методы кулланып, фәндә беренче тапкыр ачыкланганнар. Халкыбызның этногенезына искиткеч материал бирүче бу бүлек китапның иң кызыклы бүлекләреннән берсе.

«Мәгърифәтчелек һәм культура» исемле бүлек (Г. М. Хисаметдинов) татар халкы культура мирасының ерак гасырларга сузылган тарихын ачыклап бирә. X йөздә үк

---

[1] Китапның «Иҗтимагый мөнәсәбәтләр», «Халык белемнәре», «Мәгърифәтчелек һәм культура» дигән бүлекләрен язудан башка, Г. М. Хисаметдинов редакторлык эше дә башкарды. Н. И. Воробьевның озакка сузылган авыруы һәм үлеп китүе аркасында, әлеге китапны редакцияләүнең күп өлеше Г. М. Хисаметдинов өстенә төште.

инде болгарларның гарәпчә әлифба кабул итүләре һәм ул замандагы алдынгы илләр белән бәйләнешкә керүләре җирле культураның тиз арада нык үсеш алуына этәргеч булган. Монголларга кадәрге чорда ук инде Болгар илендә астрономия, медицина, тарих, фәлсәфә, хокук, әдәбият белеме фәннәренең тууы, XIII—XVI йөздән калган гүзәл шигърият ядкарьләре — болар барысы да татар культурасының тирәннән үсеп чыгуын күрсәтүче матур-матур дәлилләрдер. Казанны басып алу һәм татарларны чукындыру вакытында күп кенә мәктәп-мәдрәсәләр юкка чыгарылсалар да, халык мәгарифе яшәүдән туктамаган. Соңга табарак, татар руханиларын үз ягына аудару максаты белән, патша хөкүмәте мәчет-мәдрәсәләр корырга указ чыгаргач, аларда укытылган дин сабагыннан тыш дөньяви белем бирү дә азмы-күпме арта барган. Прогрессив рус галимнәре йогынтысында татарларның үз араларыннан да укымышлылар үсеп чыкканнар. Әмма патша хөкүмәтенең татарларны руслаштыру политикасы аркасында, татар культурасының җанлануы әллә ни нык үсеп китә алмаган.

Бу бүлектә шулай ук XIX йөзнең икенче яртысында шактый алга киткән мәдрәсәләр һәм алардагы реформалар хакында да шактый күп әйтелгән. Әмма җәдитчелек турында сөйләгәндә, аңа бирелгән характеристиканы әле тулысынча ачыкланып беткән дип санап булмый. Бүлектә шулай ук XX йөз башындагы татар мәктәпләре буенча кызыклы статистика китерелә. Әйтик, 1912 нче елда Казан губернасында 1088 мәктәп һәм мәдрәсә булып, аларда барлыгы 83 мең кеше укыган. Губернадагы һәрбер мең татарга уртача 1,21 мәктәп һәм 55 укучы туры килсә, шул ук сандагы русларга 0,88 мәктәп һәм 40 укучы туры килгән.

Бүлекнең уңай ягы тагын шунда, татарлар арасында укый-яза белү турында сөйләгәндә, грамоталылыкны нәрсәдән чыгып билгеләүне ачыклауга омтылыш бар. Элегрәк татарларның грамоталылыгын русча укый-яза белүгә карап бәягәннәр, һәм күп кенә статистик мәгълүматлар да шуннан чыгып төзелгән. Әлеге китапта исә укый-яза белүне үз телендә укый-яза белү итеп карарга кирәклек турында әйтелә. Безнеңчә, бу фикер ачыклауга мохтаҗ түгелдер, чөнки дөньядагы һәрбер халыкның грамоталылыгы турында хөкем йөрткәндә, аның чит телдә түгел, ә үз телендә укый-яза белүе турында сөйлиләр. В. И. Ленин Россиядәге мөселман халыклары культурасы турында сүз алып барганда, шундый бер чагыштыру китерә: казан татарларыннан 150 кешегә 1 мәчет һәм 1 мулла туры килсә, руслардан һәм башка халыклардан 1500 кешегә бер рухани тия. Татарларда 100 кешегә, ә христиан динендәгеләргә 1500—3000 кешегә 1 мәктәп туры килә (405 нче бит). Тагын шуны искәтеп үтик, грамоталылык турында сөйләгәндә без гомумән мәгълүматлылыкны түгел, ә укый-яза белүне күз алдында тотабыз.

Фольклор турындагы бүлек тә кызыклы язылган. Үзенең азатлыкка булган хыялын һәм омтылышларын, борын-борыннан килгән йола һәм гореф-гадәтләрен, ырулык һәм феодаль җәмгыятеннән калган дини ышануларын халык үзенең бай шигъриятендә гаҗәп оста чагылдырган. Әлеге бүлектә туй җырларына, мәкаль-әйтемнәргә, табышмакларга һәм әкиятләргә анализ бирелгән. Эпик жанрның бер төре булган бәетләр бик матур тасвирланган. Бәетләрдә Россия халыкларының туганлыгы, хезмәт ияләренең авыр тормышы, аларның якты киләчәк өчен көрәше, бу көрәштә җанын биргән фидан шәхесләр турында җырлана. Х. Х. Ярми һәм Ф. И. Урманчеев язган бу бүлек халкыбыз үткән озын һәм катлаулы юлны, төрле тарихи периодларда булып үткән вакыйгаларны күрсәтү ягыннан әһәмиятле. Кызганычка каршы, бу бүлектә татарларның аерым группаларының авыз иҗатына характеристика бирелмәгән. Татар фольклорының үзенчәлеге, аның башка төрки халыклар белән якынлыгы һәм үзгәлеге турында да бер сүз әйтелми. Мәсьәләгә тарихи аспекттан чыгып якын килү җитеп бетмәгән.

Ә менә халык музыкасына һәм сынлы сәнгатькә багышланган бүлекләр турында моны әйтеп булмый. Тарихилык биредә үз урынында. Гаҗәп кызыклы һәм күп кырлы фактик материалга нигезләнеп язылган бу бүлекләр халык иҗатының тирән тамырларын гасырлар әзлеклелегендә дөрес чагылдырганнар. М. Н. Нигъмәтҗанов һәм Ф. Х. Вәлиев язган бу хезмәтләр культураның чыганагы һәм үсеш юллары турында гына түгел, ә татар халкының этник психикасын ачып бирүе белән дә бик кыйммәтле.

Шушы кечкенә генә рецензиядә китапта күтәрелгән барлык мәсьәләләргә тукталу мөмкин түгел. Алар белән укучы үзе якыннан танышыр дип ышанабыз.

Билгеле, уңышлар белән бергә, әле хезмәттә гомуми характердагы кайбер җитешсезлекләр дә бар. Без инде баштарак китапка нигез итеп традицион этнографияне ачыклау алынганлыгын әйтеп узган идек. Шулай булса да, хәзерге тормышта булган аерым үзгәрешләргә тукталып киту зыян итмәгән булыр иде. Китапның исеме дә шуңа әйди бит. Китапта этногенезга кагылышлы мәсьәләләрнең барлык бүлекләрдә чагылмавы шулай ук җитешсезлек санала. Иллюстрацияләрнең аз булуы үзен шактый сиздерә. Төсле рәсемнәр бөтенләй юк. Ә бит һәркемгә мәгълүм, этнографик хезмәтләрдә рәсемнәр текстлар белән бер дәрәҗәдә әһәмиятле. Кайвакытта никадәр күп сибелгән матур сүзләр дә татар милли орнаментын, андагы ачык колоритны, бизәкләр һәм төсләр гармониясен, алардагы шигърияттне алыштыра алмый.

Шундый кайбер кимчелекләр булуга карамастан, «Урта Идел һәм Урал буе татарлары»ның дөньяга чыгуын Татарстанның гыйльми һәм культура тормышында гына түгел, күп милләтле Идел буенда да зур һәм шатлыклы вакыйга итеп бәяләргә кирәк. Фәнни әйләнешкә кертелгән яңа һәм зур материал этнографларга, археологларга, телчеләргә, тарихчыларга һ. б. галимнәргә халкыбызның килеп чыгышының катлаулы проблемаларын чишәргә ярдәм итәр. Китап шулай ук киң катлау укучылар тарафыннан да яратылып укылыр дибез. Бик кыйммәтле китап. Аның белән танышкач, һәртөрле изүләргә дә карамастан үзенең бай культурасын саклап калган халык талантының бөеклегенә башыңны иясең.

Инде килеп, теләк формасында шуны әйтәсе килә. Китап татарчага тәрҗемә ителсен иде. Юкса, «Наука» нәшриятында 6300 данә белән чыгарылган бу русча вариантны бөтен Россия киңлекләре буенча күптән таралып бетте инде. Татарчасын чыгарганда авторлар, бәлки, югарыда күрсәтеп үтелгән кимчелекләрне дә искә алырлар иде. Бу — озакка сузмыйча башкарыла торган эш, безнеңчә. Галимнәребез дә, нәшриятыбыз да Казанда бит. Татарстанның илле еллыгына багышлап шул эш эшләнсә, социалистик культура төзүче татар халкына бер зур бүләк булыр иде. Халык хәзинәсен җыйнап бирүдә тырышлыклары өчен, халкыбыз бу эшне башкаручыларга тагын бер тапкыр олы рәхмәтен укыр иде.

Ахыргы сүз. Анысы белән язучыларыбызга мөрәҗәгать итәсе килә. Әдәбият дөньясында халыкның этнографиясен чагылдыруда гүзәл үрнәкләр биргән әсәрләр байтак. Андыйлар татар әдәбиятында да юк түгел. А. Акъегет, Р. Фәхретдинов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Камал, М. Фәйзи, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, К. Тинчурин әсәрләре моңа бик яхшы мисал. Соңга табарак язылган кайбер роман-повестьларда да халкыбызның традицион этнографиясен тасвирлау зур осталык белән эшләнде. Моны бигрәк тә Ә. Фәйзинең «Тукай» романына һәм Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестена карата әйтәсе килә. Фольклорчы һәм олы язучыбыз Гомәр ага Бәшировның әлеге автобиографик повесте, әдәби әсәр булу белән беррәттән, кыйммәтле этнографик чыганак та. Әдәбиятыбызның аксакалы һәм горурлыгы, ифрат дәрәҗәдә киң мәгълүматлы галимебез Нәкый ага Исәнбәтнең тарихи драмалары, аның әдәбият һәм культура тарихына карата язган гаять эчтәлекле мәкаләләре — болар чын мәгънәсендә культура мирасыбызның алтын фондын тутыручылар. Башка бер әйбер дә язмыйча, «Татар халык мәкальләрен» чыгару белән генә канәгатьләнсә дә, Н. Исәнбәт халкыбызның культура тарихында мәңге сүнмәс йолдыз булып калыр иде. «Татар халык мәкальләре» кебек әсәрләр бер безнең илдә генә түгел, ә бөтен дөнья әдәбиятында сирәк очрыйлар. Андый хезмәтләр мәңгелек, аларны гасырлар да күмеп кала алмый.

Ләкин менә шундый киң диапазонлылык Н. Исәнбәт, Г. Бәширов һәм башка берничә исем белән генә чикләнә кебек. Олыларга алмашка килүче яшь язучылар иҗатында бу эстафетаны дәвам иттерү әлегә күренми кебек. Әби-бабайлар, олылар исән чакта традицион этнография белән, халык иҗаты белән кызыксыну, шуларны матур итеп хикәя-повестьларда чагылдыру, татар халкының героик үткән юлын сурәтләүче тарихи роман һәм драма жанрларына игътибар арттыру әдәбиятыбызны нык баетыр һәм дәрәҗәсен тагын да күтәрер иде. Мондый эш бер бүгенге көн укучылары өчен генә түгел, ә күп санлы киләчәк буын өчен дә зур мирас булып калыр иде. Тарих битләрен актарганда аларга ярдәм итәрлек фән кешеләре дә юк түгел хәзер.

# РӘХМӘТЛӘР ЮЛЛЫЙМ

«Урта Идел һәм Урал буе татарлары» исемле монографияне дөньяга чыгарган иптәшләргә ихлас күңелемнән рәхмәтемне белдерәм. Халкыбыз тарихына караган мондый зур хезмәтне татар укучылары күптәннән зарыгып көтәләр иде. Уфа китап кибетләрендә бу китап күз ачып йомганчы диярлек сатылып бетте. Мин үзем, профессиям буенча гади бер инженер, халкыбыз тарихы белән күптәннән кызыксынам. Бу китап миндә көтелмәгән яхшы тәэсир калдырды. Моңа кадәр татар тарихына караган бүтән хезмәтләрдән аермалы буларак, мәгълүматларга байлыгы, халыкның үткәненә хөрмәт хисе белән сугарылган булуы белән бу монография мине үзенә гашыйк итте.

СССРның бөтен почмакларында һәм киңлекләрендә татар халкы вәкилләре яши. Дөресен әйткәндә, шушы көнгә тикле төрле өлкәләргә чәчелеп урнашкан бу зур бер халыкның килеп чыгышына һәм культура тарихына карата чын мәгънәсендәге объективлык җитми иде. Күп кенә тарихчыларның хезмәтләрендә һәм мәктәп дәреслекләрендә безнең тарихыбыз, бернинди нигезсез, монгол яулары белән бәйле рәвештә генә яктыртыла килә иде, ә безнең төп бабаларыбыз — Идел буе болгарларының данлы тарихы, ничектер, читләтеп үтелә иде. Хәлбуки, безнең халык XX гасыр башына кадәр үзен татар дип санамаган да. Бу факт үзе генә дә күпне аңлата кебек. Төрле гыйльми һәм әдәби китапларда монголларның — «монгол», «монгол-татарлар», «татарлар» дип йөртелүләре тарих буенча мәгълүматы аз булган кешеләрдә аңсыз рәвештә бутау тудыра, шуңа да күпләрнең һаман да хәзерге татарларга монголлар тарихы аша каравы дәвам ителеп килә иде. «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» дигән хезмәттә терминнарның мондый системасызлыгы бетерелгән, халкыбызның соңрак чорларда үткән юлы — Идел буе болгарлары тарихының дәвамы икәнлеге эзлекле рәвештә дәлилләп күрсәтелгән. Тарихыбызга бик тә кирәк мондый ачыклыкны ассызыклап күрсәтү — монографиянең иң отышлы ягы, минемчә.

Без хезмәттәш иптәшләребез белән бу китапны кат-кат укыдык, аерым бүлекләре буенча дулкынлана-дулкынлана әңгәмәләштек. Безгә сөенеч алып килгән, халкыбыз тарихын дөрес яктырткан бу кыйммәтле хезмәтне язган галимнәргә тагын бер мәртәбә рәхмәтемне юллыйм һәм аларга яңа уңышлар телим.

ЯКУПОВ Р. С.

Уфа.

# ПЕДАГОГНЫҢ ЯКТЫ ЯЗМЫШЫ

*(Яковлевның туууына 120 ел)*

Тугандаш Татарстан республикасы чуваш халкына да күп кенә әдипләр, культура һәм җәмәгать эшлеклеләре бирде. Татарстан җирендә туып үскән Педер Хузангай, Василий Краснов (Аслы), Тихон Педеркки, РСФСР язучылары Союзы секретаре Александр Алга, Чувашстан язучылары союзы идарәсе председателе, филология фәннәре кандидаты Николай Дедушкин һ. б. ларның исемнәрен дә, иҗади-иҗтимагый эшчәнлекләрен дә чуваш халкы гына түгел, республикабыздан читтә дә яхшы беләләр.

Олы педагог, зур җәмәгать эшлеклесе, Идел буе халыкларының күренекле мәгърифәтчесе Иван Яковлевич Яковлев та моннан 120 ел элек, 1848 елның апрелендә, Татарстан җирендә, Тәтеш районының Яңа Тимбай авылында туа. Туганнан соң өч көн үткәч тә, ул әтисез дә, әнисез дә кала. Аны чуваш крестьяннары тәрбияләп үстерәләр. Башта авыл мәктәбендә башлангыч белем ала, аннары, землемерлар училищесын бетереп, землемер булып шул якларда эшли. Белемгә сусавы зур була аның һәм Сембер шәһәрендәге классик гимназиягә укырга керә. 1875 елда гимназияне алтын медаль белән бетереп, Казан университетында укуын дәвам итә.

И. Яковлев гимназиядә укыган вакытында ук крестьян балаларыннан укытучылар әзерләү өчен беренче мәктәп-интернат ача.

1869 елда И. Н. Ульянов Сембер шәһәрендә халык мәктәпләре инспекторы итеп билгеләнә. һәм ул И. Я. Яковлевка бу мәктәпне үстерүдә бик күп ярдәм күрсәтә. Соңыннан шушы мәктәптә укып чыккан Н. М. Охотниковка һәм икенче бер чуваш егете В. Н. Никифоровка гимназист Владимир Ульянов университетка әзерләнергә ярдәм итә.

И. Я. Яковлев университетта укыган елларында чувашлар өчен беренче әлифба төзи. 1872 елда басылып чыккан бу әлифбага беренче уңай бәяне И. Н. Ульянов бирә.

Университетны тәмамлаганнан соң, И. Я. Яковлев Казан уку-укыту округының чуваш мәктәпләре буенча инспекторы итеп билгеләнә һәм 1903 елга кадәр шул хезмәтендә эшли. Ә 1903 елны «политик яктан ышанычсыз кеше» дигән сылтау белән хезмәттән куыла.

Чуваш халык мәгарифенең беренче житәкчесе буларак, И. Я. Яковлев Чувашстанның хәзерге территориясе авылларында гына да 400 дән артык башлангыч һәм ике класслы мәктәпләр оештыра.

Чуваш халкының милли аңы үсешендә И. Я. Яковлевның роле гаять зур. Сембердәге ул җитәкләгән мәктәптә беренче чуваш композиторлары, шагыйрьләре, прозаиклары, артистлары, художниклары, галимнәре житешә. А. В. Луначарский Яковлев мәктәбенә: «...барлык чуваш культурасының яңарыш чыганагы», — дип бәя бирә. Бу мәктәптә М. Глинканың «Иван Сусанин» операсы куела, халык җырларының беренче антологиясе һәм ике томы чыга, педагогик музей һәм картиналар галереясы оеша. Мәктәпнең авыл хуҗалыгы фермасы чуваш крестьяннары арасында алдынгы методларны тарату өчен агробаза итеп үзгәртелә.

И. Я. Яковлевның педагогик теориясендә халыкчанлык идеяләре беренче планда тора. Халыкчанлык төшенчәсе астында ул хезмәт халкы интересларына тәңгәл килә торган тәрбия, туган телне яклау, культура һәм милли аңның үсеше мәсьәләләрен күз алдында тота.

И. Я. Яковлев үзенең мәктәбендә һәр яктан житлеккән, үз халкына тирәнтен бирелгән патриот-гражданин тәрбияләп чыгаруны бурыч итеп куя. Аныңча, мәктәп — халыкка йогынты ясауның беренче адымы. Укытуның эчтәлеге халык интересларына буйсындырылган булырга, дөрес тәрбия бирүнең нигезендә хезмәт ятарга тиеш. 1919 елда В. И. Ленинга язган хатында ул болай ди: «Мин мәктәп эшчәнлегенең нигезенә акыл һәм физик хезмәтне салырга, аны башлыча демократик хезмәт йортына әверелдерергә дигән ныклы карарга килдем. Тәрбия эше хезмәткә нигезләнгән».

И. Яковлевның педагогик өйрәтүләре үзләренең гуманизмы һәм демократизмы белән аерылып тора. «Тәрбиянең максаты — кешенең бәхете, тәрбия ысулы — шатлык», — дип яза ул.

Ялкынлы педагог рус хөкүмәтенең руслаштыру политикасын бик кыю фаш итә. Балаларның үз туган телләрендә белем алу хокукларын яклап чыга. «Бары тик туган тел ярдәмендә генә, — ди ул, — иске төшенчәләргә яңа элементлар кертергә мөмкин».

И. Я. Яковлев халыклар дуслыгы идеяләрен кайнар рәвештә яклап чыга, ул поляк халкының милли-азатлык хәрәкәтенә теләктәшлек белдерә, чувашлар арасында Украина поэзиясен һәм музыкасын пропагандалый, үзенең укучыларын рус булмаган милләт халыкларына мәгърифәт хезмәте күрсәтергә өнди, үзенең мәктәбендә татар, мордва крестьяннары балаларыннан да укытучылар әзерли, якут, алтай һ. б. халыкларның культурасын, көнкүрешен өйрәнә, Андерсен әкиятләрен тәрҗемә итә.

Чуваш халкы И. Я. Яковлевка гаять зур хөрмәт белән карый. Бу табигый дә: ул үз халкына бөтен барлыгы белән бирелгән чын патриот иде. Менә шуңа күрә дә халык арасында аны «нәсел-нәсәбен онытмас Иван» дип йөрттәннәр. Бу сүзләрне, дөрес булса, аңа карата иң беренче башлап И. Н. Ульянов әйткән дип сөйлиләр. Бер дә гаҗәп түгел, шулай булуы да мөмкин. Илья Николаевич Сембердә эшли башлаган елларында ук аның турында болай дип язган: «Талантлы чуваш Иван Яковлевич Яковлев — бирелгән кеше, Буаныкы... — чуваш әлифбасы булдыру өстендә эшли»...

В. И. Ленин да И. Я. Яковлев эшчәнлегенә зур бәя бирә. «Чуваш милләтен күтәрү юнәлешендә илле ел эшләгән һәм царизмның күп кенә эзәрлекләүләренә дучар булган», — дип яза Владимир Ильич аның турында (Әсәрләр. 50 том, 61 бит). Икенче бервакыт В. И. Ленин аңа карата: «Бу кешенең рухы баһадирларча иде. Илле ел буе ул үз халкын яктылыкка әйдәде һәм нинди шартларда әле!», — дип соклану белдерә. («Литература и жизнь», 1958 ел, № 43).

В. И. Ленин Яковлевка карата зур кайгыртучанлык күрсәтә. Карт педагогны квартирасыннан чыгармаска дип, телеграф белән күрсәтмә бирә һәм аңа нарком паёгы бирел торырга әйтеп телеграмма җибәрә.

Ялкынлы педагог һәм җәмәгать эшлеклесе И. Я. Яковлев исеме чуваш халкы өчен генә түгел, илебезнең барлык тугандаш халыклары өчен дә якын һәм кадерле.

**Г. ВОЛКОВ**, доцент,
И. Я. Яковлев исемендәге чуваш педагогия институты проректоры.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЧЕХОСЛОВАКИЯ КУЛЬТУРАСЫ КӨННӘРЕ

Июнь башларында Казан халкының игътибар үзәгендә Чехословакия культурасы көннәре булды. Ул 31 майда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында ачылды.

Казанга дөньяга танылган Прага оркестры, Ян Озабала җитәкчелегендәге атаклы Братислава курчак театры, Густав Бром җитәкчелегендә популяр эстрада оркестры килде. Казанлылар Гелена Блегарова, Милан Герногоус, Алена Гавличкова һәм Антонин Бартош чыгышларын яратып карадылар. Милан Бауэр һәм Михаил Карин тамашачыларны кызыклы соната кичәләре белән таныштырдылар.

Шул көннәрдә Казанда Чехословакия фильмнары фестивале башланды. Шәһәрнең китап кибетләрендә Чехословакия китаплары күргәзмәләре, Татарстан дәүләт музеенда Чехословакия турында фото-күргәзмә, ә нәфис сәнгать музеенда Словакиянең художество промыселлары күргәзмәсе ачылды.

Кунаклар Казан дәүләт консерваториясенең актлар залында, В. И. Качалов исемендәге Зур драма театрында, Спорт сараенда, Офицерлар йортында, Ленин исемендәге, Урицкий исемендәге культура сарайларында һ. б. урыннарда чыгышлар ясадылар.

Мәскәүдә, Волгоградта, Горькийда һәм Казанда үткәрелгән Чехословакия культурасы көннәре ике ил арасындагы дуслыкның ныгуына зур өлеш кертәләр.

## БАТЫРГА ҺӘЙКӘЛ

Татарстанда легендар шагыйрь Муса Җәлил исемен йөрткән шәһәр бар. Күптән түгел генә шәһәр халкы Муса Җәлилгә куелган һәйкәлне ачу тантанасында катнашты. Шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал шагыйрьнең һәйкәле янында шигырьләр укыдылар, шәһәр халкы, пионерлар чәчәкләр салдылар.

## ЛАЕКЛЫ БҮЛӘК

Татар әдәбияты фәнен үстерүдә һәм фәнни кадрлар хәзерләүгә куйган зур хезмәтләрен искә алып, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы мөдире профессор Хатип ага Госманга Т а т а р с т а н н ы ң а т к а з а н г а н ф ә н э ш л е к л е с е дигән мактаулы исем бирде.

Аңа каләмдәш дуслары, журнал редакциясе һәм күп санлы авторлар, бу зур шатлыкны уртаклашып, тагын да зур уңышлар теләләр.

## ОЧРАШУЛАР

Бөек рус шагыйре А. С. Пушкин истәлегенә багышлап поэзия көне үткәрү иләбезнең матур бер традициясенә әйләнде. Быел Бөтенсоюз поэзия көнендә Татарстан язучылары исеменнән шагыйрь Нәби Дәүли катнашты. Ул Михайловское авылында, Ленинградның культура сараенда, Псков театрында, Остров шәһәрендә, Мәскәүнең Чайковский залында чыгышлар ясады.

Нәби Дәүли сәяхәткә чыкканда үзе белән Татарстан туфрагын алып барган иде. Ул аны Пушкин каберенә салган һәм кайтканда аның кабереннән дә бер уч туфрак алып кайткан.

14 июньдә әдипләр Тукай каберенә килделәр. Бу ике бөек шагыйрьнең кабер туфракларын бер-берсенә куштылар. Шагыйрьләр Пушкинга, Тукайга, халыклар дуслыгына багышланган шигырьләрен укыдылар.

* * *

Башкортстан язучылар союзының VI нчы съездында катнашу өчен Уфага язучылардан Хәсән Туфан, Гариф Гобәй, Ләбибә Ихсанова һәм Журналистлар союзыннан Асия Гыйниятуллиналар бардылар. Съездда Хәсән Туфан котлау речь белән чыкты.

* * *

Татарстанның Лениногорск районында татар әдәбияты атналыгы булып үтте. Шагыйрьләрдән Зәки Нури, Гамил Афзал, Равил Фәйзуллин, Мәрзия Фәйзуллина, прозаиклардан Аяз Гыйләҗев, Атилла Расих һәм Туфан Миңнуллиннар күп санлы нефтьчеләр, колхозчылар, укучы балалар белән очраштылар.

* * *

Татар әдәбияты атналыгы Киров өлкәсенең Малмыж районында да булды. Язучылардан Габдрахман Минский, Фатих Хөсни, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Мостафа Ногман, Самат Шакирлар тугандаш өлкә хезмәт ияләрен татар әдәбиятындагы яңалыклар белән таныштырдылар, үз әсәрләрен укыдылар.

* * *

Тәтеш һәм Буа районнарында күренекле чуваш халык педагогы һәм мәгърифәтчесе, Ульяновлар семьясының якын дусты Иван

Яковлевич Яковлевның тууына 120 ел тулуга багышланган әдәбият һәм сәнгать атналыгы булды.

Атналык Тәтеш педагогия училищесында зур әдәби-музыкаль кичә белән ачылды. Кичәне кыскача кереш сүз белән КПССның район комитеты секретаре Х. Җәгъфәров ачты. Чувашстан язучылар союзы идарәсе председателе, филология фәннәре кандидаты Н. С. Дедушкин бүгенге чуваш әдәбияты һәм сәнгате турында сөйләде.

Атналыкта чуваш язучыларыннан Александр Алга, Петр Петеркки, Василий Краснов (Аслы), Владимир Ухли, Александр Калган, Георгий Ефимов, Василий Давыдов, Иоким Максимов-Кошкинский, филология галимнәре һәм сәнгать осталары чыгышлар ясадылар.

Бу очрашуларга Татарстан язучыларыннан Малик Хәмитов һәм Хәсән Сарьян катнашты.

* * *

Башкортстан республикасының Чакмагыш районында шул районда туып үскән күренекле кешеләр белән очрашулар уздырылды. Анда әдипләр, сәнгать эшлеклеләре, фән белгечләре, дәүләт эшлеклеләре, революция ветераннары, Советлар Союзы геройлары, Социалистик Хезмәт геройлары һ. б. күренекле кешеләр катнашты. Чакмагыш районында туган татар шагыйре Галимҗан Латыйп һәм Ф. Мансуров әнә шул тантанада катнаштылар.

* * *

Узган елдан бирле Татарстан язучылар союзы каршында әдәбиятны пропагандалау бюросы эшләп килә. Татарстан язучылары һәм сәнгать осталары, татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге яналыклар, аның үсеш традицияләре белән таныштырып бару бурычын үз өстенә алган бу бюро республикабызның төрле шәһәрләрендә, авылларында, промышленность предприятиеләрендә хезмәт ияләренең язучылар һәм сәнгать осталары белән очрашуларын оештырды.

Июнь аенда менә нинди очрашулар булды:

**Мөслим районында:**

Шагыйрьләрдән Илдар Юзеев, Марс Шабаев, композитор Мирсәет Яруллин, җырчылардан Хәдичә Гыйниятова һәм Сәлим Хәялиевлардан торган бригада чыгыш ясады.

**Нижнекамск районында:**

Габдрахман Минский, Гөлшат Зәйнашева, танылган җырчы Әлфия Афзалова, яшь шагыйрь Мөнир Шәймөхәмметовлар күңелле очрашулар үткәрделәр.

**Балтач районына:**

Шагыйрь Самат Шакир, композитор Заһид Хәбибуллин, нәфис сүз остасы Рафаэль Галиевлар барды.

**Дөбьяз районында:**

Драматург Риза Ишморат, шагыйрь Рәшит Гәрәй, композитор Әнвәр Бакиров, яшь язучы Габдулла Шәрафиевлар бригадасы колхозчылар, укучылар һәм укытучылар белән очраштылар.

Язучы Мәҗит Рафиков һәм Кави Латыйпов Горький тимер юлчыларының Казан бүлеге оештырган агит-вагонда Арча — Шәмәрдән — Вятские-Поляны маршруты белән йөрделәр. Алар тимер юл эшчеләрен татар әдәбиятының бүгенге көне белән таныштырдылар, әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

* * *

Язучыларның Тукай клубында укытучыларның белемен күтәрү институты оештырган курсларга килгән татар теле укытучылары, мәктәп директорлары белән әдипләр очрашты. Бу кичәдә Нәкый Исәнбәт, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, филология фәннәре кандидаты Хәмит Ярми, шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нәби Дәүли, язучы Атилла Расих, балалар язучылары Гариф Гобәй һәм Ләбибә Ихсанова, язучы Самат Шакир үзләренең әдәбият турындагы фикерләре белән уртаклаштылар, соңгы вакытларда язган әсәрләре, иҗат планнары белән таныштырдылар. РСФСРның татар мәктәпләреннән килгән укытучылар язучыларны зур кызыксыну белән тыңладылар, соңыннан күп кенә сораулар бирделәр.

* * *

Язучы Малик Хәмитов Мамадыш районында булып кайтты. Район хезмәт ияләренә ул бүгенге татар әдәбияты һәм «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр турында сөйләде.

Район газетасы редакциясе каршындагы «Яшь авазлар клубы»ның чираттагы утырышында яшь һәм башлап язучылар белән әңгәмә үткәрелде.

## ЯҢА СЕКТОР АЧЫЛДЫ

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты составында яңа сектор — сәнгать секторы оештырылды.

Аңа татар театры тарихы, халык музыкасы һәм халык сынлы сәнгатен фәнни тикшерү бурычлары йөкләтелде. Институтның гыйльми советы сектор мөдире итеп филология фәннәре кандидаты, язучы Баян Гыйззәтне сайлады.

## ГОРЬКИЙ МУЗЕЕНДА ЯҢА БҮЛЕКЛӘР

Шушы көннәрдә Казандагы Горький музеенда ике яңа бүлек ачылды. Берсе пролетар язучысының якын дусты, атаклы җырчы Федор Иванович Шаляпинга багышланган, ә икенчесе «Горький һәм татар әдәбияты» дип атала. Ф. И. Шаляпинга багышланган бүлекне ачу тантанасында катнашу өчен Мәскәүдән атаклы җырчының кызы Ирина Федоровна Шаляпина килгән иде. Ул бирегә җыелган әдипләргә, укучы балаларга, эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә Федор Ивановичның Казанда үткәргән балалык елларыннан, Алексей Максимович белән очрашып, дуслашу вакытларыннан бик күп истәлекләр сөйләде. Соңыннан ул Шаляпинның шәхси әйберләре белән таныштырды, аларның һәркайсының тарихын сөйләде. Бирегә Федор Ивановичның гомере буе уйнаган рояле, ноталары, кон-

церт программалары, концертларда алган мактау венокларының тасмалары, җырчының киеп йөргән киемнәре, тростлары, чәй сервизлары, урындыклары һ. б. кыйммәтле экспонатлар бар.

«Татар әдәбияты һәм Горький» дигән бүлектә заманында Максим Горький белән очрашкан, аның белән хатлар алышкан, аның әсәрләрен тәрҗемә иткән, бөек әдиптән язарга өйрәнгән татар язучыларының фоторәсемнәре, китаплары, аларның Максим Горький турында әйткән сүзләре урнаштырылган щитлар куелган.

Бу ике бүлек музейга килүчеләр тарафыннан зур кызыксыну белән карала.

### ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Татар совет театры сәнгатенә зур өлеш керткән режиссер Гомәр Исмәгыйловка 60 яшь тулып узды. Утызынчы елларда Татар академия театрында ул сәхнәгә куйган «Томан арты» (Ш. Камал), «Чаткылар» (Т. Гыйззәт), «Галиябану» (М. Фәйзи) һәм аеруча «Ташкыннар» (Т. Гыйззәт) спектакльләре режиссерның иҗат диапазоны киңлеге һәм аның таланты турында сөйлиләр. Г. Исмәгыйлов үзенең иҗаты белән үзбәк һәм Кырым татарлары театрларының үсешенә зур өлеш кертте. Журнал редколлегиясе Гомәр ага Исмәгыйловка озын гомер һәм тагы да зур иҗат шатлыклары теләп кала.

### КОЛХОЗЛАРДА СИМФОНИК КОНЦЕРТЛАР

Татарстанның Дәүләт симфоник оркестры СССР халык артисты, дирижер Натан Рахлин җитәкчелегендә республикабызның нефть районнарына гастрольгә чыкты. Аның программасында Чайковскийның икенче симфония финалы, Бетховенның «Эгмонт» увертюрасы, Листның икенче венгер рапсодиясе һәм Чайковскийның итальян каприччиосы һәм татар композиторларының әсәрләре бар иде.

Симфоник оркестр Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә, Лениногорск һәм Нижнекамск районнарында нефтьчеләр, колхозчылар алдында чыгыш ясады. Районара симфоник оркестр белән очрашу һәм иҗади сөйләшүләр үткәрде.

### КОНКУРСТА ҖИҢДЕ

Мәскәүдә курчак театрларының Бөтенроссия ярышына йомгаклау туры узды. Курчакчылар форумына Союзның барлык курчак театрларыннан директорлар, баш режиссерлар, художниклар җыелган иде. Социалистик илләрдән кунаклар килүе дә бу тантаналарны арттырды. Казан курчак театры режиссер И. М. Москалев куйган «Әбугалисина» һәм «Бер, ике, өч, дүрт, биш» спектакльләре өчен II дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

### МУЗЫКА МӘКТӘБЕНӘ 25 ЕЛ

Зеленодольск шәһәрендә музыка мәктәбе ачылуга 25 ел тулды. Ул 1943 елның утлы сугыш көннәрендә эшли башлаган иде. Хәзер анда 400 бала фортепьяно, скрипка, виолончель, баян, домбра, кларнет классларында укыйлар. Талантлы укучыларга соңыннан илебезнең барлык өлкәләрендә дә югары музыка белеме алырга мөмкинлекләр тудырылган.

### ӘЛИШЕР НӘВОИГА БАГЫШЛАНГАН УТЫРЫШ

Шушы елның 10 июнендә СССР Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының киңәйтелгән гыйльми советы утырышы булды. Ул үзбәк халкының бөек шагыйре, акыл иясе һәм җәмәгать эшлеклесе Әлишер Нәвоиның тууына 525 ел тулуга багышланды. Утырышта институтның өлкән гыйльми сотрудникы, филология фәннәре кандидаты Ш. Ш. Абилов «Әлишер Нәвои һәм татар совет әдәбияты» дигән темага доклад ясады. Конференц-залда Ә. Нәвои әсәрләреннән зур күргәзмә оештырылган иде.

### ДИССЕРТАЦИЯЛӘР ЯКЛАНДЫ

Казан университетының тарих һәм филология фәннәре буенча гыйльми дәрәҗәләр бирү советында тәнкыйтьче һәм фән эшлеклесе Гали Халит «Татар әдәбиятында иҗат методларының проблемалары» дигән темага докторлык диссертациясе яклады.

Оппонентлардан филология фәннәре докторлары профессор Кирәй Мәргән, профессор Хатип Госман, профессор Н. А. Гуляевләр бу хезмәткә югары бәя бирделәр.

* * *

6 июньдә Казан университетының гыйльми советында тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре Ф. Урманчеев һәм Алабуга педагогия институты проректоры Т. Галиуллин диссертация яклады. Беренче диссертация татар совет халык иҗатындагы төп жанрларның үсеш юлларын тикшерүгә багышланган иде. Икенче диссертациянең темасы — «Хәзерге татар поэзиясе һәм халык иҗаты». Рәсми оппонентлар һәм фикер алышуларда катнашучылар — университет профессоры Х. Госман, СССР Фәннәр академиясенең Башкортстан филиалы өлкән фәнни хезмәткәре С. Галин, филология фәннәре кандидаты А. Яхин, тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре И. Надиров һ. б. — диссертацияләрнең актуаль темаларга һәм фәнни яктан тирән итеп язылуларын билгеләп үттеләр.

7 июньдә тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре Ф. Әхметова Казан дәүләт педагогия институтының гыйльми советында «Фольклор һәм хәзерге татар прозасы» дигән темага диссертация яклады. Профессор М. Гайнуллин, филология фәннәре кандидатлары М. Җәләлиева, С. Галин аның хезмәтенә югары бәя бирделәр.

Һәр ике гыйльми совет яшь фольклорчыларга филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирү турында бертавыштан карар кабул итте.

# Хөрмәтле укучыларыбыз!

**Шушы елның сентябрь аеннан 1969 ел өчен газета-журналларга, шул исәптән «Казан утлары» журналына да, язылу башлана, «Казан утлары»н ел башыннан ук берничә мәшәкатьсез ала башлыйсыгыз килсә, озакка сузмыйча гына аңа язылып куегыз!**

**«Казан утлары» — Бөтенсоюз каталогына кертелгән журнал. Аңа Советлар Союзының теләсә кайсы элемтә бүлегендә һәм теләсә кайсы «Союзпечать» агентлыгында һичтоткарлыксыз язылырга мөмкин. Бөтенсоюз газета-журналлар каталогына ул 73210 индексы белән теркәлгән. Шул индексны әйтсәгез, Сезне журналга бик ансат яздырырлар. Әгәр үзегез яшәгән җирдә нинди дә булса сәбәп аркасында безнең журналга язылу мөмкинлеге булмаса, аңа түбәндәге адрес буенча акча җибәреп тә язылырга мөмкин:**

*г. Қазань, ул. Куйбышева, дом 17/25.*
*Областной отдел «Союзпечать».*

**Язылу бәясе: бер елга — 4 сум 80 тиен,**
**бер саны — 40 тиен.**

**Укучыларыбыз арасында «Казан утлары»н җәмәгать тәртибендә таратучы иптәшләр дә шактый күп. Безнең редакция аларны ел саен истәлекле бүләкләр белән бүләкләп килә. Ул иптәшләр бу ел да «Казан утлары»на подписка җыюда актив катнашырлар дип ышанабыз. Журналга кимендә 100 кешене яздырган иптәшләрне редакция быел да кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләячәк.**

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210